Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы
Ләбиб Айтуганов исемендәге
Девятерня төп гомумбелем бирү мәктәбе



# Девятерня мәктәбенең 100 еллык кыскача тарихы






Ләбиб Айтуганов исемендәге Девятерня төп гомумбелем бирү мәктәбенең тарих һәм география укытучысы Шайхутдинов Илдус Нургаян улы редакциясендә эшләнде.



ДЕВЯТЕРНЯ
2017

**Эчтәлек**

1. Кереш.
2. 1 нче бүлек.1917 нче елгы революциягә кадәр белем бирү системасы тарихы.
3. 2 нче бүлек. Яңа чорда – яңа тарих.
4. 3 нче бүлек. Бөек Ватан сугышы елларында Девятерня авылы мәктәбе
5. 4 нче бүлек. Сугыштан соң авыл һәм Девятерня мәктәбе (1947 – 1964 еллар).
6. 5 нче бүлек. Девятерня мәктәбе 1964 -1980 нче елларда.
7. 6 нчы бүлек. Девятерня авылы мәктәп тарихы, 1980-1982 еллар.
8. 6 нчы бүлек. 1982-2000 елларда Девятерня мәктәбе.
9. 7 нче бүлек. 2000-2010 еллар, 21нче гасыр башы – хезмәттәшлек, бергәләп җитәкчелек итү чоры.
10. 8 нче бүлек. 2010 нчы елдан соң Девятерня мәктәбе.

11. Йомгаклау.
12. Кушымталар.
    12.1. Мәктәп барлыкка килүдән башлап бүгенге көнгә кадәр мәктәп җитәкчеләре.
    12.2. Укыту-тәрбия эшләре буенча директор урынбасарлары (завучлар).
    12.3. Тәрбия эшләре буенча директор урынбасарлары (организаторлар).
    12.4. Өлкән пионервожатыйлар.
    12.5. Хуҗалык мөдирләре.
    12.6. Мәктәпне медальгә тәмамлаучылар исемлеге.
    12.7. Ләбиб Айтуганов исемендәге мәктәп премиясе лауреатлары.
    12.8. Л. Айтуганов исемендәге Девятерня мәктәбе буенча педагогик династияләр.
    12.9. “Буби” мәдрәсәсен тәмамлаган шәкертләр исемлеге.
    12.10. Татарстан республикасы милли архивыннан бирелгән Девятерня мәктәбе ачылу турындагы белешмә.
    12.11. Девятерня урта мәктәбенең 75 еллык юбилеен үткәрү турындагы Әгерҗе районы хакимияте башлыгының карары.
    12.12. Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының Девятерня урта мәктәбенә Ләбиб Айтуганов исеме бирү турындагы боерыгы.
    12.13. Девятерня мәктәбен тәмамлаучылар исемлеге.
    12.14. Фотоларда мәктәп тарихы.
13. Файдаланылган әдәбият исемлеге.

## Кереш

*Без – төньягы татар иленең,*
*Бер тамчысы Бөек Иделнең.*
*Мин чишмәңә бүген иелдем,*
*Тарихларга чумдым, күмелдем.*
*Филисә Хәкимова.*

Әйе, Татарстан Республикасының төньяк-көнчыгышында урнашкан Әгерҗе районы – Бөек Иделнең бер тамчысы. Район үзәгеннән шактый читтә урнашкан Девятерня авылы минем өчен бик кадерле. Туган авылым күрке булып, калкурак җирдә урнашкан ике катлы мәктәп бинасы ерактан ук сәлам биреп тора. Мәктәбебез үткән тарихны белү теләге безне эзләнү эшенә этәрде, чөнки минем уемча, һәр кеше үзе белем алган мәктәбе турында күбрәк белергә, аның тарихын мәңгеләштерергә омтылырга тиеш. Моның өчен Республика Үзәк дәүләт тарихи-сәяси документлар архивыннан соратып алынган документларны өйрәндек, авылыбызның "аяклы тарихы" Айдарова Мәүгыйдә Хәйдәр кызы тарафыннан 1974 елда төзелгән "Алар бездә укыттылар" дигән альбомнан файдаландым, Әгерҗе төбәгенә кагылышлы китапларны укыдым һәм мәктәбебез ветераннары язып калдырган истәлекләрне кулландым. Бу истәлек документларны бик кызыксынып өйрәндем һәм үзем өчен бик кызыклы нәтиҗәләр чыгардым. Авылым мәктәбе үзенең бай тарихы белән күпләрнең күңелләрендә горурлык хисләре уята.

Рәсми дәүләт тарихы бездә һәрвакытта да сәясәт һәм идеология йогынтысында языла. Нәтиҗәдә анда фактлар белән туры килми торган югары түрәләр һәм аерым вакыйгаларны рәсми идеологиягә якынайту максаты белән бозып күрсәтүләр, уңышларны күпертү, аерым охшамаган фактларны төшереп калдыру очрклары бик күп, ялган экиятләр дә җитәрлек. Аерым авторлар редакциясендә бөек рус шовинизмы рухында язылу очраклары да байтак.

Ә чын, дөрес тарих ул бар, булган бит!

Архив документларында чын тарих саклана. Һәрбер төбәкнең – авылның, районның чын тарихын язарга инде күптән вакыт, соңга да калып барабыз бугай. Тарихи шәхесләребез арабыздан китеп бара, еш кына алар белән бергә тарихи документлар, тарих шаһитләре һәм аерым тарих фрагментлары да югала.

Республикада Үзәк дәүләт тарихи-сәяси документлар архивы эшли. Аның документларын өйрәнеп, торган җиребезнең чын дөрес тарихын булдыру – безнең өстенлекле юнәлешләребезнең берсе.

Балаларда Туган ягыбыз тарихы һәм мәдәнияте белән кызыксыну, шушы кыйммәтләрне саклау теләге тәрбияләү мәктәпнең бер әһәмиятле бурычы булырга тиеш.

Туган як тарихына патриотларча караш тәрбияләү, минемчә, һәрбер аек акыллы, үз төбәген, торган җирен, эчкән суын яратучы кешенең изге бурычы, намус эше булырга тиеш кебек тоела. Чөнки торган җир – туган ил – Ватан – ул синең әтиең, әниең, апаң, абыең, энең, сеңлең, әбиең, бабаң. Ул – синең туган, яшәгән йортың, урамың, авылың. Ул - син укый яки эшли торган мәктәп. Ул – синең сулаган һаваң, басып йөргән җирең. Ул – безнең барлык байлыгыбыз. Ә төп байлык – шул урында яшәүче халык, халкыбызның тагын бер байлыгы - ул аның 1000 елдан артык булган тарихы. Тарихны өйрәнмичә, үткәнне белмичә, хәзерге тормышны аңлап, яңаны төзеп булмый. Чөнки бүгенге тормыш меңнәрчә елларның җимеше, нәтиҗәсе ул. Тарих – хәтер ул. Ул азатлык өчен башларын җуйган каһарман җаннарны онытмаска өйрәтә. Тарихыбызда булган ялгышлыкларны кабатламаска, бердәм булырга сабак бирә. Сатлыкҗаннарга карата нәфрәт уята. УЗГАН ТАРИХЛАРЫН ОНЫТКАН ХАЛЫКЛАР ЮККА ЧЫГА!!! SOS!!!

И.Н.Шайхутдинов

## 1 нче бүлек
## 1917 нче елгы революциягә кадәр белем бирү системасы тарихы

Без яшәгән төбәк – Урта Идел буендагы хәзерге Татарстан урнашкан, Кады, Көтмәс, Бима елгалары, Тугызбуй төбәге җирләре дә борын-борыннан бик күп халыкларның очрашып, үзара тел, лөгать һәм әхлак алмашу урыны булган. Безнең төбәкнең дә илебездә барган вакыйгалар белән тыгыз бәйләнгән кызыклы тарихы бар. Мәгариф, тел, уку, укыту, мәктәпләр тарихы күпьеллык гомуми тарихыбызның состав өлеше булып тора.

Безнең борынгы бабаларыбызга зур йогынты ясаган халыклар һуннар (гуннар), төрки каганлыгында үз заманасы өчен элементар белем бирү системасы булган. Хәзәр каганлыгында рун язуы киң таралган була. Бөек Болгар иле хәзәрләр тарафыннан тар-мар ителгәч, болгарлар, Азов буйларыннан безнең якларга килгәннән соң, яшәү традицияләрен дә алып киләләр. Болгарлар килгәнче, күп заманнар элегрәк безнең якта мари, удмурт халыкларының борынгы бабалары булганнар, ләкин аларның нинди дә булса язудан файдаланулары турында мәгълүматлар юк. Ә Болгарлар башта рун язуыннан файдаланганнар. Исламны кабул иткәч, ягъни 922 нче елда, гарәп әлифбасына нигезләнгән язуга күчәләр. Вакытлар узу белән гарәп язуы шактый киң тарала. Элегрәк күпчелек каен тузына һәм балавыз белән капланган такталарга язганнар. Язу өчен сөяк һәм каләмнән файдаланганнар. Бер үк вакытта Сәмәркандтан алып кайтылган кәгазъ дә күренә башлый. Кәгазъгә каурый каләм белән карага манып язганнар.

Кульязма китаплар бик озак язылганнар һәм кыйммәт торганнар. Алар өчен чыдам тышлыклар ясаганнар. Китапларны бик кадерләп саклаганнар.

Хәзерге татарларның килеп чыгышы безнең төбәкне монголлар яулап алганнан соң башлыча болгарлар һәм кыпчаклар белән бәйле. XIII гасыр урталарыннан һәм аннан соңгы еллардан башлап Идел болгарларын төбәкнең башка халыклары белән кушылганнан соң татарлар дип атый башлаганнар.

Вакытлар узу белән Алтын Урда составында яшәүче татарларда мәгариф нык үсеш ала. Дәрәҗәле кешеләр генә түгел, гади халыкның да күпчелеге укый-яза белгән. Мәдрәсәләрдә гарәп әлифбасын кулланганнар. Металл каләм белән кәгазъгә күпчелек Коръән аятьләре һәм шәрык шагыйрьләренең шигырьләрен язганнар. Мәдрәсә һәм мәктәпләрдә Ислам кануннарын, дини дисциплиналар, шигырь сәнгатен өйрәнгәннәр.

XV гасырның беренче яртысында Урта Иделдә барлыкка килгән яңа дәүләт - Казан ханлыгында язу шулай ук гарәп әлифбасына нигезләнгән була. Эш кәгазьләрен, китапларны, төрле язмаларны шушы имляда язганнар.

1552 нче елда татарлар үз дәүләтчелеген югалталар һәм шуннан соң мәдәният үсешенә ярдәм итәрлек бердәнбер көч мөселман руханилар була.

Архивларда Тугызбуй җирлегенә бәйле 1518, 1545 нче елларга караган грамоталар барлыгына ишарәләр бар... Хәзерге архив материаллары арасында Девятерня 1622 нче елда телгә алына башлый. Шулай булгач, авыл буларак, ул XVI гасырның икенче яртысында формалашкан булырга тиеш һәм, шушы еллардан башлап, анда яшәүче халыкның укымышлылык тарихы да шул чордан башлана дип уйларга нигез бар. Безнең бабаларыбыз күченеп килгән яңа җирләрне үзләштерү, хуҗалык итәрлек һәм яшәрлек шартлар тудыру, руслаштыру һәм христианлаштыру сәясәте кыенлыкларын җиңү һәм хисапсыз башка кыенлыкларны хәл итеп кенә калмыйча, борынгы бабаларының элек-электән килгән диннәрен, традицияләрен, бәйрәмнәрен, телләрен, гореф-гадәтләрен һәм дә мәгарифләрен саклап калганнар һәм үстергәннәр. XVII, XVIII, XIX гасырлар барышында мәркәзебез Казанда, акрынлык белән булса да, мәгариф өлкәсендә уңышларга ирешелгән: уку йортлары ачылган һәм аларда укып чыккан мәгърифәтле кешеләрнең безнең як халкына йогынтысы зур булган.

XV-XVI гасырларда татарларның эстетик һәм укуга булган ихтыяҗы элек иҗат ителгән әсәрләр, халык авыз иҗаты, гарәп, фарсы телләреннән тәрҗемәләр хисабына канәгатьләндерелгән.

1718 нче елда Казанда “Хисап мәктәбе” ачылган, ләкин анда крестьян балалары укырга алынмаган.

1732 нче елда руханилар әзерләү өчен славян-латин училище ачыла, соңыннан ул семинария итеп үзгәртелә, 1797 нче елда академия була һәм Казанда 1918 нче елга кадәр эшли.

1758 нче елда дворян һәм бай катлау балалары өчен Казанда, Россиядә беренче булып, провинциаль гимназия ачыла, анда 1769 нчы елда татар сыйныфы ачылып, Екатерина II нең махсус указы белән мөгаллим итеп татар укымышлысы Сәгыйть Хәлфин билгеләнә. Аңа губернаның баш тылмачы дигән дәрәҗә дә бирелә. Аның 1778 нче елда гарәп имлясы белән “Татар теле әлифбасы” дигән грамматикасы Мәскәү университеты типографиясендә басыла. Император Павел I, 1799 нчы елда, “дини китаплар һәм догалыклар” бастыру өчен, Казанда татар типографиясе ачарга рөхсәт бирергә мәҗбүр була. Бу типография гимназия каршында ачыла. 1801-1802 нче елларда басылып чыккан беренче китаплар әлифбалар һәм “Һәфтияк” була. Бу атаклы гимназиядә безнең төбәкнең (Идел-Кама буе төбәге) һәм Россиянең атаклы күренекле кешеләре укып чыкса да, провинциаль безнең як гади кешеләре уку турында бернинди дә мәгълүмат юк. 1804 нче елда беренче Казан гимназиясе нигезендә Казан университеты ачылып эшли башлый. Бу дәрәҗәле уку йортында безнең авылдан да күп кенә егет һәм кызларга югары белем алу бәхете елмая. Сүз уңаеннан, Девятерня авылы мәктәбен бетереп төрле уку йортларында беренчеләрдән булып югары белем алган авылдашларыбыздан Рахматуллин Мәгъсүм Хикматулла улын (Ижау механика институты), Гимашева (Салахиева) Зәйтүнә Сәләхи кызы, (Казан медицина институты 1958-1964 еллар), Айтуганов Ләбиб Кирам улын (Казан педагогика институты, 1954 ел) китерергә мөмкин.

1786 нчы елдан соң гына губерна шәһәрләрендә дүрт сыйныфлы төп училищелар, өяз шәһәрләрендә (безгә якыннары Алабуга һәм Сарапул) ике сыйныфлы укытуга корылган кече халык училищелары ачылган.

Казан бистәләре өязләрендә татар балалары земство башлангыч мәктәпләрендә һәм мәдрәсәләрдә белем алган. Ләкин безнең Тугызбуй авыллары, белгәнебезчә, Казан губернасына керми, ә Вятка губернасының Сарапул өязенә карый, шунлыктан, билгеле, урыс теле өстенлек иткән Сарапул өязендә Исәнбай волосте авыллары балаларын укытуга башлап йөрүче һәм ярдәм итүче булмаган.

Күп гасырлар буенча яшәп килгән мәчетләр төзүне тыю XVIII гасырның икенче яртысында Екатерина II патшалык иткән вакытта бетерелә, Казанда Апанай, Ахун, Әмирхан мәдрәсәләре кебек эре уку йортлары барлыкка килә. Аларда укыту киң программа буенча алып барыла. Шул вакыттан башлап һәр авылның мәчете, аның карамагындагы мәдрәсәсе була, указлы муллалар кайтартыла, анда балалар гарәп графикасы нигезендә белем алганнар, мәдрәсәләр ата-аналар һәм авыл байлары хисабына яшәгәннәр. Һәрбер мәэмин-мөселман Коръән укый белергә тиеш дип саналган. Шуңа күрә татарлар арасында укый-яза белү башка халыклар белән чагыштырганда (мәсәлән, безнең якларда яшәүче мари һәм удмуртларга караганда) күпкә укымышлырак булганнар. Мәдрәсәләрдә балаларны гарәп әлифбасы нигезендә укырга-язарга өйрәткәннәр. 1802 нче елда Казанда Мортаза Симети әлифбасы басылып чыга. Балалар безнең якта да шушы әлифба нигезендә укытылган булырга мөмкин. Мәдрәсәләрдә балаларны дин сабагына, укырга-язарга гына түгел, әдәплелеккә, сакчыллыкка һәм ата-бабадан килгән яхшы гадәтләргә күнектерергә, иманга өйрәтү хакында да кайгыртканнар.

Девятерня авылында электән үк бер мәчет булган. Ислам динен тоткан Идел буе татарларына хас булганча һәр мәчет каршында мәктәп тә эшләп килгән. Мәктәп өчен махсус бина булмаган очракта мулла һәм аның җәмәгате – абыстай үз өйләрендә ир һәм кыз балаларны аерым укытып, сабак биргәннәр. Архив документлар күрсәткәнчә, күрше Нарат авылында мәдрәсә 1832 нче елда һәм 1841 нче елда мәктәп ачыла. 1904 нче елдан өяз земствосы тарафыннан рус- татар мәктәбе эшли башлый. (“Әгерҗе төбәге тарихы”, Р.Мәрдәнов, И.Һадиев) Девятерня авылында революциягә кадәр уку йортлары ачылу турында конкрет мәгълүмат булмаса да (хәзергә) Нарат авылындагы кебек уку йортлары якынча шул ук елларда ачылган дип фаразлана.

Якташыбыз (Кадыбаш авылыннан) Шакиров Раил абыннның тарихи-әдәби язмаларында Девятерня авылында мулла Вахит хәзрәт эшләгәндә ике мәхәллә төзелүе турында әйтелә. Вахит хәзрәткә эш күп булгач, Чулман аръягы Каентүбә авылыннан Шәрип хәзрәтне алып кайталар. Авылда ике мәхәллә булып бер мәчет эшли. Соңыннан Шәрип хәзрәтнең улы Габдулла хәзрәт мулла булып кала.

Шул ук Раил Шакировның Нарат авылы тарихына багышланган тарихи-әдәби әсәрендә 1869 нчы елда Нарат авылында Габделсаттар мулла Сөендековның Маһринур абыстай белән берлектә ике катлы йортта 26 шәкертне укытуы телгә алына. Өйләрендә кечкенә китапханә

була, уллары Габделҗан китапханәдә бик күп укый, соңыннан Казанга зур мәдрәсәгә укырга китә, Истамбулга укырга һәм Хаҗга бармакчы була. Габделсаттар үзе Исәнбай авылында мөәзин гаиләсендә туа, 7 ел Сәмәркандта белемен дәвам итә. Уфада мөфти катында имтихан тота һәм 30 яшендә указлы мулла булып Нарат авылына кайта. Мазарасты мулласы киңәше буенча Маһринурга өйләнә. Мулла да, абыстай да әлифтән башлап, шәкертләрне укырга, шулай ук инсаф-әдәп, эш сөю, тыйнаклык, мөләемлек, мәрхәмәтлелек кануннарын каннарына сеңдерәләр. Малайлар өстәге өйдә, кызлар астагы катта укыйлар. Әмма алар башлыча кадими уку йортлары була. Габсаттар хәзрәт шулай ук иген иккән, терлек асраган, гади крестьян кебек яшәгән, тегүче булган. Ул тарих буенча китаплар туплаган. Үзе дә "Ак кирмән" ("Мирас бүлү") исемле китап язган. Ул 1816 елда Бубый мәдрәсендә укыган, 88 яшендә Нарат авылында вафат булган. (Туган елы 1796 ел, үлгән елы 1884 ел).

Җәдитчә уку оештырылган Иж-Бубый мәдрәсәсен татар дөньясының зур горурлыгы, мактанычы булган "мөселман академиясе" дип йөрткәннәр. Безнең авылдан да Иж-Бубый мәдрәсәсендә укып белем алучылар байтак булган. (Исемлек теркәлә). Мәдрәсәне тәмамлаган укытучыларның да безнең якларда белем бирүләре мәгълүм. Мәсәлән, Иң-Бубый укытучысы Иксанов Әхмәтзакирның 1910 елның 1 мартыннан Нарат авылы училищесында укытуы билгеле.

1869 нчы елда, архив мәгълүматлары буенча, Нарат авылы мәдрәсәсендә 52 кеше укый, Девятерня авылында да бу вакытта мәдрәсә эшли, мәктәпләр дә эшләгән, ачылу вакыты 1850 нче елгы мәгълүмат буенча "электән үк" дип күрсәтелгән. Мәктәпләрдә 3-4 ел укыганнар. Укулар, гадәттә, октябрь ахырында башланып, март ае беткәнче дәвам иткән. Дәресләр көн саен (җомга – ял көне) иртәнге 8 яки 9 да башланып, 6-7 сәгать дәвамында барган. Мәгариф министрлыгының 1870 нче елгы карары нигезендә татарларга яңа мәктәп һәм мәдрәсәләр ачу фәкать бер шартны үтәгәндә: рус телен укытуны керткәндә генә рөхсәт ителгән.

XX гасыр башында татар мәктәпләрендә акрынлап земство акчасына рус класслары яки махсус рус-татар мәктәпләре ачыла башлый. Андыйлар безнең якта Исәнбай, Үтәгән, Кадыбаш, Эсләк, Нарат авылларында ачылганлыгы билгеле (нишләптер, Девятерня авылы бу исемлектә юк). Девятерня авылыннан да мөмкинлеге, теләге булганнарның шунда барып укулары билгеле. Мәсәлән, бездә Исәнбай рус-башкорт башлангыч халык училищесын (Исенбаевское русско-башкирское земское начальное народное училище) 1914 нче елда тәмамлаган Мөсифуллин Мөхәммәдһади Исмагыйль улының укуы турында шәһадәтнамәсе бар. (Шәһадәтнамә теркәлә.) Архивта сакланган 1906 нчы елгы мәгълүматлар буенча Сарапул өязенә караган рус-татар мәктәпләренә земство тарафыннан Үтәгәннекенә 780 сум, Наратныкына 520 сум, Кадыбашныкына 432 сум акча бүлеп бирелгән. Ә саф татар мәктәп-мәдрәсәләренә ярдәм сораган очракта да хөкүмәттән бер тиен дә ярдәм бирелмәгән. Дәреслекләр булмаган. Ул вакытта бердәнбер төрки телле матбугат органы кырымтатар телендә нәшер ителгән "Тәрҗеман" газетасын яздырып алу да мөмкин булмаган. Шулай булсада, бабаларыбыз үз көчләренә ышанып һәм таянып, электән үк белемгә омтылганнар, мәгърифәтле булганнар. ("Әгерҗем – йөрәк җырым", Мансур Вәли-Барҗылы)

Шулай итеп, татарларда 1917 нче елга кадәр белем алу системасы була, ләкин белем алу мәдрәсәләрдә барлык җирдә дә бик үк тиешле югарылыкта булмагандыр. Г.Тукай ачынып "Күп яттык без мәдрәсәдә, аңламадык бер нәрсә дә", дип юкка гына язмагандыр. Ләкин ничек кенә белем бирүдә кимчелекләр булмасын, күп тарихчыларның татарларның белемгә омтылуы Россиянең көнчыгыш өлешендә яшәүче халыклар арасында күпкә югары булуын нигезләгән дәлилләре бар. Алар арасында гыйлемле кешеләр процент ягыннан руслар белән чагыштырганда да күбрәк булган. Кайсы катлаудан гына чыкмасын, татар кешесе һичшиксез башлангыч дин гыйлемен өйрәнгән һәм ул татарча укый-яза белә. XX гасыр башында татар халкының 80 %ка якыны ана телендә белемле булган! (Чагыштыру өчен) Ә менә күршеләребез удмурт халкында язу 18 гасыр ахырында гына барлыкка килә, бары 1775 елда гына рус язуы нигезендә удмурт теле грамматикасы төзелә, билгесез авторлар көче белән 2800 сүздән торган удмурт теле сүзлеге дөнья күрә. 19 гасыр башында да удмурт халкының бары 2 %, ә гасыр ахырында 8% гына чиркәү мәктәпләрендә укып укымышлы була, ә революция алдыннан 1916 елда удмуртларда укымышлылык 14,7% тәшкил иткән.(История нашего края, Ижевск, издательство Удмуртия,1981 год, 21 страница).

Җыйнап кына әйткәндә, бик күптәнге заманнардан алып безнең якта мәктәп, укытучылар мөһим урын биләгән. Ислам өммәтеннән булган татар кешеләре балаларына белем бирүне иң

изге бурычлары дип санаганнар.  Авылда элек тә, хәзер дә  иң затлы кеше булып мөгаллим санала.  Балалар өчен укытучы апалар, абыйлардан да яхшы, белемле, гадел кеше булмаган, булмады.  Безнең чорда да урамда  укытучыларның килгәнен еракта күрсәк, аңа олы хөрмәтебезне, ихтирамыбызны ирештерергә ашыга идек..

## 2 нче бүлек
## Яңа чорда – яңа тарих

Дөньяны тетрәткән 1917 нче ел... 1917 нче елгы революциядән соң мәктәпләрдә дин сабагы укыту тыела. Яңалиф укыту башлана. Яңа чор, яңа фикер, яңа карашлар, алгарыш, ялгышлар, яңа тарих башлана.

Яшь совет республикасы барлыкка килә. Большевиклар җитәкчелегендә республика көннән көн арта барган дошманнарына каршы көрәшә-көрәшә яңа сәяси, икътисади, милли, мәдәни политика алып бара. Безнең бурыч хәзерге вакытта уена килгән һәркем хурлый торган коммунистлар партиясе эшчәнлегенә бәя бирү түгел, алар эшчәнлегенең күп якларын тәнкыйтьләп карау бәлки дөрестер дә... Ләкин большевикларның сәяси һәм икътисади программалары күп тәнкыйтьләп булса да, мәдәни программаларын тарих һәм фактлар исбатлавынча нәтиҗәле була. Революциядән соңгы беренче елларда ук тәрбиясез калган балаларны кайгырту чаралары күренә. Мәктәп һәр катлау кешеләре өчен ачык гомуми уку йортына әйләнә.

Татарстан халык хуҗалыгын исәпкә алу архив фондыннан алынган архив белешмәсе буенча Красный Бор районы Девятерня авылында беренче дәрәҗәле башлангыч мәктәп 1917 нче елда Алабуга өязе мәгариф бүлеге тарафыннан ачылган. (Татарстан республикасы милли архивы №25, 12.02.02. Белешмә кушымтага теркәлә). *Димәк 2017 елда Девятерня авылында мәктәп ачылуга 100 ел тулды!* Аерым типовой мәктәп булмагач ташпулатта ике класс укытыла, укытучы булып Казанцева Зөхрә исемле укытучы эшли башлый, аерым мәктәп булганчы сөрелгән кешеләр Шакир бай һәм Муллахмәт бай өендә укый торган булганнар. Соңрак ике катлы агач мәктәп төзелә.

Күргәнебезчә, безнең як авыллары ничек кенә цивилизация учакларыннан ерак булса да, һәрвакытта да һәр торак пунктта нинди дә булса формада уку йортлары булган. 1917 нче елга кадәр мәдрәсәләрдә күбрәк дини сабак бирүгә игътибар зур булса, гасыр башында халыкның әкренләп дөньяви аң-белемгә омтылышы үсә, дөньяга карашлары үзгәрә башлый. Авылда ТБУМ, ягъни тулы булмаган урта мәктәп ачылганчы ук наданлыкны бетерү өстендә күп эш эшләнә. Балаларга башлангыч белем бирү белән беррәттән, зурларны да хәреф танырга, укый-яза белергә өйрәткәннәр. “Мәдәни революциянең” төп бурычларыннан берсе — наданлыкны бетерүгә юнәлдерелә. 1919 нчы ел ахырында “РСФСР халкы арасында наданлыкны бетерү турында” декрет кабул ителә. Клублар, уку биналары, мәдәният йортлары ачыла. Кара тактага язылган беренче җөмләләр — “Без кол түгел. Кол без түгел” дигән сүзләрне күпләр хәтерлидер. Белемле кешеләр саны артканнан арта бара. Ләкин мәгърифәтнең бу вакыттагы системасы кимчелекләре булу һәм катлаулы сәяси тормыш, Гражданнар сугышы чынлыкта күпчелек халыкта тулы урта һәм югары белем алу мөмкинлеге булдырмый, илдәге фәннең дөнья фәненнән артталыгы төп халык массаларының күп мәдәни кыйммәтләрдән читтә калуына китерә. Шулай да халыкның белемлелек дәрәҗәсе Татарстан территориясендә 1926 нчы елны күпкә арта (45 %ка җитә).

Халык хуҗалыгын тизләтелгән юл белән җимерекләрдән торгызу һәм үстерү, шулай ук илне индустрияләштерү белән бәйләп бару халык мәгарифе һәм халык хуҗалыгы өчен кадрлар әзерләүне иң төп, әһәмиятле мәсьәлә дип санарга мәҗбүр итә. Дәүләт һәм коммунистлар партиясе халык мәгарифе алдында киң хезмәт ияләре массаларының мәдәни үсешенә (гомуми белем бирү, наданлыкны бетерү, массакүләм һөнәри белем бирү) белемле белгечләр һәм фәнни хезмәткәрләр әзерләүне тәэмин итүче бурычлар куя. “Мәдәни революциянең” яңа этабы башлана. Мәдәният өлкәсендә ул гомуми мәҗбүри башлангыч белем бирүне кертү, 40 яшькә кадәрге олыларның наданлыгын бетерүне, мәктәпләр һәм мәдәният учреждениеләре челтәрен киңәйтүне, татарлардан белемле кадрлар әзерләүне күз алдында тота. Бу тулысынча үтәлерлек максат була. Девятерня авылында шулай ук башта яңа нигезләрдә эшли торган башлангыч, аннан соң бишьеллык һәм җидееллык мәктәп ачыла, яңа бина төзелә, төрле фәннәр буенча укыту өчен белгечләр кайта башлый. Балаларга башлангыч белем бирү белән беррәттән, зурларны да хәреф танырга, укый-яза белергә өйрәткәннәр.

Девятерня авылында хәзерге мәктәп 1926 нчы елда башлангыч мәктәп буларак ачыла. 1926-1927 нче уку елы беренче уку елы була.

Беренче башлангыч мәктәп ачылган елларда уку ике класслы бер бинада ике сменада алып барыла. Беренче чиректә укулар гарәп графикасында укытыла, аннан соң латин графикасы белән укытыла башлый. Кайбер елны ташпулатта 2 класс укытыла. Анда балаларны Иж Бубыйда туып үскән Казанцева Зөһрә укыта. Кайбер елларда укулар шулай ук Шакир Хаҗиның ике катлы йортында һәм Муллахмәт бай йортында да алып барыла. (Бу йортларның хуҗалары ниндидер сәбәпләр белән читкә сөреләләр.) Шулай ук Минсадыйк байның 2 катлы таш пулат йорты да типовой мәктәп бинасы төзелгәнче укыту өчен файдаланыла.

1928 нче елда хәзерге таш магазин урынында ике катлы итеп мәктәп бинасы салына. Укучыларның беренче укытучылары Үтәгән авылыннан килгән Җәмилова Зәйнәп, Девятернядан Казанцева Зөһрә (Җәмилова Зәйнәпнең әнисе) була. Соңрак Гомәров Габдулла, Садыйков Габдулхак, Сләк авылыннан Мөслимов Галимулла балаларга беренче дәресләрен бирә башлыйлар. Шул чорда мәктәптә укыган кешеләрнең сөйләүләре буенча бу вакытлар балалар өчен искиткеч зур бәхет, шатлык була. Беренче тапкыр үзәктән еракта урнашкан караңгы татар авылындагы кечкенә балалар дәүләтнең конкрет кайгыртуын сизәләр, аларны искиткеч сихри көчкә ия булган белемле педагоглар укыта башлый, шул көннәрдән башлап һәр балага түләүсез белем алырга киң мөмкинлекләр ачыла, шуңа күрә һәр туган көн балалар өчен бәйрәм була. Алар күтәренке күңел белән белем алалар, уйныйлар, җырлыйлар, цивилизацияле дөньяга якынаю мөмкинлеге алалар.

Күңелләре шатлык белән тулган әти-әниләр дә мәктәптән читтә калмыйлар, чөнки коммунистлар партиясе һәм совет хөкүмәтенең наданлыкны бетерү программасы буенча (ликбез) әти-әниләр дә кичләрен хәреф танырга, укырга, язарга өйрәнергә мәктәпкә киләләр. Бу чор авыл халкы күңелендә тирән үзгәрешләр, массовый төстә наданлыкка каршы көрәш, белемгә омтылыш, серле мәгърифәт дөньясына баруда беренче баскыч, өметләр, якты хыяллар чоры булып кала һәм болар барысы да авылыбызда мәктәп ачылу белән бәйләнгән.

Ләкин наданлыкны бетерү бурычы татар телен латин графикасына (яңалифкә) күчерү аркасында читенләшә. Бу карар 1927 нче елда кабул ителә. Нәтиҗәдә татарларның бер өлеше, бигрәк тә олы буын кешеләре наданнар хәлендә кала. Әлифба алмашу сәбәпле халыкның төп массасы элек нәшер ителгән ун меңнәрчә китапларны, кыйммәтле кульъязмаларны укый алмый башлый. Ул елларда ун ел эчендә әлифбаны ике кат алыштыру күп кешеләрне борчый. Девятерня җидееллык мәктәбендә 1930 елда татар телен латинча язуга күчерү тәмамлана. Яшьләр мең еллык милли мәдәнияттән мәхрүм калалар. Моңа кадәр безнең халык гарәп әлифбасыннан болгарлар ислам кабул иткәннән бирле X гасыр башыннан ук файдалана. Мең ел эчендә шул әлифба нигезендә басма һәм язма меңнәрчә китаплар языла. Дәүләти һәм көнкүреш эшләре шул әлифбага нигезләнә. Яңа әлифбага күчүнең төрле юрамалары бар. Аларның берсе менә нәрсәдән гыйбарәт. Татар халкы тормышында ислам дине зур урын алып тора. Гарәп әлифбасыннан баш тарту татарларны һәм башка халыкларны диннән аерыр өчен эшләнгәндер дип уйларга кирәк.

1928 нче елдан Девятерня 4-еллык башлангыч мәктәбе КЯМ (колхоз яшьләре мәктәбе, русчасы ШКМ) дип йөртелә башлый. Ләкин, билгеле, балаларның белемгә сусаган ихтыяҗларын бу мәктәпләр генә канәгатьләндерә алмый. Кызу темп белән үсеп килүче илебез халык хуҗалыгына белемле күп төрле белгечләр кирәк була. Шунлыктан Красный Бор районының Девятерня, Исәнбай, Бима һәм башка авылларында типовой проект белән зуррак мәктәпләр төзелә башлый. Бу чорда авылда халыкның тормыш хәле дә яхшыра башлый, халык саны туктаусыз арта. Девятерняда 1926 нчы елгы халык санын алу нәтиҗәләре буенча 319 хуҗалык булган, 1416 кеше яшәгән, халык саны буенча хәзерге Әгерҗе районы авыллары арасында 6 нчы урында, ә ул чактагы Красный Бор районнары авыллары арасында Исәнбай, Сләк авыллары белән иң зурларыннан саналган. (Чагыштыру өчен: 2002 нче елның 1 нче гыйнварына Девятерняда 231 хуҗалык булып, 606 кеше яшәгән. Халык саны буенча район авыллары арасында 10 нчы урында.) 1926 нчы елда бер хуҗалыкта уртача 4,4 кеше яшәсә, 2002 нче елда ул 2,6 кеше тәшкил итә, ягъни 1,7 тапкыр кимрәк. 1919 нчы елда 365 хуҗалыкта 1514 кеше яшәгән. Бу Девятерняда исәпкә алынган иң күп халык яшәгән ел.

1931-32 нче уку елында беренче тапкыр бишенче класс ачылган Девятерня тулы булмаган урта мәктәбендә (ТБУМ) (җидееллык) якын-тирә авыллар – Нарат, Гали, Кадыбаш, Сләк, Атнагул, Алга, Касай, Татарстаннан да килеп белем алучы 200дән артык укучы була. Аларга 18 укытучы белем бирә.



**Девятерня колхоз яшьләр мәктәбенең I-II-III-IV-V класс укучылары, укытучылары, хезмәткәрләре. 1.09.1932.**

Уртада сулдан уңга:

1. Гәрәева Валентина Ивановна – рус теле укытучысы.
2. Гәрәев Мансур Гәрәевич – мәктәп директоры
3. Ямалиев Лотфулла Ямалиевич – табигать белеме укытучысы.
4. Мөсифуллина Әминә Әкмалетдиновна – химия-биология укытучысы.
5. Мөсифуллин Әкмалетдин – татар теле укытучысы.
6. Тулбаев Бәдыйк – мәктәп завучы.
7. Тулбаева Зифа - башлангыч класс укытучысы
8. Гумеров Габдулла Габдрахманович – башлангыч класс укытучысы.

Мәктәпнең (ТБУМ) яңа стандарт бинасы 1932 нче елның декабрь башында салынып бетә. Шул көннән башлап 5 класс укучылары ике параллель класска бүленеп, яңа бинада укый башлыйлар. Мәктәп төзүдә Шәйдуллин Мулламөхәмәт җитәкчелегендә бригада эшли, прораб район үзәге Красный Бордан килә. Мәктәп авылның төньяк көнбатыш ягында басу түрендә төзелә. Аны төзү, агач ташу һәм башка эшләрдә 9 авылның атлы кешеләре катнаша, чөнки башка якын-тирәдәге авылларда башлангыч мәктәптән кала, өлкән класслар булмый, шуңа укырга күрше авыллардан да балалар килә. (Нарат, Гали, Кадыбаш, Сләк, Атнагул, Үтәгән, Касай авылларыннан).



*Девятерня авылында җидееллык мәктәбе ачылган елны (1932 нче ел) бишенче класс укучылары.Укытучылар (сулдан уңга – утырганнар):Мөсифуллин Әкмәлетдин, Батыршин Хәсән, Гәрәев Мансур (мәктәпнең беренче директоры), Тулбаев Бәдыйк (мәктәпнең беренче завучы), Әбләева Хәнифә, Шакиров Фәһем (беренче учком председателе)*

Мәктәп биш бүлмәле булып, анда 1-5 нче класслар урнаша. Беренче звонокка ата-аналар, җәмәгать оешмасы вәкилләре килә, мәктәп ачу тантанасы аеруча тәэсирле оештырыла, Интернационал җырлана. Ата-аналарның күзләрендә яшь бөртекләре ялтырый, ул яшь бөртекләре зур шатлык билгесе була, чөнки аларның балаларына белем ишекләре тагын да киңрәк ачыла.



**Девятерня жидееллык мәктәбенең беренче укытучылары.**

1 рәттә сулдан уңга:

1. билгесез.
2. Гәрәев Мансур
3. Тулбаев Бадыйк
4. Мөсифуллин Әкмалетдин
5. билгесез.
6. билгесез.

2 рәттә сулдан уңга:

1. билгесез.
2. Мөсифуллина Әминә
3. Гумеров Габдулла
4. Гәрәева Валентина.

Түбәндә мәктәпнең беренче укытучылары турында кыскача белешмә китерелә.



**Тулбаев Бәдыйк** җидееллык мәктәпне беренче төзетүче. Ул 1932 нче елдан Девятерня колхоз яшьләр мәктәбенә завуч булып килә. Яңа гына нигез салынып, башланып киткән мәктәптә идея –политик тәрбия эшләрен алып бару бик авыр була. Төрле авыллардан җыелган төрле яшьтәге төрле белемле балалар белән эшне юлга салу аның өстенә төшә. Физика-математика укытучысы буларак та, яшь белгечкә фән нигезләрен төшендерү күп көч сорый, уку әсбапларыннан башка күргәзмә материаллары бөтенләй булмый. Төрле белем белән, төрле җирләрдән килгән укытучылар коллективын оештыру да аның җилкәсенә төшә. Җәмәгать эшләреннән дә аңа зур өлеш чыга.

1936 нчы елдан 1941 нче елга кадәр мәктәпнең директоры вазифасы аңа күчә. Мәктәптә булган барлык хуҗалык, тәрбия эшләре аның җилкәсенә төшә.

1941 нче ел. Сугыш. Ватан сугышы фронтларында батырлыклар күрсәтеп көрәшеп, җиңеп Үтәгән җидееллык мәктәбенә директор булып кайта.

Анда да сугыш вакытында кичергән кыенлыклар өстенә авыл халкы арасында, балалар арасында сугыш китергән җәрәхәтләрне төзәтү өстендә эшли.

Фронтта күрсәткән батырлыклары өчен дәүләт аны орденнар, медальләр белән бүләкли, ә хезмәттә күрсәткән фидакарь хезмәте, балаларны коммунистик рухта тәрбияләгәне өчен хөкүмәтебез аны Хезмәт Кызыл Байрагы һәм Ленин орденнары белән бүләкли.

**Гәрәев Мансур Гәрәевич.** 1932 нче елның августында Мәскәү балалар йортында тәрбияләнгән Гәрәев Мансур Гәрәевичны колхоз яшьләр мәктәбенең директоры итеп билгелиләр. Ул тарих, география фәннәрен укыта. Энергияле, инициативалы кеше буларак, укытучылар коллективы һәм авыл халкы арасында үзен оста оештыручы кеше итеп таныта. Төрле авыллардан килеп укучылар өчен интернат төзетә, гомуми туклану өчен мәктәп участокларын һәм хуҗалыгын барлыкка китерә. Уку әсбапларын табу кыенлыкларын үз



җилкәсендә татый, мәктәптә тулы йөреш, өлгереш һәм тәртип булдыру өчен барлык көчен куеп эшли һәм яхшы нәтиҗәгә ирешә.
Мәктәп эше белән беррәттән, авыл халкы һәм яшьләре арасында армый-талмый, көн-төн көч куеп эшләргә туры килә, чөнки авылда колхозларның яңа гына оешып килгән чагы була, массаларга аңлашу эшләре, аңа һәм аның җитәкчелегендәге укытучылар коллективына төшә. Шушы вакыттагы сәяси компанияләрне һәм авылдагы кимчелекләрне тәнкыйтьләп пьессалар язды һәм үзе катнашында сәхнәгә куелды, бу бик зур агитация иде. Авыл яшьләрен культура хезмәте күрсәтүгә оештырды, авыл яшьләренең дусты, комсомол һәм колхоз поручениеләрен үти иде.
1936 нчы елдан очучыларның хәрби училищесына укырга алалар, училищены яхшыга гына тәмамлап, летчик-истребитель исеме ала, бу хезмәтендә дә үзен сынатмый, ләкин 1939 нчы елны Көнбатыш Белоруссияне азат иткәндә геройларча һәлак була. Аның тормыш иптәше Валентина ирсез һәм улы Рим атасыз калалар.



**Батыршин Хәсән Шәехович.** 1932 нче елны хезмәт, җәмгыять белеме укытучысы булып Алабуга педагогик техникумын тәмамлаганнан соң килеп тарих фәнен укыта. Беренче педагогик адымын ясаган яшь, тәҗрибәсез укытучыга эшләү һәм җәмәгать эшләрен башкару авырга килә. Күргәзмә ярдәмлек материаллар булмаса да, дәресне эчтәлекле, күңелле үткәрүе белән балалар арасында зур авторитет казана. Гәрәев Мансур белән берлектә яшьләр арасында тәрбия, политик эшләр алар җилкәсенә төшә, комсомол оешмасы белән берлектә комсомол эшенең эшен җанландыру, яшь комсомолецлар туплау, алар белән тәрбия эшләре, авылда булган искелек калдыклары белән көрәшү дә алар өстенә төшә.

1935 нче елдан Казан педагогия институтына студент итеп кабул ителә. 1938 нче елдан 1940 нчы елга кадәр Чаллы районы Князово авылында укытучы булып эшли. 1940 нчы елның 20 нче июнендә Кызыл Армия сафларына кабул ителә, 1941 нче елдан 1945 нче елга кадәр Бөек Ватан сугышында катнаша, геройлыклары өчен дәүләтнең 7 орден һәм медальләре белән бүләкләнә.

1946 нчы елдан Чаллы районы Князово урта мәктәбендә директор булып эшли. 1964 нче елда балаларга коммунистик тәрбия бирүдә, мәктәп коллективын оештыруда, авыл халкына идея-политик тәрбия бирүдә күрсәткән хезмәтләре өчен хөкүмәтебез тарафыннан аңа Татарстанның атказанган укытучысы исеме бирелә.

**Мөсифуллина Әминә Әкмәлетдиновна, Закирова Мәхмүдә Закировна.**



Мөсифуллина Әминә 1932 нче елдан химия, биология укытучысы булып килә. Яшь кыз булуына карамастан, дәресләрне кызык итеп, эчтәлекле, җәлеп итәрлек оештыру белү ягыннан укутучылар арасында зур авторитет казана. Оста гармунчы һәм җырчы буларак, балаларда сәнгатькә мәхәббәт тәрбияләүдә зур өлеш кертә, күргәзмә ярдәмлекләрне бик кыенлык белән булса да таба, булмаганнарын кулдан ясый. Үзешчән сәнгать түгәрәге оештырып укучыларны сәхнәгә бастыра, комсомолка буларак, авыл яшьләрендә дә сәнгатькә мәхәббәт тәрбияли.

1937 нче елдан Казан педагогия институтына укырга китә, аны тәмамлаганнан соң Кукмара районында мәктәп директоры һәм укытучы булып эшли.

Закирова Мәхмүдә 1939 нчы елдан Девятерня мәктәбенә татар теле укытучысы булып килә. Тел-әдәбият укытучысы буларак, туган телгә мәхәббәт тәрбияли, комсомолка буларак, мәктәп балалары һәм авыл яшьләре арасында зур эш алып бара, җырчылар түгәрәге оештыра, агитатор буларак, сәяси компанияләрне, хөкүмәт карарларын халыкка җиткерүдә зур хезмәт башкара.



**Класс житәкчесе Тухбатуллина Нәсимә, мәктәп директоры Гараев Мансур, завуч Тулбаев Бәдыйк бишенче класс укучылары арасында.**
**1936 нчы ел.**

1942-1946 нчы елларда Кадыбаш сигезьеллык мәктәбендә шул ук фәннәрне, 1946 нчы елдан 1959 нчы елга кадәр Исәнбай уньеллык мәктәбендә укыта, укыткан вакытта читтән торып педагогик институтны бетерә. 1960 нчы елдан 1970 нче елга кадәр Комсомолка поселогында башлангыч класс укытучысы һәм башлангыч мәктәпнең мөдире булып эшли. Мөдир, укытучы, агитатор буларак, төрле милләт вәкилләреннән торган Комсомолка поселогында күпкырлы тәрбия алып бару аның өстендә төшә.



**Төхвәтуллина Нәсимә Закировна.**

1935 нче елдан Девятерня җидееллык мәктәбенә укытучы булып килә, үзенең ягымлы карашы, тәмле теле белән укытучылар коллективы һәм балалар арасында бик тиз танылa, җәмәгать эшләренә бик нык бирелгән була. Авыр елларда аны, хатын-кыз булса да, сәләтле икәнен белеп, авыл Советына председатель итеп сайлыйлар, авыр сугыш елларында картлар, бала-чагалар хезмәтенә нигезләнгән хуҗалык эшләрен оештыру, алып бару гаять авыр була. Авыл Советы өстенә төшкән йөкләмәләрне гадәттән тыш авыр шартларда үтәргә туры килә, шулай да авыл Советын алдынгылар рәтенә бастыра, халыкның материаль көнкүреш дәрәҗәсен үстерүгә зур көч куя. Чиксез авырлыклар сәламәтлеген какшатып, авыруы аны вакытсыз якты дөньядан алып китә.



**Тукманова Зәйтүнә Рәхмәтулловна.**

1933 нче елны Минзәлә педучилищесын тәмамлап, туган авылы Исәнбайга башлангыч класс укытучысы булып кайта. 1942 нче елны Девятерня җидееллык мәктәбенә укытучы итеп күчерелә. 1944 нче елдан 1948 нче елга кадәр мәктәп директоры һәм география укытучысы булып эшли. Мәктәптәге авыр тормышны сөйләп бетерерлек түгел. Сугыш. Авылны фәкыйрьләндергән, балалар ялангач, ач, уку әсбаплары юк, йөреш начар, өлгерешне әйтәсе дә юк. Шушы хәлдә балаларга белем-тәрбия бирү, коллективны оештыру, мәктәп хуҗалыгын юлга салу аның өстенә төште, бик зур кыенлыклар белән йөреш, өлгереш нормаль хәлгә китерелде.

1948 нче елдан 1950 нче елга кадәр госпитальдә дәвалана, 1950 нче елдан 1958 нче елга кадәр Девятерня мәктәбендә укытучы булып эшли, 1958 нче елдан 1965 нче елга кадәр Алга башлангыч мәктәбендә мөдир һәм укытучы булып, ә 1965 нче елдан 1970 нче елга кадәр Нарат башлангыч мәктәбендә укытучы һәм мөдир булып эшли. 1970 нче елдан лаеклы ялга чыга. Лаеклы ялга чыккач та әле 1971 нче елда Девятерня мәктәбенең озынайтылган көн группасында тәрбияче булып эшли. 1945 нче елдан партия члены буларак, җәмәгать эшләрендә бөтен иңе белән йөзә. Партгруппаларда җитәкче, партоешмаларда секретарь, агитколлектив җитәкчесе, контроль комиссиясе члены, агитатор, атеистик пропаганда советы председателе хезмәтләрен башкарды. Аның күпкырлы хезмәтләрен искә алып хөкүмәт күп кенә медальләр һәм грамоталар белән бүләкли. Өлкән коммунист пенсиядә чагында да җәмәгать эшләре алып бара, магазиннарда лавочная комиссия члены, авыл советы каршында оештырылган контроль комиссия члены вазифаларын башкара.



**Ганиева Зәйтүнә Абдулловна.**

Сугыш. 1941 нче елны ике баласы белән, тормышын калдырып, эвакуацияләнеп Девятерня сигезьеллык мәктәбенә татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып кайта. Ике баласы белән кияргә киеме, ашарына булмаган, торырга йорты булмаган килеш килеп төшә. Безнең илдә кеше кеше өчен кайгырта, бу гаиләне Девятерня халкы җылы каршылап кочагына ала. Кыю, ихтыяр көчле, энергияле педагог авырлыкларга каршы башын югары күтәреп, бөтен көчен, белемен, сәләтен куеп, балаларга коммунистик тәрбия бирү өлкәсендә армый-талмый эшли. Мәктәптә балаларда тел һәм әдәбиятка мәхәббәт тәрбияли, грамотага өйрәтә. 1950 нче елдан 1955 нче елга кадәр һәм 1961 нче елдан 1962 нче елга кадәр мәктәпнең завучы булып эшли.

Мәктәпкә килгән ул вакыттагы яшь, тәҗрибәсе булмаган укытучыларны бик теләп белем нигезләрен өйрәтү буенча методика белән таныштыра. Укучылар арасында татар әдәбиятын пропагандалау буенча күргәзмә ярдәмлекләр эшләде, уку сыйфатын күтәрү өстендә яңалыклар барлыкка китерде. Агитатор буларак, авыл Советы, колхоз, профсоюз оешмасы тарафыннан җиткерелгән эшләрне массага пропагандалау эшләрендә актив катнашты. Үткен сатирик чыгышлары белән хатын-кызларның хокукларын яклауда бөтен көчен куйды, аның тарафыннан сөйләнгән эчтәлекле лекцияләр тыңлаучылар тарафыннан җылы каршыланды. Аның хезмәтен искә алып хөкүмәтебез аны күп кенә медальләр һәм грамоталар белән бүләкләде.



**Җәмилева Зәйнәп.**
Алексеевск районының Көрнәле авылында 1900 нче елның 25 нче январендә туа. 17 яшендә Казанда укытучылыкка укып, зурлар арасында укытып йөри. 1919 нчы елда яңадан Бубыйда курсларда булып кайта. Соңыннан ул гаиләсе белән безнең якларга кайта. 1927-1929 нчы уку елларында Девятерня башлангыч мәктәбендә 2 нче класслар белән эшли башлый. 1933 нче елда яңадан белемен күтәрү өчен Алабугага курсларга китә. Ләкин Зәйнәп апа үзенең яраткан эшен башкача дәвам итә алмый, авыруы сәбәпле эшен ташларга мәҗбүр була.

**Казанцева Зөһрә.** 1897 нче елда Иж-Бубыйда туа. Зәйнәп апа белән бергәләп башлангыч классларда укыта. Ул Нариман исемендәге колхозны төзүдә катнашкан активистларның берсе була. Девятерня мәктәбенә эшкә килгәнче Камай авылы балалар йортында эшли, ә калган 20 ел укытучылык хезмәтен Девятерня мәктәбенә багышлый.

Шушы ук елларда **Әбләева Хәнифә апа, Гайфуллин Вәли, Мухаметшин Ясави, Муратаев Сахиб абый**ларның да Алабуга техникумын тәмамлап, Девятерня мәктәбендә укытулары билгеле.

Мәктәбебезнең беренче укытучылары турында мәгълүматлар ветеран укытучы Айдарова Мәүгыйдә Хәйдәр кызы тарафыннан 1974 нче елда төзелгән "Алар бездә укыттылар" исемле альбомнан алынды. Башка ветеран укытучыларның хезмәте һәм тормышы турында материаллар мәктәп тарихына аерым теркәләчәк махсус төзелгән папка-альбомнарда саклана.



*Класс җитәкчесе Тухбатуллина Нәсимә, мәктәп директоры Гараев Мансур, завуч Тулбаев Бәдыйк бишенче класс укучылары арасында.*

Мәктәп тормышында беренче көннәреннән үк укучылар үзидарә органнары-учкомнар зур роль уйнаганнар. Аның беренче председателе булып Шакиров Фәһем сайланган. Шулай ук җидееллык мәктәптә беренче елны ук укучылар пионер оешмасы эшли башлый. 1934 нче елны алырның иң лаеклыларын комсомол оешмасы сафына кабул итәләр. Аларның мәктәп байрагы астында төшкән фотолары мәктәпнең 40 еллык юбилеена багышлап төзелгән альбомда саклана. Алар:

Закиров Әнвәр,

Закиров Муллаян,
Юсупов Хөсәен,
Айтуганов Нәкыйп,
Абдуллин Сәләхи,
Гайнуллина Фатыйма,
Шәйхетдинова Галия,
Исхакова Минеһода,
Закирова Рәхимә,
Айтуганов Ягъсуп,
Мингазов Җәвит,
Айдарова Мәүгыйдә,
Садыйков Касыйм,
Садыйкова Зәйтүнә.



*1934 нче елның 17 нче июне. Мәктәптә беренче мәртәбә пионер сафыннан комсомол сафына күчерелгән укучылар мәктәп байрагы астында.Закиров Әнвәр (байрак тоткан), арткы рәттә - Закиров Муллаян, Юсупов Хөсәен, Айтуганов Нәкыйп; урта рәттә утырганнар – Гайнуллина Фатыйма, Шайхетдинова Галия, Исхакова Минеһода, Бакирова Рәхимә, алгы рәттә - Айтуганов Ягъсуп, Мингазов Җәвит.*

1935 нче елда беренче чыгарылыш, 1936 нчы елда икенче чыгарылыш укучылар җидееллык мәктәпне тәмамлыйлар. Бу укучылар арасында укытучылар, хәрби кешеләр (полковник дәрәҗәсен алучы да бар), завод директоры урынбасары, сәүдә эшчеләре, бухгалтерлар, партия эшчеләре, хезмәт алдынгылары бар.

Уку елын яхшы билгеләренә тәмамлаган укучылар уку елы ахырында уңай яктан билгеләп үтелгәннәр, төрле шәһәрләргә экскурсияләргә барганнар. Мәсәлән, 1934-35 нче уку елында 7 нче классны яхшы билгеләренә тәмамлаган укучылар укытучы Тулбаев Бәдыйк һәм Батыршин Хәсәннәр җитәкчелегендә Казан шәһәренә экскурсиягә алып барылалар. (Фото).



*1934-1935 нче уку елында VII классны иң яхшы билгеләренә генә тәмамлаган укучылар укытучылар Тулбаев һәм Батыршиннар җитәкчелегендә Казан шәһәренә экскурсиягә алып барылалар. Сулдан уңга утырганнар: 1. Закирова Мәхмүдә (соңнан Нарат мәктәбендә укытты), 2. Тулбаев Бәдыйк (мәктәп директоры), 3. Батыршин Хәсән (завуч), 4. Авзалова Мәрфуга, 2 рәт 1. Нәбиуллина Факия (Девятерняда фельдшер булып эшләде), 2. Абдуллина Мәрьям, 3. Якупова Кәримә, арткы рәттә 1. Валиуллин Назил, 2. Ибатуллин Сәхәби , 3. ? Мәсгут, 4. ? Гариф, 5. Закиров Әнвәр (Асфан абыйның туганы), 6. Айдарова Мәүгидә (гомер буе укытучы булып эшләде, минем яраткан укытучы), 7. Садыйкова Зәйтүнә (Садыйков Робертның апасы).*

Мәктәптә ныклы дисциплина урнаштырыла. Укучылар арасында йөреш, өлгереш, тәртип яхшы була. Шул ук вакытта мәктәп балалары уку әсбаплары белән тәэмин ителәләр.

Башка авыллардан йөреп укучылар өчен мәктәп яны интернаты төзелә, гомуми туклану өчен мәктәп участогы хуҗалыгы барлыкка китерелә. Шулай ук мәктәп хуҗалыгында 3 ат, 3-4 сыер булдырыла, 7 га чәчүлек җире, ашханәдә барлык укучыларны кайнар аш белән тәэмин итү оештырыла. Башка авыллардан килеп укучылар исә көнгә 3 тапкыр кайнар аш белән тәэмин ителәләр. Мәктәп яны участогында балаларга ашату өчен яшелчәләр үстерелә, мәктәп территориясендә кое казыла. Суы йомшак, тәмле булганга яз айларында авыл кешеләре дә аннан чәй өчен дип су алганнар.

Мәктәпнең завхозы булып Фазлыев Габдулла эшләгән, аның хатыны Хәтимә апа техник хезмәткәр эшен алып барган. 1932-39 нчы елларда мәктәптә завхоз булып Загретдинов Сәхәби эшләгән.

Мәктәп укучылары Нариман исемендәге колхоз тормышында актив катнашалар, бик нык әзерләнеп экскурсияләр оештыралар. Экскурсия барышында терлекчелек турында лекцияләр әзерлиләр, терлекчелекне үстерүнең перспектив планы диаграммалары төзиләр, алдынгы терлекчеләр турында фотостенд төзиләр. Фермаларга элү өчен стена газеталары чыгаралар, лозунглар язалар.



*Девятерня җидееллык мәктәбе укучылары укытучылар җитәкчелегендә*
*Нариман исемендәге колхозның терлекчелек фермасына экскурсия вакытында.*

30 нчы елларда мәктәптә бик яхшы укыган аерым гаилә балаларыннан Айтугановларны искә алырга мөмкин. Алар:

   

Төрле елларда Нарат авылыннан килеп Девятерня мәктәбендә бик яхшы билгеләренә генә укыган сәләтле Айтугановлар гаиләсеннән 5 бала:

1. Айтуганов Ягъсуп 1936 нчы елда мәктәпне тәмамлый, соңнан сәүдә техникумында укый. Бөек Ватан сугышында һәлак була.
2. Айтуганов Нәкыйп – мәктәпнең беренче чыгарылыш укучысы, беренче укучылар комитеты (учком) секретаре. Бөек Ватан сугышында катнашып, орден-медальләр белән капитан званиесендә кайта, соңнан Карл Маркс исемендәге колхоз рәисе булып эшли. Нариман исемендәге колхоз белән кушылганнан соң колхозда һәм партия оешмасында төрле җаваплы урыннарда эшли.
3. Айтуганов Ләбиб мәктәпне тәмамлаганнан соң Казан педагогия институтында укый. Казанда радиокомитетта һәм башка җаваплы урыннарда эшли. Күп кенә көйләр, шигырьләр, сәхнә әсәрләре авторы. 2004 нче елда Девятерня урта гомумбелем бирү мәктәбенә Ләбиб Айтуганов исеме бирелә.
4. Айтуганова Әрибә - мәктәпнең иң яхшы укучысы була, күп еллар авыл советында секретарь, аннан соң Нарат китапханәсе мөдире булып эшли. Авылның һәм районның күренекле җәмәгать эшлеклесе.
5. Айтуганова Әдилә - шулай ук мәктәпнең иң яхшы укучысы, соңнан агроном, бакчачы, почта бүлекчәсе мөдире булып эшли.

Шулай ук Юсуповлар гаиләсе членнарын аерым билгеләп үтәргә мөмкин.



1



90 яшьлек Мәүгыйдә Хәйдәровна



2



3



4



5



6



7

1930 нчы еллар ахырында мәктәпне тәмамлаган алдынгы укучылар.

1. Айдарова Мәүгыйдә - беренче чыгарылышның алдынгы укучысы. 1940 нчы елдан башлап Девятерня мәктәбендә укытучы булып эшли. 90 яшьлек Мәүгыйдә Хәйдәровна хәзерге вакытта лаеклы ялда, ләкин һаман да мәктәп белән элемтәсен онытмый. Авылыбызның хөрмәтле һәм күренекле ветераны.

2. Айдаров Әдһәм мәктәпне 1936 нчы елда тәмамлый. Соңнан сәүдә уку йортында укый. Бөек Ватан сугышында катнашып капитан званиесендә кайта. Сугыштан соң күп еллар бухгалтер булып эшли.

3. Яппарова Һава һәм Закирова Зәкия мәктәпнең алдынгы укучылары. Яппарова Һава укытучы гаиләсендә туа, үзе дә Девятерня мәктәбендә 5 ел укытучы булып эшли.

4. Юсупов Хөсәен мәктәпнең беренче чыгарылыш (1935 ел) укучысы. Финанс техникумын тәмамлый, Бөек Ватан сугышында катнаша, лейтенант. Финанс институтында читтән торып укый, җаваплы партия һәм совет оешмаларында эшли. Күп еллар Ижевск шәһәрендә райфо мөдире булып эшли.

5. Юсупова Мөнҗия мәктәпне 1937 нче елда тәмамлый, бухгалтер булып эшли, соңнан Ижевскида яши.
6. Хазиев (Юсупов) Хәсән мәктәпне 1942 нче елда тәмамлый, күп еллар колхозда бухгалтер һәм бригадир булып эшли.
7. Юсупов Мәгъсүм бөтен фәннәрне дә бик яхшы үзләштерә. Комбайнер, соңнан колхозда алдынгы терлекчелек эшчесе.



*Элек бу йортта сөргенгә сөрелгән Бакыйр байның гаиләсе яшәгән. (Шакиров Рәхимҗанның әнисе Фәхерҗан, Фәтхетдинов Рәфис-Ринатларның әниләре Рәхиләләрнең нигез йорты), соңрак авыл советы бинасы, икенче катында төрле елларда башлангыч мәктәп тә урнашкан булган.*



*Сулдан уңга: Закирова Мөсәллия күп еллар бухгалтер булып эшли. Шакирова Җәмилә Казан заводларының берсендә квалификацияле мактаулы эшче. Фазлыев Рамим колхозның хисапчысы булып эшли. Абдуллина Лания Казан авыл хуҗалыгы институтын тәмамлый. Саттарова Галия сәүдә мәктәбендә укый, соңнан Казанда кибеттә эшли.*

Сугыш алды елларында илдә, шулай ук безнең төбәктә дә халык мәгарифенә игътибар кимеми. Девятерня авылында да, язылганча, гомуми җидееллык белем бирү гамәлгә керә. 40 нчы еллар башында мәктәптә пионерлар һәм укучылар арасында Аркадий Гайдарның “Тимур һәм аның командасы” исемле повесте йогынтысында тимурчылар хәрәкәте җәелеп китә.

1940 нчы елның башында аерым хөкүмәт Указы нигезендә (“СССРда дәүләт хезмәт резервлары турында”) һөнәр училищелары, ФЗО мәктәпләре ачу һәм яшьләрне һәр елны массакүләм эш һөнәрләренә өйрәтү өчен җыю башлана. Безнең авылдан да байтак яшьләр мондый һөнәр бирү мәктәпләрендә укып төрле һөнәрләр үзләштерәләр.

1939 нчы елның көзеннән ТАССР Югары Советы Президиумы Указы нигезендә татар әлифбасын рус графикасына – кириллицага күчерү башлана. Латиница нигезендә чыгарылган миллионнарча данә китапның укучысы калмый. Кириллицага күчү СССР территориясендә булган барча славян булмаган халыкларга (әрмәннәр һәм грузиннардан кала) кагыла. Сугыш алды елларында халыкның укымышлылык дәрәҗәсе 90,4 %ка күтәрелә.

Девятерня мәктәбендә сугышка кадәр, сугыш вакытында һәм аннан соңгы авыр елларда укытучы укытучылар турында хәзер инде үзләре өлкән яшькә җиткән элеккеге укучылар искиткеч әйбәт фикердә. Мәктәптә ул вакытта зур кыенлыкларга карамастан тәртип, чисталык, хезмәткә, белемгә омтылыш, дәресләрнең аңлаешлы итеп алып барылуы турында сөйлиләр. Аларның күңелләренә укытучы апаларының гади, килешле, матур киемнәре, матур итеп тарап үрелгән чәчләре, үзләрен искиткеч әдәпле, тыйнак тотулары тирән итеп уелып калган. Ир-ат укытучылар шулай ук таләпчән, хезмәт сөючән булулары белән аерылып торганнар, укучылар аларның тәмәке тартканын, хәмер эчкәннәрен күргәне булмаган.

**Даутов Мәхмүт Исмәгыйл улы**



Даутов Мәхмүт Исмәгыйл улы 1910 нчы елда Татарстан АССР Красный Бор районы Исәнбай авылында уртхәлле крестьян гаиләсендә туа. 1922-1926 нчы елларда Исәнбай башлангыч мәктәбендә белем ала. Мәхмүт Исмәгыйл улының хезмәт юлының башы илебез хуҗалыкларында бөек борылыш чорына туры килә.

Район комсомол оешмасы комсомолец Мәхмүтнең белемгә булган омтылышын күреп ала һәм 1932 нче елда аны Казанныңавтодорожный институт рабфагына укырга җибәрә. Рабфакта укыганда да техникадан аерылмый Мәхмүт: авылга кайткан беренче комбайн белән ашлык ура. 1934 нче елда рабфакта укуын тәмамлагач, Мәхмүт 1935 нче елның 1 нче сентябренә кадәр Чистай педагогик техникумында V-VII класс укытучы-ларын әзерли торган курсларда укый.

1935 нче елның 1 нче сентябрендә Даутов М.И. Девятерня җидееллык мәктәбенә география һәм тарих укытучысы булып эшкә билгеләнә. Ул бу мәктәптә 1937 нче елның 25 нче августына кадәр балалар укыта. Эшләү дәверендә Мәхмүт Исмәгыйл улы укучыларның, әти-әниләрнең һәм укытучыларның мәхәббәтен яулый, хөрмәт казана. Мәктәп дирекциясенең аның эшенә биргән бәяләмәсендә мондый сүзләр бар: “Даутов М.И. үзен актив һәм төгәл укытучы итеп танытты. Үз предметы буенча балаларга тирән белем бирә, география фәне буенча белем сыйфатын күтәрү өстендә тырышып эшли. Даутов шулай ук җәмәгать эшләрендә дә актив катнаша. Ул Девятерня тулы булмаган урта мәктәбендә укучылар арасында пионер отряды оештырды һәм пионерлар арасында коммунистик тәрбия бирү эшен ихлас башкара. Даутов М. 6 нчы класста класс җитәкчесе вазифасын башкара. Бу класс укучылары мәктәптә иң үрнәк укучылар булуга ирештеләр. Яхшы укулары, нык дисциплиналы булулары өчен 6 нчы класс укучыларын һәм аларның класс җитәкчесе Даутов М.И. берничә тапкыр премиягә лаек булдылар”.

Даутов Мәхмүт үзенең белемен күтәрү өстендә дә нык эшли. Ул читтән торып Алабуга педагогик институтын тәмамлый.

1937-1942 нче еллар – Даутов М.И. Исәнбай җидееллык мәктәбендә тарих, география укытучысы, 1942-1952 нче еллар – шул мәктәптә директор.

1940 нчы ел – Мәхмүт Исмәгыйл улы өчен аеруча истәлекле. Бу елны аны КПСС сафларына кабул итәләр, ә авыл коммунистлары Даутов М.И.ны тиздән партоешма секретаре итеп сайлыйлар. Хезмәт юлы партия эше белән тыгыз бәйләнеп китә. Исәнбайда сугышка кадәр урта мәктәп булмый. Иске каралтыларны бергә җыйнап, Мәхмүт Исмәгыйл улы җитәкчелегендә 1949 нчы елда урта мәктәп төзелә.

1952 нче елдан 1957 нче елга кадәр Мәхмүт Исмәгыйл улы Исәнбай урта мәктәбендә география укыта.

Сугыштан соң колхозларны эреләндерүнең әһәмиятен аңлап, районда беренчеләрдән булып, Мәхмүт Исмәгыйл улы җитәкчелегендә Исәнбайда яшәп килгән 4 колхоз бер колхоз итеп берләштерелә. Колхоз бригадалары комплекслы итеп төзеләләр. Авылда колхозларны берләштергәннән соң Фрунзе исемендәге колхозның партия оешмасының башка эшләрдән азат ителгән секретаре итеп 1957 нче елда Даутов М.И. сайлана.

1958-1960 нчы елларда Мәхмүт Исмәгыйл улы Исәнбай урта мәктәбендә география һәм табигать фәннәре укытучысы, ә 1960 нчы елда аны шул мәктәпнең партия оешмасы җитәкчесе һәм директорның тәрбия эшләре буенча урынбасары итеп билгелиләр.

1970 нче елда Даутов М.И. лаеклы ялга чыга. Ялда булуына карамастан ул җәмәгать эшләрендә актив катнаша. Мәхмүт Исмәгыйл улы ата-аналар комитеты, халык контроле группасы белән җитәкчелек итә.

Укыту-тәрбия һәм җәмәгать эшләрендә күрсәткән хезмәтләре өчен Даутов М.И. СССР Югары Советы Президиумы указы белән "Аеруча хезмәт күрсәткән өчен" медале белән бүләкләнә.

1981 нче елда Даутов М.И. вафат була. Ләкин аның хезмәтен хәзер дәвам итүчеләр бар. Ике кызы да үз эшләрендә хөрмәт казанган укытучылар, оныклары да бабалары юлын сайлаганнар. Димәк, династия дәвам итә.



*Нарат башлангыч мәктәбе укытучысы Закирова Галимә дусты Сәгыйрова Халидә белән. Алар 1940 нчы елларда Девятерня җидееллык мәктәбен тәмамлыйлар, мәктәпнең иң яхшы укучылары булалар.*

***<u>1932-1937 нче елларда Девятерня тулы булмаган урта мәктәбендә укыткан укытучылар:</u>***

1. Гәрәев Мансур – мәктәп директоры, тарих фәнен укыта.
2. Тулбаев Бәдыйк – 1940 нчы елларг кадәр эшли. Математика фәнен укыта.
3. Батыршин Хәсән – физика укыта. Соңнан Мөслим районында мәктәп директоры була.
4. Гәрәева (Гоголева) Валентина – рус теле укытучысы.
5. Даутов Мәхмүт – география, хезмәт укытучысы.
6. Мөсифуллин Әкмәлетдин – татар теле укытучысы.
7. Мөсифуллина Әминә - химия, биология укытучысы.
8. Мөсифуллин Фәтхерәхмән – җыр-музыка укытучысы.
9. Саттаров Мөхәммәт – немец теле укытучысы.
10. Садыйкова Саимә - физика, математика укытучысы.
11. Хәбибуллина Саимә - физика укытучысы.
12. Мухаметшин Ясави – хезмәт һәм җәмгыять белеме укытучысы.
13. Мөслимов Галимулла – башлангыч класслар укытучысы, Гали авылы.
14. Ямалиев Галимулла – рәсем, башлангыч класслар укытучысы.
15. Тулбаева Зифа – башлангыч класслар укытучысы.
16. Ямалиев Лотфулла – география, рәсем укытучысы. Соңнан Мәскәүдә эшли.
17. Галимов Газиз - башлангыч класс укытучысы
18. Тахирә (Фамилиясе билгесез) - башлангыч класс укытучысы
19. Гумеров Габдулла Габдрахман улы - башлангыч класс укытучысы
20. Закирова Мәхмүдә - башлангыч класс укытучысы
21. Казанцева Зөһрә - башлангыч класс укытучысы
22. Төхвәтуллина Нәсимә Закировна (читтән килгән) – биология укытучысы
23. Сәйфи абый – 4 класс укытучысы
24. Мәгъбүсә апа – башлангыч класс укытучысы
25. Мөнәвиров Гомәр – башлангыч класс укытучысы
26. Әсәдова Роза – башлангыч класс укытучысы
27. Садыйков Габделхак
28. Галимә (Фамилиясе билгесез)
29. Шәймәрданов Мәсгут – башлангыч класс укытучысы
30. Әмиров Габделхай
31. Әмирова Рәсимә
32. Әбләева Хәнифә
33. Муратаев Сахиб
34. Гайфуллин В.
35. Шәймәрданов Бәдретдин – башлангыч класс укытучысы
36. Зәкиев (Исеме билгесез)
37. Җәмилева Зәйнәп



*Фаррахов Сабир мәктәпне 1937 нче елда тәмамлый. Бөек Ватан сугышында катнаша, лейтенант. Авыл советы председателе булып, соңнан авыл кибетендә эшли. Хәзер лаеклы ялда. Авылыбызның күренекле, хөрмәтле ветераны.*

***Девятерня тулы булмаган урта мәктәбен 1935 нче елда укуны тәмамлаучылар:***

1. Айдарова Мәүгыйдә
2. Абдуллина Мәрьям
3. Шакиров Фәһем  (Девятерня учком рәисе)
4. Садыйков Касыйм
5. Садыйкова Зәйтүнә
6. Набиуллина Факия
7. Тухватуллин Котдус
8. Закиров Әнвәр
9. Мәрдәнов Мәсгут
10. Ситдикова Кәнҗимәхәр
11. Бакирова Рәхимә
12. Тазиева Факия
13. Кәлимуллан Касыйм (Касайдан)
14. Шаймарданов Рәүф (Нараттан)
15. Айтуганов Нәкыйп (Нараттан)
16. Мөхәмәтҗанова
17. Вәлиуллин Котдус
18. Якупова Зәйтүнә
19. Хафизва Кәримә
20. Каиров Юныс (Галидән)
21. Сундуков Зөфәр (Галидән)
22. Закирова Мәмдүдә (Нараттан)
23. Яппарова Мәрфуга (Нараттан)
24. Галиев Гани (Кадыбаштан)
25. Мусин Гариф (Кадыбаштан)
26. Ганиев Гариф (Кадыбаштан)
27. Шарипов Әнвәр



*Садыйков Касыйм мәктәпне 1935 нче елда тәмамлый, авыл советы секретаре булып эшли. Бөек Ватан сугышында катнаша, соңнан колхозда ревкомиссия члены булып тора.*

***Девятерня тулы булмаган урта мәктәбен 1936 нче елны укуны тәмамлаучылар:***

1. Хикматуллин Хаҗи
2. Садыйков Габделхак
3. Шәйхетдинов Мулламөхәмәт
4. Закиров Зәки
5. Айдаров Әдехәм
6. Абдуллин Сәләхетдин
7. Садыйкова Мөнҗия Мөхәмәтгәрәй кызы
8. Абдуллин Садыйк
9. Гайнуллина Фатыйма
10. Шәйхетдинова Талия
11. Бакиров Габденур
12. Бакиров Габдулла
13. Сабиров Мулланур (Нарат)
14. Сабиров Габдулла (Нарат)
15. Нәҗметдинов Галәетдин
16. Батыршин Сабир (Нарат)
17. Шәйхетдинова Фәхринур (Сләк)
18. Мөслимов Салих (Сләк)
19. Хәмәт
20. Низамов Рәхим
21. Гайсин Хәйдәр (Татарстан)
22. Якупова Махинур (Касай)
23. Кәримов Касыйм (Касай)
24. Нурулла (Касай)
25. Җәмилов Газим (Сләк)
26. Закиров Муллаян (Кадыбаш)
27. Гариф (Кадыбаш)
28. Низамов Гыйззәт
29. Минһаҗев Җәвит (Нарат)
30. Айтуганов Ягъсуп (Нарат)
31. Сөләйманова Мөнирә (Кадыбаш)
32. Яппарова Һава (Нарат)

***Девятерня тулы булмаган урта мәктәбен 1937 нче елны укуны тәмамлаучылар:***

1. Фаррахов Сабир
2. Гомәров Шамил
3. Казанцев Асаф
4. Фазлыев Мәгъсүм
5. Газизов Касыйм
6. Хисматуллина Әминә
7. Фассахов Мәхмүт
8. Садыйкова Мөнҗия Сәхәби кызы
9. Мухаметҗанова Зәкия
10. Валиева Зәкия
11. Хөснетдинова Гәйшә
12. Хисматуллин Хикматулла
13. Набиуллин Хәйдәр (Касай)
14. Низамов Гыйззәт (Касай)
15. Яппаров Мөшәвир (Кадыбаш)
16. Авзалов Зиннур (Кадыбаш)
17. Гайсин Сәгыйть (Кадыбаш)
18. Арсланова Сабира (Касай)
19. Якупова Маһинур (Касай)
20. Багавиев Габдулла (Нарат)
21. Мусин Минһаҗтин (Нарат)
22. Җәмилов Шамил (Сләк)
23. Галимов Габделхак (Сләк)
24. Мәндиев Галимулла (Үтәгән)
25. Ситдикова Әминә (Касай)
26. Нәҗип
27. Банат
28. Наилә

## 3 нче бүлек.
## Бөек Ватан сугышы елларында Девятерня авылы мәктәбе

Бөек Ватан сугышы үзенең утлы эзен көрәш мәйданнарында гына калдырмый. Тылда яшәүчеләр дә ул елларда бик зур авырлыклар, мохтаҗлыклар кичерәләр. Ир-егетләр, шулай ук укытучылар, мәктәп җитәкчеләре сугышка китәләр һәм күбесе геройларча һәлак була, әзләр генә исән калып, яраткан эшләрен дәвам итә алалар. Сугышта катнашучы күпчелек укытучылар батырлыклар күрсәтәләр һәм төрле орден һәм медальләр белән бүләкләнәләр. Татарстанга шул ук вакытта безнең якларга эвакуациягә эләккән кешеләр кайта башлый. Авылда яшәү шартлары көннән-көн авырлаша бара. Барлык авыр эшләр хатын-кызлар, картлар, балалар җилкәсенә төшә. Шундый авыр шартларда да авыл мәктәбе, укытучылар үз эшләрен туктатмыйлар. Мәктәптә балаларны ашату өчен барлык чаралар да күрелә, укытучыларда Ватанга мәхәббәт, совет сугышчыларының фидакарьлеге, ил язмышы өчен тирән җаваплылык хисе тәрбиялиләр. Укыту өчен китаплар, дәфтәрләр һәм башка кирәк-ярак җитми. Кышкы чорда мәктәпләргә йөрү өчен җылы киемнәр дә булмый. Шундый шартларда да укучыларның белемгә омтылышлары кимеми. Шуңа өстәп, өлкән класс укучыларына зурлар өчен колхозда эшләргә, хәрби-кыр төзелеш эшләрендә катнашырга, урман кисәргә, завод-фабрика өйрәнчекләре мәктәпләренә укырга барырга, яз көннәрендә Красный Борга чана тартып симәнә орлыгына барырга, көз көне яңа чабаталарын киеп, пычрак ерып, Каракүлгә ашлык тапшырырга барып, ач-ялангач гаиләләренә ярдәм итәргә туры килә. Шуның өстенә көн саен үлем хәбәрләре - этиләрен, ирләрен, сөеклеләрен югалту турында кара кәгазьләр килеп тора. Бераз өлкәнрәкләр агач мылтыклар тотып, сугыш эшенә өйрәнә, окоплар казыйлар. Аларны өйрәтүгә Нуриев Фатих һәм башка тәҗрибәлерәк кешеләр билгеләнә. Укытучылар да дәресләрдән соң төрле эшләргә тартылалар, идеологик эштә катнашалар, балалар белән күп төр хуҗалык эшләрен башкаралар, басудан башак җыялар... Балалар май ахырыннан 30 нчы сентябрьгә кадәр авылдагы барлык авыл хуҗалыгы эшләренә тартылалар.

Яшүсмерләр елына 50 хезмәт көне эшләргә тиеш булалар. Авыл балалары бик тиз олыгаялар, алар җир сукалыйлар, тырмалыйлар, печән чабалар, иген уралар, машина йөртәләр, көтү көтәләр. Көнне төнгә ялгап аларга басуга тирес чыгарырга, чүп утарга, терлек азыгы әзерләргә, игеннәрне урып җыярга булышырга туры килә. Хезмәткә түләү бик аз була. Сугыш елларында җан башына бирелгән ашлык һәм бәрәңге 3 тапкыр азая. Крестьян колхоздан көненә 200 г ашлык һәм 100 г бәрәңге ала. Кешеләр алабута, салам, үләннәр, чергән бәрәңге белән туклаланалар. Шуларның барын бергә кушып, бераз он, бәрәңге, түп өстәп, “икмәк” пешерәләр. Йорт янындагы шәхси хуҗалык яшәр өчен бераз ярдәм итә, ләкин аннан алган уңыш та колхозга дәүләт алдындагы йөкләмәләрне үтәүгә китә. Шәхси ярдәмче хуҗалыкны бик зур салым кыса. Утырткан бәрәңге, бакча җире, умарталар өчен дә салым түләргә туры килә, һәр баш терлеккә дә салым салына. Җитмәсә, хәрби салым, буйдаклар салымы һәм башка шундый өстәмә салымнар да түләргә туры килә. Мәсәлән, бездә булган иске архив документларыннан күренгәнчә, сугыштан соңгы елларда (сугыш елларындагы салымнар турында рәсми документлар юк, ул салымнар да күрсәтеләчәк мәгълүматлардан нык аерылмыйдыр дип фаразлыйбыз) Девятерня авылында яшәүче Губайдуллина Мәрьям хуҗалыгы елга авыл хуҗалыгы налогын 200 сум, ит 30 кг, сөт 110 л, йомырка 75 данә, сарык йоны 600 г, бәрәңге 140 кг күләмендә түләгән. Шулай итеп, сугыш елларында авыл халкы җилкәсенә зур авырлыклар төшә. Авыл халкына, шул исәптән балаларга, укытучыларга, хезмәткәрләргә ачлык, ялангачлык, төрле авырулар, караңгыдан караңгыга кадәр авыр хезмәт, кыскасы, барысын да татырга туры килә. Авыл халкының хезмәт батырлыгы фронтта һәм дошман тылында кулына корал тотып Ватанны саклаучылар батырлыгына тиң була. Фашизмны җиңү илебез белән бергә безнең авылга, авыл кешеләренә дә бик кыйммәткә төшә. Безнең авыл советы территориясеннән 482 кеше сугышка киткән, 291 кеше һәлак булган, 164 этинең 381 баласы ятим калган!!! (Девятерняда 156, Наратта 138, Галидә 87 бала)

Укытучылар, барлык авыл халкы оборона фондына акча, икмәк, ит, сөт, яшелчә, дәүләт займы облигацияләрен, кыйммәтле әйберләрен тапшыралар. Танк колонналары төзү өчен акча җыю, заемнарга язылу, яралыларга кан бирү, сугышчылар өчен җылы кием-салым җыю, фронтка

бәйрәм бүләкләре – посылкалар җибәрү – болар барсы да авыл кешеләре дә, укытучылар да актив катнашкан патриотик хәрәкәтнең төп формалары була.

Җитештерү өлкәсендә эшләү, матди җитешсезлек, кием-салым булмау аркасында балаларның бер өлеше укырга йөри алмый. Ә шулай да гомуми мәҗбүри белем турындагы законнарны үтәү өчен төрле чаралар күрелә, ач-ялангач, ятим балаларга укырга йөри алсын өчен ярдәм оештырыла. Мәктәп яны участоклары һәм терлекчелек хуҗалыклары укучыларны тукландыруда таяныч була.

Сугыш елларында (1943 нче ел) башлангыч һәм җидееллык мәктәпләрне тәмамлаучылар өчен чыгарылыш имтиханнары кертелә, укудагы уңышлар өчен алтын һәм көмеш медальләр белән бүләкләү оештырыла башлый. Мәктәп укытучылар үз алларына куелган бурычны намус белән үтиләр.



*Краснобор районы Девятерня ТБУМнда эшләгәндә алынган рәсем. 1944ел 5 июнь. Уңнан сулга :*

1. *Маннапова Рәхимә (директор)*
2. *Садыков Габдулла 9 (военрук)*
3. *Уртада Гатауллина Хәдичә (4 кл. укытучысы)*

1948 нче елдан башлап Девятерня мәктәбендә рус теле укыткан, соңрак китапханәдә эшләгән һәм 41 еллык педагогик стажы булган Абдуллина Әлфия Фатыйх кызы шулай ук ирләр белән беррәттән 1942 нче елдан башлап сугыш тәмамланганчыга кадәр 3 ел да 8 ай солдат хезмәтен үти, фронтовик була.

***<u>Бөек Ватан сугышы елларында һәм сугыштан соңгы елларда укыткан укытучылар</u>***

1. Тукманова Зәйтүнә - мәктәп директоры
2. Маннапова Рәхимә -мәктәп директоры
3. Ганиева Зәйтүнә
4. Хикматуллин Хаҗи
5. Фаррахов Сабир
6. Исхаков Зәкәрия
7. Әминова Мөкәрәмә
8. Закирова Нәсимә
9. Нәҗипова Гөлҗиһан
10. Җәмилова Сания
11. Айдарова Мәүгыйдә
12. Шарифуллин Габдулла – 1947 елдан мәктәп директоры (17 ел)
13. Абдуллина Әлфия
14. Яппарова Һава

15. Яппарова Сания
16. Җәмилова Гамбәрия
17. Муллахмәтова Шаһидә
18. Әминов Габделхак – рус теле укытучысы, соңнан Алабуга пединституты ректоры
19. Әминова Рәсимә - башлангыч класс укытучысы
20. Зәкиев Габделхай
21. Кураев
22. Вахитов Габдрахман
23. Тазиев Мулламөхәмәт – 1951-1955, 1968-1977 елларда
24. Тухбатуллин Салих – Гали
25. Ямалиев Габдрахман – Касай
26. Мазитова Фәһимә
27. Гөлчирә - Әгерҗедә
28. Ахметова Галимә Миннәхмәт кызы (Камаева Клара апаның әнисе)
29. Латыйпова Хәдисә (Алабугадан килеп укыта)

## 4 нче бүлек.
## Сугыштан соң авыл һәм Девятерня мәктәбе
## (1947 – 1964 елларда мәктәп директоры булып Шарифуллин Габдулла Шарифулла улы эшли).



Сугыш башлангач, Девятерня авылыннан күп кенә ир-атлар исән әйләнеп кайтырбыз дип фронтка китәләр. Әмма дәһшәтле сугыш күпләрнең гомерен өзә. Алар яу кырында батырларча һәлак булалар. Сугыш кырында ятып калганнар кайгысы күпләрнең йөрәк түреннән китми. Ә шулай да Җиңү тормышның яхшырачагына өмет, ышаныч бирә.

Сугыштан соңгы беренче еллар авылга яңа авырлыклар алып килә. 1946-1948 нче елларда барлык районнар диярлек корылыкка дучар була, авылларда ачлык башлана. Дәүләт булган барлык ашлыкны тапшырырга мәҗбүр итә һәм хәтта чәчүлек орлыгы да калмый. Сугышта үлүчеләр күп булганлыктан, авылда эшче көчләр җитми. Күп эшләр хатын-кызлар, балалар тарафыннан башкарыла. Ачлы-туклы яшәгән һәм булган мөмкинлекләрдән дә файдаланудан мәхрүм ителгән авыл халкы (электр энергиясен файдалана алмый, хезмәт хакы түләнми һ.б) мөмкинлек туу белән әкренләп авылдан шәһәргә китә башлый. Бу бигрәк тә яшьләргә кагыла. Алар үз максатларына ирешү өчен төрле юллар табарга тырышалар.

Бу чорда мәктәпләр дә авыр хәлдә яши. Аларны ремонтлау өчен акча бирелми, яңалары төзелми. Шулай булуга карамастан, 40нчы еллар ахырына гомуми мәҗбүри җидееллык белем алу кертелә.




1950нче еллар ахырына авыл мәктәпләренә дәүләт булышуы арта. Мәктәпнең материаль – техник базасын ныгытырга мөмкинлек туа. Мәктәп укыту әсбаплары, укыту-методик ярдәмлекләр белән баетыла, укытучы кадрлар составы яхшыртыла бара.

1953 нче елдан, төгәлрәк әйткәндә, Сталин вафатыннан соң, илебез тарихында яңа чор башлана һәм ул 11 ел дәвам итә. Бу елларда илебездә шактый зур үзгәрешләр күзәтелә: тормышның күп өлкәләрендә реформалар үткәрелә, индустриаль тармаклар (Татарстанда нефть промышленносте) тиз үсә, Репрессия – җәза органнарының бабаштаклыгы туктатыла.

Н.С.Хрущев инициативасы белән 1953-1957нче елларда уздырылган реформалар нәтиҗәсендә илнең авыл хуҗалыгы моңа кадәр яшәп килгән кризис хәленнән чыга. Авыл хуҗалыгы продукциясен сатып алу бәяләре күтәрелә, мәҗбүри авыл хуҗалыгы продукцияләре тапшыру нормалары киметелә, колхозларда җитештерү күрсәткечләре арта, ашлык җитештерү механикалаштырыла. Авыл хуҗалыгы салымы 3 тапкыр азая, шәхси хуҗалыклардан мәҗбүри тапшырулар нормасы кими. Авылның социаль үсешендә уңай күренешләр күренә башлый. Илдә Хрущев "җепшетүе" (оттепель) башлангач, аның нәтиҗәсендә илебездә, шул ук вакытта безнең төбәктә дә үзгәртүләр була. Н.С.Хрущев идарә итү чорында крестьяннарның, авыл халкының "якты коммунистик киләчәк" төзү өчен каршылык тудыручы хосусый милекне азат итү кампаниясе башлана. Авыл кешеләренең йорт яны хуҗалыклары мәйданын кисәләр, терлек санын кыскарталар, печән һәм терлек азыгы әзерләргә ирек бирмиләр. Укытучы гаиләләренә шәхси тормышларын алып бару тагын да катлаулана, җир мәйданы, терлек тотуны кыскарту бара. Урынсыз барлык җирдә кукуруз белән мавыгу, колхозларны эреләндерү дә авыл кешеләренә уңай йогынты ясамый.

1958 нче елда илдә сигезьеллык мәҗбүри белем бирү кертелә. Безнең мәктәптә ул 1962 – 1963 уку елыннан көченә керә.

1960 нчы елның октябрендә Красный Бор районы бетерелә һәм аның территориясе Әгерҗе районына кертелә.

1960 нчы ел башында Татарстанда, шулай ук Девятерня мәктәбендә дә фәнни, мәдәни мәгърифәтчелек оешмалары: "Белем җәмгыяте", "Педагогия җәмгыяте", "Һәйкәлләрне саклау", "Табигать сөючеләр" җәмгыятьләре эшли башлый. Шул чор укытучылары үзләренең балаларга игътибарлы, кешелекле, ярдәмчел булулары белән аерылып торалар. Еш кына аларга һәр класста 25әр бала укытырга туры килгән. Алар бервакытта да зарланмаганнар, сыгылып төшмәгәннәр, үз эшләренең осталары булганнар.

1963 елда Алабуга территорияле районы барлыкка килеп Әгерҗе һәм Менделеевск районнарын да анда кушу шулай ук авыл кешеләрен укытучыларга да өстәмә кыенлыклар тудыра. Юл, транспорт, телефон элемтәсе булмаган чорда һәрбер эш буенча ерактагы район үзәге Алабугага барып кайту, билгеле, эшне тагын да авырлаштыра.

Шулай да 60 нчы еллар башы илебез өчен үзенчәлекле, кызыклы чор. Кешенең космоска очуы, Татарстанның кызу тизлек (темп) белән үсүе, нефть табылу, промышленностьның башка тармаклары кызу тизлек белән үсүе һәркайда белемле кешеләр кирәклеген күрсәтә. Яшьләр белемгә омтыла, уку йортлары, мәктәпләр үсә, шул ук вакытта безнең мәктәп тә ныгый, уку әсбаплары, материаль тәэмин ителеш яхшыра.

Шул чор укытучылары үзләренең балаларга искиткеч игътибарлы, кешелекле, ярдәмчел булулары белән аерылып торалар. Еш кына аларга һәр класста 25әр бала булган классларны кушып икешәр смена укытырга туры килгән, ләкин алар бервакытта да зарланмаганнар, сыгылып та төшмәгәннәр, үз эшләренең осталары булганнар, аларның искиткеч дәрес бирү осталыгы күп кенә хәзерге укытучыларга эталон хезмәтен үтәр иде кебек тоела. Уникаль профессиональ педагогик тәҗрибә туплана.

Ул чорларда эшләгән укытучылар турында авыл халкы, белем алып чыккан укучылар тирән хөрмәт белән искә алалар, мәсәлән мәктәпнең элеккеге иң актив һәм көчле укучысы, шул елларда иң авторитетлы оешма учком рәисе булып эшләгән, хәзерге вакытта абруйлы ветеран педагог Мәдинә Гатауллина (Калимуллина, 1952-1959 елларда укыган) һәм аның апасы Гатауллина Вәсимә апалар үз истәлекләрендә бик җылы сүзләр язалар:

"...Без һәрвакыт бала чактагы укытучыларыбызны искә алабыз. Алар безнең күңелдән бер дә китмиләр. Менә алар - Әгерҗе районының Девятерня җидееллык мәктәбенең күңелебездә җылы урын алган укытучылары: башлангыч класста укыткан Зәйтүнә апа Җәләлова һәм Җәмилова Сания апалар, татар теле һәм әдәбияты укытучысы Зәйтүнә апа Ганиева, химия-биология укытучысы Хаҗи абый Хикмәтуллин, математика, сызымнан Айдарова Мәугыйдә апа, физикадан Вахитов Габдрахман абый, немец теленнән Вагапова Наилә апа, физкультурадан Арсланов Зиннур абый, рус теле һәм әдәбияты укытучысы Әлфия апа Абдуллина, мәктәбебез директоры һәм география укытучысы Габдулла абый Шәрифуллин... Мин, еллар үткән саен, бу укытучыларның чын мәгънәсендә мөгаллим һәм мөгаллимә булуларына сокланам, аларга чын күңелдән рәхмәт укыйм.

Болар искиткеч мөгаллимнәр, аларның тырыш, намуслы хезмәтен еллар үткән саен тирәнрәк аңлыйсың икән.

Габдулла абыйның география дәресләре, викториналары, карта янында оештырган төрле уеннары күз алдыннан китми. Мин, мәсәлән, бүген дә картаны бик яхшы беләм икән, моның белән Габдулла абыйга бурычлы. Миңа һәр дәрестә карта янына баскан саен күз алдыма укытучым килеп баса һәм дәрес саен мин аңа эчемнән генә рәхмәт әйтәм. Укучыларыма да картаны өйрәткән вакытта укытучым турында сөйлим, аның ысулларын кулланам.

Трибуна артына чыгыш ясарга басам икән, мин директорыма рәхмәтле, чөнки ул мине 6 һәм 7 нче классларда ук җыелышлар алып барырга, чыгышлар ясарга өйрәтте. Хәтта ул миңа ата-аналар белән укучыларның берләштерелгән җыелышын алып баруны ышанып тапшыра, янымда торып ярдәм итә иде. Ул вакытта мин укучылар комитеты рәисе идем. Моның белән ул миндә һәм барлык балаларда мөстәкыйльлек тәрбияләгән, киләчәккә әзерләгән.

Күп мондый мисаллар. Габдулла абый искиткеч оста рәссам булып, ул ясаган портретлар мәктәп коридорларын бизәп торалар иде.

Безнең буын укучыларының телләрне яхшы белүләре һәм язуларының матур булулары белән барыбыз да укытучыларга бурычлы. Искиткеч тырыш, гадел, чиста, пөхтә, тыйнак, зәвык белән генә киенеп йөрүче, авыл халкы арасында ихтирамга лаек бу укытучы апалар, нинди генә авырлыклар күрүгә карамастан, күтәренке рух белән, балаларынн киңәшче һәм таяныч булып, булганына шөкрана кылып, матур итеп яшәделәр.” Шулай ук 1949-1956 елларда безнең мәктәптә бик яхшы билгеләренә генә укыган, 55 ел Омск шәһәрендә яшәп 27 ел милициядә (соңрак полиция) эшләгән Муллахметова Рәйсә апа да шул чор укытучылары турында искиткеч җылы фикердә, үзенең язмаларында аларның хезмәтен изгеләштереп сурәтли.

Ул чорда авыл балалары кечкенәдән үк хезмәт белән тәрбияләнеп үскәннәр. Өйдә һәр баланың үз вазифасы булган: терлек карау, су ташу, ишек алдын тәртиптә тоту, кечкенә эне-сеңелләрне тәрбияләү, ашату-киендерү, үсә төшкәч, колхозга булышу. Икмәк үстерсә дә, авыл халкы ачлыктан интегә. Урласаң, төрмәгә ябалар. Сугыш һәм сугыштан соңгы елларда авылда утын иң зур проблемаларның берсе була. Урман ягында яшәсәк тә, кешеләр, балалар да кыш көне салкыннан интегә. Ул вакыт тәртипләре буенча урманда агач кисү тыела. Мәктәптә һәм өйдә салкын булу сәбәпле яза торган каралар ката. Ул вакыт укучылары металл каралар белән кара (буяу) савытындагы кара буяуга манып язганнар. Андый перо ярдәмендә язылган линияләрнең (хәрефләрнең) киңлеген үзгәртеп булган һәм укытучылар һәр укучыдан матур каллиграфик почерк (язу) таләп иткәннәр. Еш кына кара перодан кирәкмәгән урынга тамып язуны пычрата иде, ә инде 60 нчы елларда шариклы ручкалар барлыкка килгәч, караның таму куркынычы бетсә дә, перолар белән бергә каллиграфия фәне дә тулысынча диярлек юкка чыкты. Укучылар дәфтәр урынына кирәкмәгән китаплар һәм газеталар кулланалар.

Мәктәпне уңышлы бетергән күп кенә укучылар үз тормышларын алга таба да мәктәп белән бәйлиләр һәм укуларын педагогия уку йортларында дәвам итәләр. Укытучы һөнәре сугыштан соң елларда абруйлы булып торган. Безнең Тугызбуй ягы өчен иң якын уку йортыннан Минзәлә педагогия училищесы булган. Шуңа күрәдер авылыбыздан күпләр шунда белем алган. Алар арсында Зарипова Рәшидә, Саттарова Мөнәзәхә, Җәлилова Сания, Тухватуллина Саймә, Закирова Галимә, Җәлилова Зәйтүнә, Тукманова Зәйтүнә, Маннапова Рәхимә апалар һ.б бар.



*Красный Бор районы укытучылары 1960 елның 6 июненнән 2 июленә кадәр булган укытучыларның белемнәрен күтәрү өчен оештырылган курсларда РОНО җитәкчесе Зоя Максимовна белән. 1 рәттә сулдан уңга 1 ?, 2 ?, 3 Җәмилова Зәйтүнә (Девятерня), 6 Шамсутдинова Сария ( Иске Сляк ), 7 Маннанова Рәхимә (Иске Сляк ), 9 Тухватуллина Саимә ( Гали ) 2 рәттә 1 Саттарова Менәзәһә ( Девятерня ), 2 Гимаева Роза (Исәнбай), 4 Зоя Максимовна, 5 Шарифуллина Хәдичә ( Кр. Бор), 7 Саликова Мәхмүдә (Исәнбай) 3 рәттә 2 Зарипова Рәшидә ( Девятерня ) 7 Сираева Рәшидә (Исәнбай), 8 Мөхәмәдиева Рафика (Исәнбай), 9 Садыйкова Зәйтүнә (Исәнбай)*

Аларга Минзәләгә укырга йөрү җиңеллләрдән булмый. 60 км лап ералыкны җәяүләп үтәргә туры килгән. Аларның истәлекләреннән беленгәнчә, Девятерня-Кадыбаш-Атнагул-Яңа Сләк-Исәнбай-Бима-Куләгеш-Волкова-Красный Бор пристане-Кама елгасы (көймә яллап яки паром белән)-Минзәлә маршруты катлаулы юл булса да, үзләренең куйган максатларына, ягъни укытучы һөнәренә ия булуга зур һәм искиткеч тырышлыкларын куйганнар.

Кияргә юньле кием булмау, аякта еш кына чабаталы студентлар булу күп кыенлыклар тудыра; крепостной крестьян хәлендә яшәүче авыл кешесенә ул чорда укырга тиешлекне исбаплап, паспорт алу зур күпләр чишә алмастай зур проблема була. Авылда көчле, яшь эшче көчләр җитми һәм беркемнең дә, бигрәк тә ул вакытта зур властька ия булучы колхоз председателенең дә авыл яшьләренең белемгә булган омтылышын туктата алмый.

Ләкин еш кына коточкыч ул елларның газаплы тормышы кешеләрне кыенлыкларны җиңәргә өйрәтә, берләштерә, авыр чакта ярдәм кулы сузу тормыш кагыйдәсенә әйләнә.

Бүгенге көндә мәктәбебез исемен йөртүче күрше Нарат авылында туып, 1947 нче елдан Девятерня җидееллык мәктәбенә йөреп укый башлаган, республикабызның күренекле шагыйре һәм композиторы Ләбиб Айтуганов та 1950-1954 нче елларда Минзәлә педучилищесында белем ала. Мәктәптә укыганда ук шигырьләр генә түгел, хикәяләр, пьесалар, хәтта роман да яза. Алар җитлеккән әдәби әсәрләр булмасалар да, булачак шагыйрь уйларының башлангычлары булулары белән әһәмиятле. Ул укыган вакытта Девятерня мәктәбенең рухи тормышы тагын да җанлана. Минзәләдә уку дәверендә Ләбиб Айтугановның сәләте төрле яклап ачыла. Ул анда нота язарга, мандолина, рояльдә уйнарга өйрәнә, шигырь, мәкаләләрен җирле һәм республика матбугатында бастыра. Ул вакыттагы күренекле әдипләр С.Урайский, М.Хөсәен, С.Баттал, Г.Иделле, Г.Әпсәләмов һ.б. белән элемтәдә була.

1954 нче елда Казан дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. Анда укыганда Ләбибнең чын иҗат эше башлана. Студент елларында аның И.Юзеев сүзләренә “Карлыганым-бөрлегәнем” дигән беренче җыры, аның артыннан ук “Төнбоек” җыры языла. Институтның III курсында укытанда ук Татарстан радиосының музыкаль тапшырулар редакциясендә эшли башлый: уку белән хезмәтне бергә алып бара. Институтны кызыл дипломга тәмамлагач, радиода эштә кала.

Татарстан радиосында Ләбиб Айтуганов киң колач җәеп эшли. Күп төрле тапшырулар эшләү белән бергә, иҗат белән дә шөгыльләнә. “Юллар”, “Язлар җитсә”, “Җырлап үстем”, “Дустым җыры” һ.б. җырларын яза, композиторларга шигырьләр иҗат итә. Ул һәрвакыт эштә, хәрәкәттә була. Авылга ялга кайткач та тик ятмый: авыл яшьләрен җыеп, спектакльләр, концертлар оештыра, агитбригада белән Татарстан авылларына йөри.

Ләбиб Айтуганов радиода озак эшләми: 1964 нче елның 24 нче апрелендә (29 яшендә) коточкыч авыру аның гомерен өзә. Үзенә бирелгән вакытның бик кыска булуын сизгәндәй, барысын эшләп бетерергә өлгерим дигән сыман, сирәк кешеләрдә генә очрый торган үҗәтлек белән ашкынып иҗат итә. Радионың сәнгать редакциясе эше Ләбиб эшләгән елларда гөрләп бара. Аның тирәсендә һәрвакыт артистлар, шагыйрьләр, композиторлар була. Ул А.Ключарев, И.Шәмсетдинов, Ф.Әхмәтов, М.Яруллин, И.Юзеев, А.Арсланов, И.Шакиров һ.б. күренекле шәхесләр белән бергә сәнгать дөньясын баета.

Ләбиб Айтуганов кыска гына гомерендә татар дөньясына аның онытылмас сәхифәләрен язган шәхес булып керде. Ләбиб исеме аны күреп һәм ишетеп белгән һәр кеше өчен һаман да кадерле исемнәрнең берсе булып кала. Без, Девятерня мәктәбе коллективы, шундый укучыбыз, якташыбыз булуы белән горурланабыз һәм мәктәбебезгә талантлы шагыйрь, композитор, радиожурналист, оста җырчы, биюче Ләбиб Айтуганов исемен бирү теләге белән яшәдек. Аның якты истәлеген 2004 нче елда шул рәвешле мәңгеләштереп, әлеге исемне лаеклы йөртү – киләчәккә олы максатыбыз булып тора.

1955 нче елда авыл советы һәм партия оешмасы карары белән Девятерня авылында кичке мәктәп эшли башлый. Беренче елны 5нче класс ачыла. Укытучы итеп Айдарова Мәүгыйдә Хәйдәр кызы билгеләнә. Рәсем, җыр, физкультурадан башка барлык фәннәр дә укытыла. 1962 елда инде Девятерня авылында бары 3 кенә кеше укый-яза белми, ә 16 яшьтән 49 яшькә кадәр 18 кешенең белеме 4 класстан түбән була. Авылда наданлыкны бетерү өчен укытучылар күп көч куялар, белемсезләр аерым укытучыларга беркетелә. Мәсәлән: Мөсифуллин Илдар Вахитовка, Исмагилова Нәгыймә Зариповага, Камаева Шәмсия Айдаровага. Камаев Мулламухамәт, Хаҗиева Әмдәзия, Гильфанов Мирфаяз, Хөснетдинов Зөфәр, Садыйков Мортаза, Гайнуллин Хөсәеннәр кичке мәктәпнең беренче укучылары булалар. 8-10нчы класслар ачылгач, һәр фәннән аерым фән ияләре килә. Укулар бик авыр шартларда бара. Дәресләр “Ленинград”дип аталган бик иске, хәтта куркыныч класста (салкын, ишелү куркынычы булган, бер керосин лампасы яктысында һ.б) дәресләр алып барыла. Бу укучылар укуның киләчәктә кирәк буласына ышанып, тырышып укыйлар, урта белемгә ия булалар. Кичке мәктәптә укуның торышын тикшерергә килгән Красный Бор РОНОсы җитәкчесе Зоя Максимовна мәктәптә укыту торышының уңышлы баруын әйтә. Шул чор укытучыларының әйтүе буенча Зоя Максимовна искиткеч белемле, сәләтле, шулай ук гадел булуы белән аерылып торган, хәтере яхшы булган, ул районлагы барлык укытучыларны таныган һәм исем, фамилияләре белән эндәшкән.

Бу елларда эшләгән техник хезмәткәрләрнең эшләрен авыл халкы мактап искә ала. Аларның хемәтләре шулкадәр авыр була, барлык өлкән класcларны ике генә хезмәткәр: Файрушина Маһира, Шаяхметова Саймәләр җыештыралар. Һәрберсе өчәр мичкә яга, моның өчен утынны кул пычкысы белән кисәләр, яралар, идәннәрне ышкып юалар, көн саен бик тирән коедан 10-15 көянтә су чыгаралар. Шулай да 100 яшькә кадәр яшәгән Маһира әби үткәннәрне искә төшереп сөйләгәндә беркайчан да авырлыклардан зарланмаган, ә уен-көлке белән генә сөйләгән.

Ул елларда мәктәпләрдә пионер һәм комсомол эшләренә зур игътибар бирелә. Укучыларны пионерга алу ныклы хәзерлек белән алып барыла. Пионер укуда, үз-үзен тотуда, класстан тыш эшләрдә актив катнашучы булырга тиеш. Шундыйлар гына пионер булуга лаеклы була. Һәр отрядта сборлар була һәм анда башка отрядлардан алдынгы пионерлар чакырыла һәм

аларның чыгышлары тыңлана. Дружина сборлары авыл клубында үткәрелгән. Отряд вожатыйлары рапортларын кычкырып, аңлаешлы,төгәл итеп биргәннәр.

Һәр елның 19 нчы маенда укучылар пионервожатый җитәкчелегендә (пионер ошешмасы төзелгән көн) районга үзәгенә слетка баралар. Бу слетта актив, үзләренең сәләтләрен яхшы итеп күрсәтә белүче, үз сүзләрендә нык тора белгән укучылар катнашкан. Ул елларда мәктәпнең пионер вожатые булып мин эшләдем дип искә ала шул еллар чордашы ветеран укытучы Зарипова Рәшидә Сәләхиевна. (Шул елларда мәктәптә эшләгән ветеран укытучылардан 2017 елда исән булган бердәнбер укытучы Зарипова Рәшидә Сәләхи кызы истәлекләре файдаланылды).

50 нче еллардагы мәктәп сулышы, төп мәктәптә булган вакыйгалар мәктәпнең приказлар китабында ачык чагыла. Мәктәп директоры Шарифуллин Габдулла Шарифуллович имзалаган 1 номерлы приказлар китабында Девятерня мәктәбендә түбәндәге төп вакыйгалар тасвирлана: 1958 елның январенда VII класс укучылары Вахитов Габдрахман абый җитәкчелегендә авылда “Бердәнбер бала” исемле спектакль куеп мәктәп кассасына 230 сум акча туплыйлар. Бу чорда мәктәптә гомуми стена газеталары айга 2 тапкыр матур, эчтәлекле итеп чыгарылып мәктәп директоры тарафыннанраслана. Укулар 1958 ел апрель приказында күрсәтелгәнчә һәр көнне 8.30да башлана, көннәр озынайгач иртәнге 8.00гә күчерелә. Шул ук елны мәктәпкә колхоздан кукуруз үстерү участогы бүлеп бирелә, анда өлкән класс укучылары, укытучылар дәресләрдән соң барып эшлиләр. 1958 елның 2 нояберендә IVкласс җитәкчесе Зарипова Рәшидә өч атна буена йөреш, тәртип, чисталык һәм җәмәгать эшләрендә беренчелекне алып мәктәпнең кызыл байрагын үз кулында тотканы өчен рәхмәт белдерелә һәм класска 36 дәфтәр һәм кара порошогы бүләк ителә. 1958 елның 22 декабрендә 3 атна буена йөреп, өлгереш, тәртип һәм ашлама җыю буенча мәктәп күләмендә беренчелекне алган IV класс укучылары һәм класс җитәкчесе Зарипова Рәшидәгә рәхмәт белдерелә, класс дәфтәр һәм перолар белән бүләкләнә. 1958 елның 25 декабрендә учком председателе Гатауллина Мәдинәгә укуда һәм җәмәгать эшендә күрсәткән активлыгы өчен рәхмәт белдерелә. Укучылар арасында оештырылган социалистик ярышта Гафаров Нәфүр 100 кг көл һәм 100 кг кош тизәге алып килеп мәктәптә 1 нче урынны ала, аңа рәхмәт белдерелә һәм общий дәфтәр белән бүләкләнә. КПССның XXI съездын каршы алып 1959 елның 2 мартында 27 номерлы Красный Бор РОНОсы отношениесе нигезендә укучылар өйләрдә кроликлар һәм чебешләр үстерергә тиеш булалар. Шулай ук мәктәптә куян (кролик) фермасы оештырыла. Аңа җитәкче итеп укытучы Вахитов Габдрахман абый билгеләнә. 1959 елның 13 октяберенә мәктәп директоры Шәрифуллин Габдулла Робселькорларның III бөтентатарстан съездында катнаша. Мәктәпттә ул елларда методик кабинет уңышлы эшли, аңа җаваплы укытучы Назипова Гөлҗиһан апа була. 1960 елның 1 сентябреннән башлангыч 1 класста Зямилов Нургаян Гали улы укыта башлый.

Мәктәптә һәм авылда яз һәм көз айларында агач утырту өмәләре ясала. 1960 елда мәктәп ишек алдына 160, бакчага 300, колхоз яслесе һәм идарәсе алдына 500 төп, урамда һәр укучы 2 шәр төп агач утыртырга йөкләмә бирелә.

1961 елның 20 июлендә мәктәпнең 15 отличникын һәм “4”е “5” легә укучы укучыларны Сарапул-Ижевск маршруты буенча туристик походка алып баралар, моның өчен 1200 сумга металлалом җыйган акчаны файдаланырга кушыла.

1961 елның 5 сентябрыннан мәктәптә завуч итеп Исәнбай авылы кызы Ганиева Зәйтүнә билгеләнә, ул Девятерня сигезьеллык мәктәбендә беренче югары белемле укытучы була, татар теле һәм әдәбияты дәресләрен укыта.

КПССның XIIсъездына багышланган (1961 ел 5 октябрь) эстафета журналы Красный Бор районы мәктәпләре арасында йөреп тутырыла. Соңнан Кадыбаш сигезьеллык мәктәбенә тапшырыла.

1963 елның 4 мартыннан завуч Шәрифуллин Нурулла дәваланырга китү сәбәпле, завуч итеп Хикматуллин Хаҗи Хикматулла улы билгеләнә. 1964 елның мартында химия һәм биология фәннәре буенча укучылар Исәнбай кусты олимпиада ярышларында призлы урыннарны алалар. Катнашучы укучылар - Ибраева Сария, Файзуллин Дамир, Батыршин Мирзанур, Шәрифуллина Рәйсәләргә рәхмәт белдерелә, алар китап белән бүләкләнәләр, укытучы Хикматуллин Хаҗига Хикматулла улына рәхмәт белдерелә.



*1950-1951 нче уку елының беренче яртысын*
*4 һәм 5 билгеләренә генә тәмамлаучы укучылар.*

***<u>Шул чорда мәктәптә эшләүче техник персонал исемлеге:</u>***

1. Файрушина Маһира мәктәптә күптәннән эшли.
2. Басариева Зәйтүнә, 12 август 1957 ел, сторожиха.
3. Шаяхметова Гөлҗиһан, 20 октябрь 1958 ел, сторожиха
4. Шаяхметова Саимә, 25 сентябрь 1959 ел.
5. Ситдикова Лидия, 25 сентябрь 1959 ел, сторожиха
6. Ясавиева Нажия, техничка, 1960 ел, 1 июль-1962 ел 16 сентябрьга кадәр.
7 .Ситдикова Лидия, буфетчица. 1961 ел октябрь. Эш вакыты иртәнге 6дан 16 сәг.кә кадәр.
8. Ахмадишина Мәрьям, техничка, 1961елның 2 декабрыннан 1964 елның 13 январына кадәр.
9. Абдуллина Нәҗибә, техничка. 1962 елның 4 маеннан 1962 елның 20 августына кадәр.
10. Тимершаехова Фәридә - техничка. 1962 елның 20 августыннан.
11. Абдуллина Галимә - техничка. 1962 елның 15 августыннан.
12. Абдуллина Нәҗибә - техничка. 1962 елның 16 августыннан.
13. Басариева Зәйтүнә- техничка. 1963 елның 24сентябрыннан.
14. Закирова Маһируза- техничка. 1964 елның 13гыйнварыннан.
15. Юсупова Рәхимә интернат, повар 1964 елның 13гыйнварыннан.
16. Маннапова Рәшидә интернат. Техничка 1964 елның 15 гыйнварыннан.
17. Абдуллин Габделхай интернатта төнге каравыл, 1964 елның 15 гыйнварыннан.
18. Низамова Фәрхежан- интернат, повар 1964 елның 14сентябрыннан.

**1948 – 1964 елларда мәктәп директоры булып эшләгән Шарифуллин Габдулла Шарифулла улы турында кыскача белешмә.**

Шарифуллин Габдулла Шарифулла улы 1920нче елның 22нче февралендә Әгерҗе районы Барҗы авылында, урта хәлле крестьян гаиләсендә туган. Башлангыч белемне Барҗы мәктәбендә ала. 1939 нчы елда Казан педагогия училищесын тәмамлый. Шуннан соң Азнакай районы Чалпы мәктәбендә физика, математика фәннәрен укыта. Анда бер ел эшләгәч, 1940 нчы елның 13нче октябрендә армия сафына алына. Забайкальеда солдат хезмәтен 1ел башкаргач,

Иркутск шәһәрендә автомеханик һөнәренә укый. Сугыш башыннан алып, ахырына кадәр автомеханик булып хезмәт итә. Японияга каршы сугышта да (9.08-3.09.1945) катнаша.

Сугыштан соң, 1945-1946нчы уку елында, Габдулла Шарифулла улы Әгерҗе районы Үтәгән җидееллык мәктәбендә география, рәсем, сызым фәннәрен укыта. 1947 нче елдан таләпчән һәм киң эрудицияле педагог Девятерня җидееллык мәктәбендә директор һәм география укытучысы, ә 1966-67нче уку елыннан шул ук мәктәптә география укытучысы булып эшли. Габдулла Шарифулла улы укытучылар һәм авыл халкы алдында зур хөрмәттән файдаланды, ул балаларны (күпчелек ятимнәрне) укытырга, белем бирергә, ашатырга, тәрбияләргә зур көч куя. Ул һәркайда өлгерә, оста мөгаллим, оештыручы һәм хуҗалыклы кеше була. Габдулла Шарифулла улының тормыш иптәше Абдуллина Әлфия Фатих кызы Девятерня мәктәбендә 1948нче елның гыйнварыннан 1975нче елга кадәр рус теле фәнен укыта.



Соңрак, Габдулла Шарифулла улы 8 ел Девятерня авыл советы рәисе булып эшли һәм лаеклы ялга чыга.

1981нче елның сентябрыннан мәктәп директоры Әхмәтҗанова Мөхтәрәмә Мөхәмәтдин кызы декрет ялынна киткәч, 1982нче елның 15нче августына кадәр вакытлыча мәктәп директорын алыштыра.

## 5 нче бүлек.
## Девятерня мәктәбе 1964 -1980 нче елларда. (Мәктәп директоры Әхмәтов Минегаян Мөхәммәт улы).



1963 – 1964 нче елларда илебез тормышында зур үзгәрешләр була, бу үзгәрешләр, билгеле, мәгариф системасына да йогынты ясый.

Н.С.Хрущев ил җитәкчелегеннән читләштерелә. Йомшару чорының демократик яңалыклары кими. Промышленность һәм авыл хуҗалыгы өлкәсендә административ идарә ысулларыннан икътисади ысулларга күчәргә омтылыш ясала.Ул промышленностьнең югары темплар белән үсүенә этәргеч була. 1965 нче елда авыл хуҗалыгын үзгәртергә тагын бер омтылыш ясала. Колхозларның бурычы бетерелә, продукцияне сатып алу бәяләре күтәрелә, өстәмә түләүләр билгеләнә, салымнар киметелә. Авылларны 1965-1975 нче елларда техник яктан яңадан коралладыру аеруча югары була.Минераль ашламалар куллану кискен үсә. Бу чорда колхозларда хезмәт җитештерүчәнлеге 44 % ка күтәрелә. Бу исә кешеләргә яхшырак киенергә, тукланырга мөмкинлек бирә. Авыл шәһәрдән социаль өлкәдә хәтсез калышса да, 70 нче елларда йортларда телевизор, электр уйнаткычлары, магнитофоннар, суыткычлар, кер юу машиналары арта. Мәктәпләрне дә акрынлап техник җиһазлар белән коралландыру мөмкинлеге туа.

Ул чорда авыл балалары кечкенәдән үк хезмәт белән тәрбияләнә: хуҗалыкта, өйдә һәрбер баланың күп төрле үз эше була, өйдә, ишек алдында тәртип кертү, терлекне карау, кечкенә эне-сеңелкәшләрне тәрбияләү, ашату, киендерү, үсә төшкәч, колхозга булышу... Ипи үстерсә дә, авыл халкы ачлыктан интегә. Урласаң, төрмәгә ябалар. Сугыш һәм сугыштан соңгы елларда авылда утын иң зур проблемаларның берсе була. Урман янында яшәсәк тә, кешеләр, балалар кыш көне салкыннан интегә. Ул вакыт тәртипләре буенча урманда агач кисү тыела. Мәктәптә һәм өйдә салкын булу сәбәпле, яза торган караларката. Ул вакыт укучылары металл перолар белән кара (буяу) савытындагы кара буяуга манып язганнар. Андый перо ярдәмендә язылган линияләрнең (хәрефләрнең) калынлыгын үзгәртеп булган, һәм укытучылар һәр укучыдан матур каллиграфик почерк (язу) таләп иткәннәр. Еш кына кара перодан кирәкмәгән урынга тамып язуны пычратакан, ә инде 60 нчы елларда шариклы ручкалар барлыкка килгәч, караның таму куркынычы бетсә дә, перолар белән бергә каллиграфия фәне дә тулысынча диярлек юкка чыга. Укучылар дәфтәрләр җитмәгән очракта кирәкмәгән китаплар һәм иске газеталарның буш урыннарына язганнар.

Ләкин 80 нче еллар чигендә команда боерыгы системасы тирән кризис хәленә керә башлый. Халык куллану товарларына ихтияҗ арта, аны канәгатьләндерү акрын бара.. Кешеләр алырга теләгән әйберләр җитешмәү гадәти хәлгә әверелә.Авылның шәһәрдән артталыгы, авылдагы социаль өлкәдәге кимчелекләр, промышленностьнең үсеше авыл кешеләренең шәһәргә омтылуына сәбәп була.Авылда халык саны кими, билгеле бу мәктәптә укучылар саны кимүенә дә китерә.

Җәмгыять тормышында, рухи өлкәдә уңай үзгәрешләр күп була, республикада фән, мәдәният бер өлкәдә тормый, балаларга урта һәм югары белем алу мөмкинлекләре киңәя, авылда да халыкның интеллектуаль дәрәҗәсе күтәрелә. Укучыларга ныклы сыйфатлы урта белем бирү мөмкинлеге арта. Татарстанда 70 нче елларда гомуми урта белемгә күчү тәмамлана. Әлеге чорлар шаукымы безнең мәктәбебезгә дә йогынты ясамый калмый. Девятерня укучылары сигезьеллык мәктәпне тәмамлаганнан соң Исәнбай Урта мәктәбенә барып белемнәрен дәвам итсәләр, 1967 елда Кадыбаш авылында урта мәктәп ачыла. Күпчелек укучылар укуларын якындагы Кадыбаш мәктәбендә дәвам итәләр. Девятерня авылында урта мәктәп 1985 нче елда ачыла. Балаларга үз авылларында, юл мәшәкатьләреннән башка, урта белем алу мөмкинлеге туа.

1964 нче елның декабрендә Девятерня сигезьеллык мәктәбендә коллектив фикерен исәпкә алып яңа директор билгеләнә. Директор булып шушы ук мәктәптә ике елга якын уку-укыту бүлеге мөдире булып эшләгән Әхмәтов Минегаян Мөхәммәт улы куела. Ул мәгариф өлкәсенә

шактый тәҗрибә туплап килгән кеше була. Гали авылында колхозчы гаиләсендә туган, Кадыбаш һәм аннан соң Минзәлә педагогия училищесын 5 ле билгеләренә генә тәмамлаган, аннан Минзәлә районы, Новоалександровка рус мәктәбендә укыткан, Совет армиясе сафларында хезмәт иткән һәм аннан соң 3 ел Нарат башлангыч мәктәбендә укытучы һәм берүк вакытта директор булып та эшләргә өлгергән кеше була. Ул вакытта Нарат мәктәбендә укучылар саны 70 җиткән була. Девятерня сигезьеллык мәктәбе директоры вазыйфасын Минегаян ага 1980 нче елның июленә кадәр дәвам итә.



Девятерня сигезьеллык мәктәбе укытучылары 1977/1978 нче уку елында мәктәп директоры Әхмәтов М.М. белән

Чыннан да яшь директор өчен гаять авыр йөк була бу: сигезьеллык мәктәп кенә булса да ( балалар сны 345 була), барлык класслар да параллель , авыл яшьләре өчен кичке урта мәктәп , озынайтылган көн группалары оештырыла, өстәвенә 75 урынлы мәктәп яны интернаты булдырыла, ә укытучы-тәрбиячеләрнең саны гына 30 дан артык була.



Девятерня сигезьеллык мәктәбенең чыгарылыш класс укучыларын мәктәп директоры Ахметов М.М. котлый. 1972 нче ел, 25 нче май. “Соңгы кыңгырау”.

Мондый катлаулы шартларда тиешле дәрәҗәдә оештыру өчен партия группасы ( җитәкчесе Айдарова Мәүгыйдә Хәйдәр кызы) һәм профсоюз оешмасы (профком рәисе укытучы Зарипова

Рәшидә Сәләхи кызы) белән киңәшләшеп, иң элек коллективның барлык членнары өчен дә бердәм таләпләр куюдан башлана. Яңа җитәкченең таләпләрен коллективның зур күпчелеге яклап чыга.

Гомуми положениеләрдән чыгып, мәктәпнең, аның традиция һәм уңай якларны, уку һәм укыту өчен тудырылган шартларны искә алып, мондый бердәм таләпләр укучылар, озынайтылган көн группалары, интернат тәрбиячеләре өчен дә төзелә. Аларның үтәлеше нык контрольдә тотыла. Озак та үтми нәтиҗә дә күренә башлый: хезмәт дисциплинасы яхшыра төшә, укучылар арасында йөреш, өлгереш кебек күрсәткечләр дә күтәрелә башлый.

Шул ук вакытта мәктәпне, укыту-тәрбия эшләрен уңышлырак һәм бу эшне җиңеләйтү максатыннан да, техник средстволар белән тулыландыру эшләре тагын да яхшырак алып барыла. Мәсәлән, районның авыл мәктәпләре арасында беренче булып мәктәпкә кино һәм радиоузел аппаратлары кайтартыла. Мәктәпнең үз радиосы эшли башлый. Аерым фәннәргә, төрле темаларга багышланган радиотапшырулар оештырыла. Ә киноаппарат белән эш итәргә барлык укытучылар да өйрәнәләр. Дәресләрдә, дәрестән тыш чараларда уңышлы гына файдаланалар. Баштарак төп фәннәр буенча кабинетлар булдыру, аларны җиһазлау эшләре дә шушы елларда башлана.

Укучыларга уку, укытучыларга эш өчен уңай шартлар тудыру буенча да күп кенә эшләр эшләнә: мәктәпнең төп бинасы фундаментка утыртыла, түбәсе өр яңадан калай белән ябыла, төп бина янына 3 класслы янкорма, кызлар һәм малайлар өчен аерым интернат биналары, спорт мәйданы һәм башка күп кенә хуҗалык өчен кирәкле объектлар төзелә. Бу эшләрдә , әлбәттә, район җитәкчеләре, урындагы К.Маркс исемендәге колхоз (председателе Камалиев Әхәт Хазетдинович), Комсомолка урман пункты (начальнигы Ибраев Ф.Х.) һәм Девятерня урманчылыгы ярдәм итәләр.

Мәктәпне транспорт чаралары белән дә тәэмин итү шул елларга туры килә. Барлык кирәкле инвентарьлары белән ат, арба һәм чаналары белән яңа ДТ -75 тракторы, “Москвич” (фургон) җиңел машинасы, яңа “Дружба” пычкалары алына. Болар мәктәп хуҗалыгын алып баруга зур ярдәм итәләр. 25 миче булган мәктәпне, укытучыларны ягулык утын белән тәэмин итү нигездә алар ярдәмендә башкарыла.

Ул елларда Девятерня сигезьеллык мәктәбе укучылары зона, район, республика күләмендәге төрле ярышларда, конкурсларда, олимпиадаларда актив катнашып призлы урыннарны алалар. Районда булган киңәшмә-җыелышларда Девятерня мәктәбе тәҗрибә участогы, производство бригадасы (җитәкчесе биология укытучысы Вахитов Габдрахман һәм Шәрипова Рәкыяләр) һәрвакыт уңай яктан гына телгә алына.

Мәктәп яны тәҗрибә участогы эше күпләргә үрнәк итеп куела. Укучылар үстергән яшелчәләрне 3 ел рәттән (1971-1973 нче елларда) Мәскәүгә, Бөтенсоюз халык хуҗалыгы казанышлары (ВДНХ) күргәзмәсенә соратып алалар. Нәтиҗәдә күп кенә укучылар грамоталар, кыйммәтле бүләкләр белән бүләкләнә, Шаймарданова Роза ВДНХ ның алтын медаленә ия була.



Девятерня сигезьеллык мәктәбенең
1969 нчы ел чыгарылышыннан бер төркем кызлар.

1969-1975 нче елларда мәктәпнең производство бригадасы белән мәктәп китапханәчесе Шарипова Рәкыя җитәкли. Ә участок һәм бригада эшләре белән гомуми җитәкчелек биология укытучысы Вахитов Габдрахманга төшә. Бригада членнары үз җирләрендә суган, чөгендер һ.б. төрле яшелчәләр үстерәләр, берүк вакытта тәҗрибә эшләре дә алып баралар. Ә кыш көннәрендә җәйге сезонга әзерләнү белән бергә, игенчелек нигезен дә өйрәнәләр. Тырыш хезмәтнең нәтиҗәсе дә куанычлы була: бригада членнарының күбесе мәктәптән соң авыл хуҗалыгы профессияләрен сайлыйлар.



Класс житәкчесе Саттарова Мөнәзәһә апа 1965 нче елда 3 нче класс укучылары белән

Яңа уку елына хәзерлек буенча районда игълан ителгән ярышларда Девятерня мәктәбе берничә ел рәттән җиңүче исемен яулый, район Советы, КПСС ның район комитетының күчмә Кызыл байрагы белән бүләкләнә.

Үсеп килүче яшь буынга фән нигезләрен өйрәтүдә һәм аны коммунистик рухта тәрбияләүдә ирешкән уңышлары өчен 1975 нче елда мәктәп директоры Әхмәтов М.М. һәм уку-укыту бүлеге мөдире Хикматуллин Х.Х. “РСФСР ның халык мәгарифе отличнигы” дигән исемгә лаек булалар.

Һәр елны җәен мәктәп укучылары колхоз хисабына оештырылган пионер лагерьларында ял итәләр. Лагерь ике сменада эшли. Һәр сменада 25-30 укучы ял итә. Укучыларның сәламәтлекләрен ныгытуда, ялларын файдалы һәм кызыклы да оештыруда физкультура укытучысы Гатауллина Г.В. һәм өлкән пионер вожатые Зиятдинова Гүзәлияләр күп көч куялар.

1970-1980 нче елларда укучыларга хезмәт тәрбиясе бирү, аларны авыл өчен кирәкле профессияләр белән кызыксындыру проблемасы тагын да кискен куела. Чөнки сүз партия тарафыннан эшләнгән, илдә азык-төлек проблемасын уңышлы хәл итү турында бара. Куелган бурычны тормышка ашыруда мәктәпнең хезмәт укытучылары Тазиев Мулламөхәммәт һәм Тараканов Дамирлар (Иж-Бубый авылы егете) үзләреннән зур гына өлеш кертәләр. Алар җитәкчелегендә хезмәткә өйрәнүнең базасы ныгытыла, колхоз белән элемтә тагын да яхшыртыла, ныгый.



**1979 нчы ел, 1 нче сентябрь.**

Уңнан сулга: Ахметова Мәгъфүрә Габдениуровна, Сайфетдинова Фәйзә, Гатауллина Гөлүсә Валиулловна, Газизова Халисә Колдусовна, Муратова Разилә Нургаяновна.

Девятерня сигезьеллык мәктәбе укытучылары укучыларга спорт тәрбиясе бирү өстендә эш алып баралар. 1973 нче елны мәктәптә зур гына спорт мәйданчыгы булдырыла. Бу эшкә күп көчне физкультура укытучысы Рафаэль Шайдуллин һәм директор Минегаян Әхмәтовлар куя. Әлеге спорт мәйданчыгында ул вакытта бик күп ярышлар уздырыла: йөгерү, сикерү, күңелле стартлар. Яше, карты буш вакытларда мәйданчыкка тартыла.

Ул елларда 75 урынлы мәктәп яны интернаты эшли. Анда Нарат һәм Гали авылларыннан килгән укучылар яши. Алар көнгә 3 мәртәбә кайнар аш белән тәэмин ителәләр. Җылы, якты, чиста бүлмәләрдә яшиләр. Укучылар үзләре дә чисталыкны, тәртипне саклыйлар. Аларга дәресләр хәзерләү, яшәү шартлары тудыруда тәрбиячеләр Җәләева Розалия (Нарат кызы), Хабибуллина Лилия ( Касай авылы) , бигрәк тә Айдарова Мәйгыйдә (бер үк вакытта укытучы да) Газизова Халисә, Камалиева Мәрьямнәр апалар, Мухаметова Мәрхәбә, Гильфанова Зөлфирәләр зур тырышлык куялар. Продукция белән тәэмин итүдә колхоз да зур ярдәм итә. Балалар тәрбияче апаларын “икенче әниләре” итеп күрә.

Мәктәптә укучылар саны зур булу сәбәпле, озак еллар буена лаборант штаты да булдырыла. Лаборантлар кабинетларны күргәзмә ярдәмлекләр, техник чаралар белән тулыландыруда җаваплы булалар. Фән ияләре белән лаборатор эшләрне, тәҗрибәләрне тиешле тәртиптә ясарга җаваплы да булалар. Үз вазыйфаларына бигрәк тә төрле елларда лаборантлар Габдрахманов Рәүф (Гали), Хәлиуллин Илфат (Нарат), Муратов Камилләр, Фәтхетдинов Ренатлар җаваплы карыйлар.

Бу елларда мәктәптә җәмәгать оешмалары нәтиҗәле эшли. Партия группасы составында 11-13 коммунист хисаплана. Группа белән озак еллар мәктәпнең өлкән һәм тәҗрибәле укытучысы Айдарова Мәүгыйдә Хәйдәр кызы җитәкчелек итә. Партия эше түләүсез, җәмәгатьчелек башлангычында башкарыла. Шулай булса да, группаның эше күпкырлы була. Ә инде профсоюз оешмасын тәҗрибәле укытучы, коллективта зур авторитет казанган Зарипова Рәшидә Сәләхетдин кызы җитәкли. Оешмада мәктәпнең барлык укытучылары, тәрбиячеләре, техник хезмәткәрләре дә член булып торалар. Оешманың эшчәнлеге мәктәп тормышының барлык якларына да кагыла. Уку-укыту өчен шартлар тудыру, дәүләт тарафыннан билгеләнгән льготалардан файдалану, мәктәптә гомуми дисциплина, хезмәтне саклау эшенең торышы, хезмәттәге бәхәсле мәсьәләләр - профсоюз оешмасы шөгыльләнгән проблемаларның кайберләре генә.

Гомумән, мәктәптә профсоюз оешмасы дирекциянең таянычы, ә укытучыларның яклаучысы була.

70 нче елларда мәктәп сулышы, төп вакыйгалар мәктәпнең приказлар китабында ачык чагыла.

1970 нче елда В.И.Ленинның 100 еллыгына хәзерлек чорында 8 нче класс укучылары Хөсәенов Рахимҗан һәм Абдуллин Фәнил броневик макеты, Шәйдуллин Альберт һәм Шәйдуллин Рамил Ленинның Разливтагы шалаш макетын, Тазиев Роберт һәм Закиров Илфатлар Ленинның Кокушкинодагы музей-йорты макетларын ясап, мәктәп директоры Рәхмәтен алганнар.

1973 нче елда Зарипова Рәшидә һәм Саттарова Мөнәзәһә җитәкчелегендә 15 укучы Казан шәһәренә экскурсиягә җибәрелгәннәр.

Комсомолка эшчеләр поселогында яшәүче эшчеләрнең балалары 1974 нче елдан Удмуртия республикасының Кияс районы Лутоха урта мәктәбенә укырга йөри башлыйлар.

Ел саен туристик слетлар, мәктәптә һәм 19 нчы май көнне район үзәге Әгерҗе шәһәрендә пионер слетлары үткәрелгән.

1975 нче елның 1 нче октябрендә Вахитов Габдрахман абый һәм Тукманова Зәйтүнә апаларның 60 еллык юбилеен, укытучы Зарипова Рәшидә Сәләхиевнаның эшли башлавына 25 ел тулуы билгеләп үтелгән.

1976 нчы елда 32 укучыны эченә алган озайтылган көн группасы эшли башлый.

1977 нче елның 31 нче маеннан 8 укучы Биктимерова Гөлүсә һәм Каримова Рәүфәләр җитәкчелегендә Ульяновск шәһәрендә экскурсиядә булганнар.

1978 нче елдан ике озайтылган көн группасы ачыла, 1 нче группада 36, икенче группада 33 бала йөри. Төрле елларда озайтылган көн группасында Тукманова Зәйтүнә, Җәмилева Зәйтүнә, Ахметова Мәүгыйдә, Закирова Сәрия (1975 нче елның 20 нче ноябрендә каты авырудан соң вафат булды), Гильфанова Гөлфирәләр эшләде.

Укучылар ел саен ГТО нормаларын тапшыралар, һәр укучыга нормативларны уңышлы тапшырганнан соң тантаналы шартларда күкрәк билгеләре тапшырыла.

Мәктәптә “Белем җәмгыяте”, “Табигатьне саклаучылар”, “Табигый һәйкәлләрне саклау” җәмгыятьләре уңышлы эшләп килә.

Үткәрелә торган барлык чаралар балаларның белемгә булган кызыксынуын көчәйтү, патриотик тәрбия бирүгә юнәлдерелгән, шуңа күрә дә Девятерня сигезъеллык мәктәбе бу чараларда хаклы рәвештә район буенча алдынгы мәктәпләрдән санала.

1963-80 нче елларда түбәндәге кешеләр мәктәптә хуҗалык бүлеге мөдире вазыйфаларын башкаралар: Юсупов Мәгъсүм (Девятерня), Мөхәммәтҗанов Рифкат (Девятерня), Рамазанов Нурмөхәммәт (Девятерня), Садыйков Әхәт (Гали авылы).

Ул елларда әле мәктәп биналарын үзәктән җылыту системасы булмый: гади мичләр (барлык мичләр саны 25 тән артып китә) белән җылыталар, барысына да утын ягалар. Ә кышка ягулык утын хәзерләү, аны кисү, ташу, кайткач – кисү, яру кебек авыр эшләр техник персонал өстенә төшә. Өстәвенә чистартырга, себереп, юарга да кирәк була.

Шундый гаять авыр эшне техник хезмәткәрләр намус белән башкаралар, укыту-тәрбия эшләре өчен барлык мөмкинлекләрне дә тудырырга тырышалар. Алар: Файрушина Маһира, Абдуллина Галимә, Низамова Фәхерҗан, Рамазанова Рәхимә, Гайнуллина Рәшидә, Вәлиеева Гөлчирә, Гараева Рәкыя, Газизова Разия, Габдрахманова Люция, Гыйләҗетдинова Рәшидә, Басариева Зәйтүнә, Тимершәехова Фәридәләр.

Мәктәп буфетында Вәлиева Ниалә, китапханәдә Шәрипова (Бәдретдинова) Рәкыяләр озак еллар эшләделәр, үз эшләренә җаваплы карадылар.

Таҗиева Рәмзия каравылчы (1966 ел), соңрак мәктәп счетоводы булып эшләде. 1968елда авыл советында үзәкләштерелгән бухгалтерия оештырылу сәбәпле анда күчерелде.

Мәктәптә төнге каравылчыларның эшләре дә бик җаваплы була. Алар төнге вакытта мәктәп биналарын саклау, интернатта яшәүче балаларның иминлеген тәэмин итү, яшелчәләрне саклау, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү кебек вазыйфалар башкаралар. Менә алар: Вахитова Фатыйма, Әхмәдишина Мәрьям, Гыйләҗева Хәлимә, Абдуллина Нәкыя, Әхмәтова Галия (Гали), Рамазанова Галимә (Гали).

Әлфирә Фатхетдинова “Беренче адымнар” исемле иҗат түгәрәге оештырып, каләм тибрәтүче яшь дусларына иҗади сукмак буйлап беренче адымнарын ясарга ярдәм итә. Аларның иҗаты район газета битләрендә ачык чагыла. Укучылар табигать, мәхәббәт, көн кадагында торган проблемалар чагылыш тапкан иҗат эшләре белән кызыксынып шөгыльләнделәр.



**1978 нче ел. Девятерня сигезьеллык мәктәбенең бер төркем укытучылары.**

1 нче рәттә сулдан уңга: интернат тәрбиячесе Гильфанова Зәлфирә Мирфаиз кызы, җыр укытучысы Зиятдинова Гүзәлия Галәү кызы, башлангыч класс укытучысы Ахметова Мәүгыйдә Габденур кызы, лаборант Фәтхетдинов Ринат Муллави улы. 2 нче рәттә сулдан уңга: физика укытучысы Назмиева Әлфия Габденур кызы, физика-математика укытучысы Муратова Фәридә, математика укытучысы Ахметзянова Мөхтәрәмә Мөхәммәтдин кызы, биология-география укытучысы Шайхутдинов Илдус Нургали улы, рус теле укытучысы Фәтхетдинова Әлфирә Шәех кызы, татар теле укытучысы Шаймарданова Гәүһәрия Рәхим кызы, тарих укытучысы Шайхутдинова Ләлә Нургали кызы.

Мәктәптә укучылар һәм класс- комплектлар саны зур булганлыктан, укытучы- тәрбиячеләр саны да 37 гә җитә. Бу чорда эшләүчеләрне шартлы рәвештә 3 төркемгә бүләләр: олы, тәҗрибәле, ветеран укытучылар, аннан урта буын, ниһаять яшьләр эшли. Коллективта төрле буын вәкилләре эшләсә дә, алар тату, үзара дус һәм бер-беренә ярдәм итешеп эшлиләр. Мәктәптә шундый эшчән, эзләнүчән, бер-берсен аңлап эшләүче коллектив туплауда уку-укыту бүлеге мөдире Хикматуллин Хаҗи, профсоюз оешмасы җитәкчесе Зарипова Рәшидә һәм партия группасы җитәкчесе Айдарова Мәүгыйдәләрнең хезмәтләре зур була.



*Укытучы Зарипова Рәшидә Сәләхетдин кызы 6 нче сыйныф укучыларына татар теле дәресе үткәрә.*

Мәктәпнең укыту-тәрбия эшләрендә иң беренче чиратта тәҗрибәле укытучылар барлык яктан да үрнәк булып торалар. Болар:

Шәрифуллин Габдулла Шәрифулла улы – география, рәсем;

Абдуллина Әлфия Фәтих кызы- рус теле һәм әдәбияте;

Айдарова Мәүгыйдә Хәйдәр кызы – татар теле һәм әдәбияте;

Вахитов Габдрахман Габдулла улы – физика, биология (1946 нчы елда эшли башлый);

Зарипова Рәшидә Сәләхетдин кызы – татар теле һәм әдәбияте, 1958 нче елдан бирле;
Хикматуллин Хаҗи Хикматулла улы – химия, биология, Завуч,
Наҗипова Гөлҗихан Нәҗип кызы – тарих, музыка, 1941 нче елдан бирле;
Таҗиев Мулламөхәммәт Гыйләҗетдин улы- хезмәт, 1951 нче елдан эшли башлый;
Тухватуллина Саимә Фаррах кызы- Гали башлангыч мәктәбе;
Закирова Галимә Закир кызы – Нарат башлангыч мәктәбе;
Мөхәммәтшин Ясави – Нарат башлангыч мәктәбе;
Җәмилева Зәйтүнә Касйм кызы – башлангыч класс, 1949 нчы елдан;
Җәмилева Сания Искәндәр кызы - башлангыч класс, 1944 нчы елдан;
Саттарова Мөнәзәха Фәррах кызы – 1947-1949 елларда пионервожатый, 1949 нче елдан- башлангыч класслар укытучысы булып эшли.



1972-ел.
1-рәт сулдан уңга: Закиров Камил, Мусин Ралиф, Арсланов Фәнил, Садыйков Фидәрит, Фазлыахметов Рөстәм, Рамазанов Нургаян, Шарипов Фәрит, Гыйләҗев Фәнил.
2-рәт сулдан уңга: Абдуллин Ринат, Багаутдинова Гөлия, Сибгатова Рәшидә, Фәррахова Гөлшат, Камалиева Фәридә, Мухаметзянова Розалия, Абдуллина Фәридә.
Укытучы: Саттарова Мөнәзәһә.
(Хәзерге Ситдикова Гөлсинә апалар йорты каршында ике катлы бина бар иде. Өске катта - [illegible] советы, [illegible] II сыйныф укучылары белем алды. Ул урында [illegible] дә юк.)

Аларда булган һәр эштә төгәллек, сабырлык, акыллылык, үз эшләренә җаваплылык белән карау, балаларны ярату кебек күркәм сыйфатлар башкаларга да күчә. Шуңа күрә дә аларның абруе мәктәптә генә түгел, ата-аналар һәм җәмәгатьчелек арасында да зур була, һәр урында аларны хөрмәт итәләр, сүзләренә колак салалар.



Физика укытучысы Муратова Фәридә бер төркем укучылар белән.

Күбесенә сугыш  (1941-1945), аннан соңгы авыр чорда эшләргә туры килә. Укучыларның ашарларына ашлары, кияргә киемнәре, укырга китаплары, язарга каләм-дәфтәрләре булмаган чор туры килә алар өлешенә. Өстәвенә үзләре дә гаять авыр шартларда яшиләр  һәм эшлиләр. Шуна да карамастан, якты киләчәккә өмет белән яшиләр, һәр укучыны да аң-белемле итәргә омтылалар.



**1974-75 нче уку елында бер төркем укытучылар татар теле кабинетында.**

Беренче рәттә сулдан уңга: интернат тәрбиячесе Газизова Халисә, мәктәп завучы химия укытучысы Хикматуллин Хажи, тәрбияче Закирова Сария, мәктәп директоры Ахметов М. М., физика-математика укытучысы Харисова Илгизә, икенче рәттә сулдан уңга: биология укытучысы Шайхутдинов И.Н., татар теле укытучысы Шакирова Альфира, башлангыч класс укытучысы Ахметова М., физкультура укытучысы Шайдуллин Р., рус теле һәм әдәбияты укытучысы Фәтхетдинова Альфира, рус теле һәм әдәбияты укытучысы Арсланов Зиннурлар

Урта һәм яшь буын укытучылар аларнын эш тәҗрибәләрен бик теләп өйрәнәләр. Аларча эшләргә, балаларны яратырга, хөрмәт итәргә өйрәнәләр.

Урта һәм яшь буын укытучылар һәм тәрбиячеләр исемлеге:
- Әхмәтова Мәугыйдә Габденур кызы – башлангыч классар, 1970 елдан,
- Арсланов Зиннур Солтан улы – физкультура, рус теле, озынайтылган көн группасында тәрбияче;
- Әхмәтҗанова Мөхтәрәмә Мөхәммәй кызы – математика, 1964 нче елдан;
- Шайдуллин Рафаил Фатих улы – физкультура;

- Бахавиева Тәскирә Габдулла кызы – математика;
- Тараканова Зөлфирә - башлангыч класслар;
- Тараканов Дамир – хезмәт;
- Җиханшина Миләүшә - рус теле һәм әдәбияты, 1968 елдан;
- Баязитова Венера – математика, 1966 ел,
- Солтанова Вәсилә - математика;
- Солтанов Йосыф, хезмәт, 1967 ел;
- Ризванова Венера – математика. 1970 ел;
- Сагирова Наилә - инглиз теле, 1970 - 1971 уку елында беренче тапкыр инглиз теле укытылды;
- Батыршина Гөлнур Г. – татар теле һәм әдәбияты, 1971 елдан;
- Шайхетдинова Ләлә Нургаян кызы - тарих,1978 ел;
- Фатхетдинова Әлфира Шаех кызы - рус теле һәм әдәбияты, 1974 нче ел;
- Шайхетдинова Лена Габдулла кызы – математика, 1979 нчы ел;
- Набиуллин Борис – тарих, 1976 ел
- Ижболдин Рәшит Касыйм улы - физкультура;
- Халиуллина Халисә Котдус кызы- татар теле һәм әдәбияте, 1972 нче ел;
- Шайхутдинов Илдус Нургаян улы- геогрфия, тарих, 1974 нче ел;
- Харисова Илгизә - математика;
- Калимуллина Рәсимә - рус теле һәм әдәбияты;
- Гатауллина Гөлүсә Вәлиулла кызы – физкультура, 1976 нчы ел;
- Минхаҗева Гөлсинә- математика,
- Шаймарданова Гәйхария Рәким кызы – татар теле, завуч, 1975 нче ел;
- Нәҗмиева Әлфия Габденур кызы – математика;
- Гатина Хәтимә - татар теле укытты, интернат тәрбиячесе;
- Салихова Роза - өлкән пионервоңатый, 1967 ел;
- Зиятдинова Гүзәлия Галәетдин кызы - өлкән пионер вожатый, 1968 елдан;
- Башарова Рәмзилә -интернат тәрбиячесе, 1969 ел;
- Камалиева Мәрьям кәрим кызы – интернат тәрбиячесе;
- Нәбиуллина Лилия Хәйдәр кызы – интернат тәрбиячесе;
- Җәләева Розалия Габдулла кызы - интернат тәрбиячесе.
- Фазлыева Гөлсәрия Ф. , 1973 ел,
- Шакирова Альфира – татар теле укыта, соңнан Нарат башлангыч мәктәбенә күчә, 1974 ел.
- Җәмилова Лидия Газиз кызы – химия һәм биология укыта, 1976 ел.
- Закирова Гөлсинә - физика,1976 ел,
- Муратова Фәридә - физика, математика, 1977 ел,
- Абдрашитов Рафаэл – физкультура,1975 ел,
- Тимеркаева Фәймә - биология, 1976 ел;
- Башарова Нурия - математика, 1975 ел.
- Муратова Рәзилә - библиотекарь, 1979 ел.



Ул чорда эшләгән укытучыларга күп вазыйфалар йөкләтелә. Алар агитатор, лектор, пропагандист та булалар, җәмәгать оешмаларын да җитәклиләр. Колхозда төрле эшләрдә дә актив катнашалар, колхозчыларны оештыру эшен алып баралар, авыл хуҗалыгы продуктларын (ит, йон, сөт, йомырка) хәзерләү эшеннән дә алар читтә калмый.




Өстәвенә төрле хисапсыз партия, комсомол порученияләре, ата- аналар белән эш, төнге дежур торулар .... Бу эшләр барысы да мәктәптән тыш эшкә өстәмә итеп бирелә. Бик тә авыр була ул чор авыл укытучыларына. Шуңа да карамастан, алар һәр эшне, бирелгән порученияне башкарырга үз вакытында зур җаваплылык белән башкарырга тырышалар.



**Әхмәтов Минегаян мәктәпне тәмамлаучы укучылар алдында**
*Июнь, 1980-ел*

Җәмәгать эшләрендә, халыкка культура хезмәтен күрсәтүдә бигрәк тә Хикматуллин Хаҗи, Назипова Гөлҗихан апалар башлап - оештырып йөрүчеләр булдылар.

Тагын бик еш була торган төрле җыелышлар, сессияләр, башкарма комитет утырышлары, партия-комсомол җыелышлары, партком, идарә утырышлары - барысы да укытучының болай даз булган вакытын алалар.



**Класс житәкчесе Шайхутдинова Ләлә 8 нче класс укучылары белән**

Тагын бер үзенчәлекле факт: ул чор укытучылары үзләренә алмаш та хәзерләп калырга тырышалар.Мәсәлән, Зарипова Рәшидә, Шайхутдинова Леналар ул һәм кызларына укытучы профессиясен сайларга юнәлеш бирәләр.

**Мәктәп директоры Ахметов Минегаян Мөхәммәт улы турында кыскача белешмә**

Туган елы – 30.12.935 ел.

Белеме – 1957 нче елда Минзәлә педагогия училищесын кызыл дипломга тәмамлый. Читтән торып Казан дәүләт университетында белем ала, аны да 1968 нче елда кызыл дипломга тәмамалый.

Диплом буенча белгечлеге – рус теле һәм әдәбияты укытучысы.

Эш стажы - 35 ел, педагогик стажы – 20 ел.

Педагогик эшчәнлекне 1960нчы елда Нарат башлангыч мәктәбендә башлый, аннары елдан артык Девятерня сигезьеллык мәктәбендә директор урынбасары булып эшли.

1964 – 1980 нче елларда мәктәп директоры булып эшли.

1980 нче елдан 1995 нче елга кадәр Девятерня авыл советы председателе вазифасын алып бара.

Бүләкләре:

1. 1974 нче елның 5 нче октябрендә Әгерҗе мәгариф бүлеге Мактау тактасына кертелә.
2. “халык мәгарифе отличнигы” билгесе белән бүләкләнә.(18.06.1975)
3. Почет грамотасы ( “Белем” җәмгыятенең Әгерҗе бүлекчәсе, 20.02.1976 нчы ел)
4. Почет грамотасы ( “Белем” җәмгыятенең Әгерҗе бүлекчәсе, 25.08.1976 нчы ел)
5. Почет грамотасы(КПСС Әгерҗе район комитеты, 09.12.1976)
6. Почет грамотасы(КПСС Әгерҗе район комитеты, 1986 нчы ел)
7. Почет грамотасы(КПСС Әгерҗе район комитеты, 02.02.1987 ел)
8. Почет грамотасы(Әгерҗе мәгариф бүлеге)
9. Рәхмәт хаты (“Белем” җәмгыятенең Әгерҗе бүлекчәсе)
10. “Ветеран труда”(18.11.1987 ел)
11. Почет грамотасы (КПСС Әгерҗе район комитеты, 06.02.1988)
12. Почет грамотасы(КПСС Әгерҗе район комитеты, 1988)
13. Почет грамотасы(КПСС Әгерҗе район комитеты, халык депутатларының район советы, 18.07.1988 ел)
14. Почет грамотасы(КПСС Әгерҗе район комитеты, халык депутатларының район советы, 1989 ел)
15. Почет грамотасы(КПСС Әгерҗе район комитеты, халык депутатларының район советы, 09.02.1990 ел)
16. Грамота (КПСС Әгерҗе район комитеты, 24.08.1990 ел)
17. Грамота (КПСС Әгерҗе район комитеты, халык депутатларының район советы, 1991 ел)
18. Рәхмәт хаты ( халык депутатларының район советы,22.07.1992)
19. Диплом (Әгерҗе район башлыгы, Әгерҗе районы авыл хуҗалыгы идарәсе, 10.07.199
20. Почет грамотасы (халык депутатларының район Советы, 30.12.1995

## 6 нчы бүлек.
## Девятерня авылы мәктәп тарихы, 1980-1982 еллар.
## (Мәктәп директоры Әхмәтҗанова Мөхтәрәмә Мөхәмәтдин кызы)



41нче номерлы Әгерҗе мәгариф бүлеге приказы нигезендә 1980 елның 04 июленнән -1982 елның 6 сентябренә кадәр (приказ номер 82 06.09.1982) Девятерня сигезъеллык мәктәбенең директор вазыйфасын башкару өчен Әхмәтҗанова Мөхтәрәмә Мөхәмәтдин кызы билгеләнә. Мәктәпнең директор урынбасары Гәүһәрия Рәхим кызы Шәймарданова , пионервожатый Гөлүсә Вәлиулла кызы Биктимерова була.



*1981нче елның 9 нчы мае. Мәктәп директоры Әхмәтҗанова Мөхтәрәмә Мөхәмәтдин кызы сугыш ветераннарын , тыл хезмәтчәннәрен , ата-аналарны һәм укучыларны җиңү бәйрәме белән котлый. Аның янында пионервожатый Гөлүсә Вәлиулла кызы Биктимерова.*

Мәктәп җитәкчелеге үзенең бөтен көчен, белемен укыту- тәрбия процессын камилләштерүгә , мәктәп реформасын тормышка ашыру проблемаларын эшкәртүгә , укыту-тәрбия процессындагы һәр яңалыкның, һәр башлангычның асылын өйрәнүгә, аларны укытучыларның практикаларында файдалануга юнәлдерә . Шулай ук җитәкчелек һәр уку елында тиешле кадрлар белән тәэмин ителүгә, ата-аналар, җәмәгатьчелек белән эшләүгә зур игътибар бирә. Балаларның режимны төгәл үтәүләренә ирешү өчен укытучылардан кичке вакытларда

дежурство оештырыла. Өлгерешләре түбән булган укучыларның өйләрендә булып , аларга өстәмә белем бирү планлаштырыла һәм үтәлә.

Нарат һәм Гали авылларыннан килеп укыган укучылар өчен интернат эшләвен дәвам итә. Интернат җитәкчесе Зиятдинова Гүзәлия апа ,тәрбияче Зиятдинова Гөлфия апа була. Укучылар өчен озынайтылган көн группасы эшли аның җитәкчесе Тукманова Зәйтүнә апа була.



*Математика укытучысы Әхмәтҗанова М.М. (уртада) 7 класс укучылары белән.*

Күп мәсьәләләрне хәл итүдә ул чорда мәктәп аты зур роль уйный. Ат мәктәп завхозы Садыйков Әхәт Шафикъ улы карамагында була. Башка транспорт булмау сәбәпле кышкы чорда ат белән еш кына укучыларны күрше авыл мәктәпләренә фән олимпиадаларына алып барыла.



*Математика укытучысы Әхмәтҗанова М.М. (уртада) 6 класс укучылары белән.*



Агач мәктәп утын ягып җылытыла . Утынны техничкалар үзләре трактор белән урманнан төяп алып кайталар һәм укучылар белән бергә аркылы кул пычкысы белән кисеп, ярып өеп куялар. Төнге сәгатъ 3 тә килеп мичләргә ягып , укучылар килгәнче классларны җылытып куялар. Техничкалар булып Валиева Гөлчирә, Газазизова Разия, Гайнуллина Рәшидә, Абдуллина Галимә, Низамова Фәрхиҗан, Рамазанова Рәхимә, Габдрахманова Люция апалар була. Мәктәп һәм интернат балалары өчен ашау пешерүчеләр Шакирова Гөлшат була. Библиотекарь Муратова Рәзилә.

Мәктәпне Әхмәтҗанова Мөхтәрәмә Мөхәмәтдин кызы җитәкләгәндә мәктәп һәр елны мәктәп яны тәҗрибә участогыннан мул уңыш алып , балаларны ел әйләнә яшелчә белән тәэмин итүгә зур игътибар бирә. Ул чорда Таҗиев Мулламехәммәт Гиляҗетдин улы , хезмәт укытычысы буларак тәҗрибә участогын җитәкли. Аның төгәллеге һәркемгә дә үрнәк була. Аның түтәлләренең тигезлеге, эшкәртелүе, эш коралларының тәртиптә булуы барсында таң калдыра иде. Укучылар район буенча конкурсларда алдынгы урыннарга лаек булалар.



1981-1982 нче уку елы. 4 нче класс укучылары класс җитәкчесе Гумерова (Камаева) Илүсә Касыйм кызы (өске рәттә уртада) һәм бер төркем укытучылар белән:
өске рәттә сулдан уңга: Гатауллина Гөлүсә, Рахматуллина Лена, Тазиев Мулламөхәмәт, Шаймарданова Гәүһәрия, Зиатдинова Гөлфия, Айдарова Фәзилә, Калимуллина Рәсимә.



1980 елның көзендә колхозның терлекчелек буенча механигы Айдаров Әхтәм Хәйдәр улы ярдәме белән мәктәпкә су кертелде. Бу мәсьәләне хәл итүдә дә Мөхтәрәмә Мөхәмәтдин кызының өлеше зур булды . Аңа кадәр мәктәп кое суы белән тәэмин ителде. Бу күп

мәсъәләләрне уңай хәл итәргә мөмкинлек бирде.  Шул елда мәктәптә эшкә яраксыз булган башмаклы тракторга район финанс бүлеге җитәкчелеге Коробейников ярдәме белән капиталь ремонт ясала һәм трактор күп төрле хуҗалык эшләрендә кулланыла башлый.

Мәктәп янында яңа хуҗалык бинасы төзелде. Аны интернатта торган балаларның постельләрен юу өчен кер юу бинасы итеп файдаланалар.

Мәктәп укучылары һәм укытучылары  авыл тормышында да актив катнашалар. Авылдашлары белән бергә төрле бәйрәмнәр  оештыралар.



**1981 нче елда "Авылымның бүгенгесе" дигән кичәдән соң укучылар мәктәп директоры Ахметзянова М.М. (сулда), чараны үткәрүче ШайхутдиновИ.Н. (уңда), К.Маркс исемендәге колхозның яшь алдынгылары Рамазанова Кәүсәрия, Загретдинова Фәния һәм Ахметзянова Рәйсәләр (уртада) белән.**

**1980 – 1982 елларда мәктәп директоры булып эшләгән Әхмәтҗанова  Мөхтәрәмә Мөхәмәтдин кызы турында кыскача белешмә.**

Туган елы -06.01.1945 ел.

Белеме –югары, Алабуга дәүләт педагогия институты, 1969 ел.

Дипломы буенча белгечлеге –математика-физика укытучысы.

Гомуми эш стажы -38 ел.

1969 нчы елдан 2007 нче елның 1 нче сентябренә кадәр Ләбиб Айтуганов исемендәге Девятерня урта гомумбелем бирү мәктәбендә математика фәнен укытты. Хезмәт юлының беренче елларында комсомол укулары алып барды.

1973 нче елда партия сафларына кереп, 1974-1990 нчы елларда мәктәп партоешма секретаре вазифасын алып барды. Эш дәверендә аның тырышлыгы белән тырыш укучылар математика буенча олимпиада-конкурсларның район һәм республика турларында уңышка ирештеләр. Күп кенә укучылар математика юнәлеше буенча югары уку йортларын тәмамлап , шул юнәлеш буенча хезмәт итәләр.

Бүләкләре:

1. Почет грамотасы (ВЛКСМның Әгерҗе район комитеты, 30.03.1972 ел)
2. Почет грамотасы (КПССның Әгерҗе район комитеты, 22.08.1973 ел)
3. Почет грамотасы (ТАССР Мәгариф министрлыгы, 29.06.1977 ел)
4. Почет грамотасы ( Әгерҗе мәгариф бүлеге, 24.08.1983 ел)
5. Почет грамотасы ( Әгерҗе мәгариф бүлеге, 26.05.1985 ел)
6. " Халык мәгарифе отличнигы" исеме ( Мәгариф министрлыгы, 07.05.1985 ел)

7. Республика почет кенәгәсенә кертелде (12.11.1987 ел)
8. Почет грамотасы (ТАССР Мәгариф министрлыгы, 08.04.1988 ел)
9. Почет грамотасы (халык депутаталарының Әгерҗе район советы президиумы, 1992 ел)
10. Почет грамотасы (Әгерҗе администрациясе , 25.08.1993 ел)
11. Почет грамотасы (Әгерҗе администрациясе , 23.08.1995 ел)
12. “Ветеран труда” (уд. № 328186, 15.10.1998 ел)
13. Почет грамотасы (Әгерҗе район башлыгы , 25.08.2000 ел)
14. Почет грамотасы (район администрациясе, 27.08.2001 ел)
15. Почет грамотасы (мәктәп администрациясе, 15.10.2005 ел)
16. Әгерҗе мәгариф бүлегенә 90 ел тулу уңаеннан юбилей медале.

**6 нчы бүлек.**
**1982-2000 елларда Девятерня мәктәбе. (Мәктәп директоры Галиев Рамил Әхмәт улы, 1996 елдан 2000 елга кадәр Галиева Әлфия Хәсән кызы).**





1982 елның 15 августыннан мәктәп директоры булып Актаныш егете Галиев Рамил Әхмәт улы билгеләнде. Аның иптәше Галиева Әлфия Хәсән кызы, Салагыш авылында туып үскән, рус теле укытучысы булып эшли башлый. Бу вакытта өлкән буын укытучылары Абдуллина Әлфия Фатыйх кызы, Тазиев Мулламөхәммәт Гыйләҗетдин улы үз эшләрен яратып башкаралар. Үз эшенә бирелгән Шаймарданова Гәүһәрия Рәхим кызы намус белән уку-укыту эшләре буенча директор урынбасары булып, бөтен көчен куеп, армый-талмый хезмәт итә. Бай эш тәҗрибәсе белән район, республика күләмендә уртаклаша, яшь буынга нәтиҗәле белем бирү серләрен өйрәтә, үзе дә новатор укытучыларның эш алымнарын бик теләп өйрәнә, район күләмендә "Көмеш каләм" конкурсын оештыручы, инициаторы булып тора. 1985 елда Гәүһәрия Рәхимовнаны мәгариф өлкәсендәге югары мөмкинлекләрен һәм сәләтен исәпкә алып Әгерҗе районы мәгариф бүлегенә методик кабинет җитәкчесе итеп эшкә алалар, ул анда 1991 елга кадәр эшли, соңрак Иж-Бубый урта мәктәбендә, аннан соң 1 номерлы Әгерҗе шәһәр мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшли.1987 елдан Халык мәгарифе отличнигы, 1995 елдан Татарстан Республикасының атказанган укытучысы, бик күп методик эшкәртмәләр авторы, Республика күләмендә профессиональ конкуслар җиңүчесе, Республика һәм район олимпиадалары призерларын әзерләүче булды. Хәзерге вакытта лаеклы ялда. Математика фәнен бик көчле укытучылар Мөхтәрәмә Мөхәммәтдин кызы Әхмәтҗәнова, Шәйхетдинова Лена Габдулла кызы алып бара. Укытучылар Шайхутдинов Илдус Нургаян улы, Гумерова Илюсә Касыйм кызы, Биктимирова Гөлүсә Вәлиулла кызы, Кәримуллина Рәсимә, башлангыч сыйныфларда Әхметова Мәүгыйдә Габденур кызы, Гимашева Галия Габдулла кызы җаваплы һәм авыр педагог хезмәтен тырышып башкаралар.

1985-1995 еллар илебез тарихына "үзгәртеп кору" исеме астында кереп калды. Бу вакытта башында М. С. Горбачев торган ил җитәкчелеге икътисади һәм социаль-сәяси реформалар ярдәмендә социализмны яңартырга омтылыш ясады. Үзгәрешләрнең гомуми нәтиҗәсендә суверентлашу процесслары башланды, СССР таркалды, иҗтимагый строй алышынды. Татарстанда да суверен дәүләт статусы алу процессы тормышның барлык өлкәләрендә, шулай ук мәктәпләр эшчәнлегендә дә чагыла. Татар Иҗтимагый Үзәге (ТОЦ) эшчәнлеге эшендә Татарстанга суверен дәүләт статусы бирү теләге белән безнең мәктәп укытучылары да актив катнашты: 22 укытучыдан 20 укытучы, 12 тех.персонал (барысы да) имза җыю барышында катнаштылар, 100 гә якын авыл кешесеннән имза җыелды.

Бу чорда базар икътисадына керү шартларында мәктәпләр авыр матди хәлдә калалар. 1992 елда “Татарстан Республикасы телләре турында” Закон гамәлгә керә. Бу закон һәм “Мәгариф турында” Татарстан Республикасы Законын кабул итү мили мәктәпләр үсешенә этәргеч була.



Шундый кызыклы һәм катлаулы чорда да мәктәптә эш кайный: Нарат һәм Галидән килеп укучы балалар өчен мәктәп яны интернаты эшли. Анда тәрбияче Зиятдинова Гөлфия, төнге няня Гиляҗева Хәлимә апалар эшли. Аннан соң Загретдинова Рәмзия, ә аны алыштырып тәрбияче булып Зиятдинова Гүзәлия апа эшли башлый. Бик оста җырчы Гүзәлия апа соңнан музыка укытучысы булып китә. Рус теле укытучысы булып Арсланов Зиннур абый эшли башлый. Китапханәдә Абдуллина Әлфия Фатих кызы эшли. Пионервожатый Шәрәфетдинова Гүзәл була.

Техничкалар сәгать төнге өчтән килеп, кышкы суыкларда мичкә ягып, балалар килүгә классларны әзерлиләр.

1984 нче елны Муратов Камил Нургаян улы лаборант булып мәктәптә эшли башлый. Бу елларны Багаутдинова Гөлия Мәгьсүм кызы, Даутова Әлфия Әзгәр кызы, Ямалиева Илзирә Илгиз кызы, Мөсифуллина Рәсимә Хәсән кызы, Сәхәбутдинова Резида Мөнәвир кызы, Мулланурова Ләйсирә Вәгыйз кызы, Ситдикова Вәсилә Илгиз кызы, Хуҗина Гүзәлия Сабирҗан кызы, Мөсифуллина Нурия Шамил кызы, Мөсифуллина Әлфинур Фәйзулла кызы, Гиззатуллина Илюсә Шамил кызы Девятерня мәктәбендә белем бирәләр.

Мәктәптә озак еллар буенча авылыбызның абруйлы кешесе, Девятерня авыл советы секретаре булып эшләгән, дүрт бала анасы, үрнәк эни, сәләтле оештыручы Ситдикова Гөлсинә Мирфаяз кызы эти-әниләр рәисе булып эшләде. Аның җитәкчелегендә мәктәптә бик күп проблемалар чишелде, эти-әниләр комитеты һәрвакытта мәктәп администрациясе белән тыгыз элемтәдә эшләп укытучылар коллективына укыту-тәрбия эшендә зур булышлык күрсәтте.

1985 елдан Девятерня сигезьеллык мәктәбе урта мәктәп статусын ала.



*1986 елда Девятерня мәктәбе укытучылары*

Шушы елларда ТАССР Югары Советы депутаты, Әгерҗе районында иң алдынгы колхоз председателе Камалиев Әхәт абый ярдәме белән 320 укучыга исәпләнгән ике катлы типовой яңа мәктәп төзелә башлый. Шул елларда эшләгән укытучылар, укучылар да мәктәп төзелешенә үзләреннән зур өлеш кертәләр, армый-талмый эшлиләр. Өлкән класс укучылары җәйге каникулда һәм укудан бушаган арада үз теләкләре белән мәктәп төзелешендә эшләп беренче тапкыр үз хезмәтләре өчен хезмәт хакы алдылар. Күп еллар үткәч тә аларның күбесе мәктәптә беренче хезмәт чыныгуы үтүләрен горурланып искә алалар. (Бүгенге көндә Удмуртиянең Сарапул шәһәрендә эре предприятие җитәкчесе Хайдаров Фәнис Рафис улы сөйләгәннәрдән). Мәктәп 1989 елда тапшырыла. Мәктәп директоры Галиев Рамил Әхмәт улы мәктәпне өр-яңа мебель, җиһазлар, станоклар, спорт җиһазлары һәм башка инвентарь белән тулыландыруга зур көч куя.

1983-84 нче уку елында Лотфуллина Фәнүзә, 1987-88 нче уку елында Мингазова Раушания (7 класс) Бөтенсоюз “Орленок” пионер лагерында булуга ирешәләр. 1988 нче елны Ситдикова Алфира Республика Идел яшьләр лагерында була. Бу елларда мәктәпнең уңышлары күп була. 1995 нче елда Галиева Ләйсән мәктәпне алтын , ә Арсланова Алсу көмеш медаль белән тәмамлыйлар.



Лотфуллин Фирдәт география буенча (укытучысы Шайхутдинов), Гатауллина Лилия биология буенча (укытучысы Гатауллина), 7 нчы сыйныф укучысы Ямалиев Илзур 1986-1987 нче уку елында математика буенча район олимпиадасында I урын яулап (укытучысы Әхмәтҗәнова), республика олимпиадаларында катнашып мәктәп данын яклыйлар. Ул елларда уку елы барышында "Аҗаган" уеннары, туристик походлар биатлон һәм башка ярышлар системалы оештырылды.

"Кызыл кәнәфер" туристик группасы география укытучысы Шайхутдинов И. Н. җитәкчелегендә мәктәп данын яклап берничә тапкыр республика слетында катнашты һәм туризм техникасы, туристик җырлар номинацияләре республика буенча җиңү яулады. Мәктәп укучылары Габдулла Тукайның 100 еллыгына багышланган бәйгеләрдә, "Көмеш һәм Алтын каләм" конкурсларында катнашып зур уңышларга ирештеләр, Ләйсән Галиева Казан-Астрахань маршруты буенча экскурсиядә булып кайта.

1986 нчы елдан Шарипов Фәнис Фазыл улы мәктәптә педагогик эшчәнлеген башлый, башта хезмәт, рәсем, физика фәннәрен укыта, соңрак военрук булып эшли, лейтенант званиеле укытучы авыл балаларын хәрби хезмәткә әзерләү буенча кыска гына вакыт эчендә районда иң дәрәҗәле военрук булып таныла, ул эшләгәндә мәктәптә өлкән класс егетләре белән стройга әзерлек иртәнге 7 дән башлана иде. Ел әйләнәсендә мәктәптә хәрби-патриотик юнәлештә нәтиҗәле эш алып барылды, барлык чаралар нәкъ армиядәге кебек төгәл оештырылды, һәрвакыт офицер формасыннан йөрүче Фәнис укучы балаларга гадел, таләпчән булды, балалар абыйларына тартылдылар, чөнки егетләргә мондый эш формасы бик ошый иде. Соңыннан да ул елларда мәктәптә укыган егетләр армия сафларында хезмәт иткәндә: «Безне Фәнис абый күп нәрсәгә өйрәткән, шуңа безгә җиңелрәк булды. Рәхмәт аңа,» - дип язалар иде. Хәзер дә, очрашкан саен, элеккеге укучылары, Фәнис абыйлары янына килеп, мәктәп елларын искә төшерәләр. Алтын куллы оста НВП кабинетын барлык таләпләргә туры китереп җиһазлады, мәктәпне җиһазлауга үзеннән күп көч куйды, күп еллар мәктәп советы рәисе булды.

1986 нчы елның июнендә бер төркем укучылар өчен Украинага экскурсия оештырыла.

1989 нчы елның җәендә ике группа укучылар "Нальчик- Пятигорск- Домбай" маршрутлары буенча ял итеп кайталар. 1990 нчы елның язында Фаррахов Флюр, Тазиев Рамил, Кәримова Рәфидә җитәкчелегендә балалар Ленинград шәһәрендә экскурсиядә булалар.



**1990 нчы елның апрель ае. Девятерня урта мәктәбеннән 34 укучы укытучылар Тазиев Рамил, Фаррахов Флүр, Каримова Рафидәләр җитәкчелегендә Ленинград шәһәренә экскурсия вакытында эрмитаж каршында.**

Балаларга белем һәм тәрбия бирүдәге уңышлары өчен мәктәп директоры Галиев Рамил Әхмәт улы 1994 нче елны Татарстанның атказанган укытучысы исеменә лаек була.

1995-96 нчы уку елында мәктәп, колхоз агрономы Мингазов Минегаяз ярдәме белән, 50 гектар җир алып ашлык үстерә. Девятерня җирле үзидарә советының 27 октябрьдә чыккан 10 № лы карары, Әгерҗе районы башлыгы Белов Иван Алексеевич рөхсәте һәм райкомзем рәисе Салахеев К. А. Ның 31 октябрендә чыккан карары нигезендә. 50 гектар җирдән 780 ц уңыш җыеп алына. 335 ц бартер өчен тотыла, 445 ц складта кала. Очсыз бәядән укытучыларга һәм мәктәптә эшләүчеләргә сатыла.

1995 нче елда Татарстан җөмһүриятенең Яр Чаллы шәһәре “Әбүзәр” мәчете каршындагы мәдрәсәдә укып, №77 шаһәдәтнамә алган имам-хатыйп, мәзин һәм мөгаллим Залилов Илфат Котдус улы балаларга төрле классларда гарәп теле укыта, ислам дине тәрбиясе бирүдә зур роль уйный.

1996 нчы елның көзендә Рамил Әхмәт улы “Игенче” колхозы рәисе булып сайлана. 1996 нчы елдан 2000 нче елга кадәр мәктәп директоры булып Галиева Әлфия Хәсән кызы эшли.

Эш план буенча алып барыла. Укытучылар бөтен энергия һәм көчләрен кызганмыйча балаларга төпле бирем бирәләр, район һәм республика күләм ярышларда катнашалар. Пионервожатый Рәсимә Мөсифуллина дружина эшен җанлы һәм кызыклы итеп алып барырга тырыша. Балалар пионерлагерьларда, хезмәт һәм ял лагерьларында сәламәтлекләрен ныгыталар. Район һәм зона семинарлары да һәрдаим булып тора. Бу елларда күренекле, сәләтле ветеран укытучы Әхмәтҗанова Мөхтәрәмә Мөхәммәтдин кызы үз үрнәгендә үз балаларына укытучы профессиясен сайларга юнәлеш бирүе нәтиҗәсе буларак, Әхмәтҗанова Эльмира Рәис кызы һәм Әхмәтҗанов Ленар Рәис улларының хезмәт эшчәнлекләре башлана.

Әхмәтҗанова Эльмира Рәис кызы Арча педагогия көллиятендә укыганда практикага Девятерня мәктәбенә кайтты. Аның практика чорына район завучлары семинары туры килде. Ул килгән кунакларга йөгерек уку буенча ачык дәрес һәм “Ритмика” түгәрәге эшчәнлеген күрсәтте. Кунаклар аның эшчәнлегенә югары бәя бирделәр. Ә 1994-95 нче уку елында үз мәктәбенә эшкә кайтып, 7 нче һәм 11 нче классларда татар теле һәм әдәбияты, тарих фәннәрен укытты һәм организатор вазыйфасын башкарды. (Ул чорда пионервожатый дип йөртелмәгән.) Шул елны “Ел укытучысы” бәйгесендә катнашып, призер исеменә лаек булды, плед белән бүләкләнде.

Әхмәтҗанов Ленар Рәис улы Арча педагогия көллиятенең музыка бүлеген тәмамлап (1993-1998 нче елларда укыды), үз мәктәбенә эшкә кайта.

1998-2004 нче елларда тарих, музыка дәресләрен алып бара. Укучылар аны яраталар һәм хөрмәт итәләр. Ул үз эшенә һәрвакыт намус белән карый. Музыка һәм тарих буенча ачык дәресләр бирә. Класстан тыш чаралар үткәрүдә зур тырышлык куя. “Яшь педагог мәктәбе”ндә чыныгу алып, укучылары, өлкән хезмәттәшләре, ата-аналар арасында абруй казанган яшь педагог Ленар Әхмәтҗанов 2002 нче елда I категорияле укытучы исеменә лаек була. Үз белемен күтәрү өстендә эшләп, 1999-2004 нче елларда Чаллыда читтән торып укый, югары белемгә лаек була. Ленар Әхмәтҗанов музыка буенча авторлык программасы эшләп, аның эше уңай бәяләнә.

1995 елның августыннан1996 елның сентябренә кадәр педорганизатор һәм татар теле, әдәбияты укытучысы булып Шәрипова Әлфия Илфат кызы эшли, аннан соң Девятерня балалар бакчасы мөдире булып икенче эшкә күчерелә.

1997 елның 6 июнь төнендә сабантуй буласы көн алдыннан җаваплы кешеләрнең саксызлыгы аркасында мәктәпнең 1932 елда төзелгән агач типовой бинасы һәм аның эчендәге барлык уку әсбаплары, байлыклар янып мәктәпкә зур күләмдә зыян килде, чөнки иске бина склад хезмәтен үтәде һәм яңа җиһазларның күп өлеше анда сакланды, шулай ук иске мәктәпнең икенче башында урнашкан леспромхозның ярдәмче хуҗалыгы да янып юкка чыкты.

**7 нче бүлек.**

**2000-2010 еллар, 21нче гасыр башы – хезмәттәшлек, бергәләп җитәкчелек итү чоры.**

**(Мәктәп директоры Шайхутдинов Илдус Нургаян улы).**



Директор - Шайхутдинов Илдус Нургаян улы, югары категорияле җитәкче, III дәрәҗә Хезмәт Даны ордены кавалеры, ике тапкыр ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы грамотасы белән бүләкләнгән, "Мәгарифтәге казанышлары өчен", "Почетный работник общего образования РФ" дәрәҗәсе (звание) иясе.



Муратова Галия Габдулла кызы – укыту-тәрбия эшләре буенча директор урынбасары, югары категорияле җитәкче, РФ Мәгариф һәм фән министрлыгы грамотасы белән бүләкләнгән, "Мәгарифтәге казанышлары өчен" күкрәк билгесе иясе, Татарстан Республикасының атказанган укытучысы.



Гатауллина Гөлүсә Вәлиулла кызы - тәрбия эшләре буенча директор урынбасары, югары категорияле җитәкче, "Почетный работник общего образования РФ" билгесе иясе.

2000 елда, мәктәп директоры Галиева Әлфия Хәсән кызы гаиләсе белән Актанышка күченеп киткәч, коллектив фикерен исәпкә алып, инде күпьеллык педагогик тәҗрибәсе һәм шактый казанышлары булган, энергияле укытучы Шайхутдинов Илдус Нургаян улына шушы җаваплы вазифа йөкләнә. Укыту эшләре буенча директор урынбасары шулай ук тәҗрибәле педагог Муратова Галия Габдулла кызы, тәрбия эшләре буенча урынбасар Гатауллина Гөлүсә Вәлиулла кызы, мәктәп профсоюз оешмасы җитәкчесе Муратов Камил Нургаян уллары ярдәмендә эшлекле, компетентлы команда туплап, Илдус Нургаянович җиң сызганып эшкә керешә. Эшчәнлек бар юнәлештә дә бик киң җәелдерелә. Мәктәп җәмгыять ихтыяҗларын һәм дәүләт интересын күздә тотып авыл мәктәбенә генә хас булган күп төрле кыенлыкларны җиңә барып, яшь буынны укытуны, аңа нәтиҗәле тәрбия бирүнең сыйфатын күтәрү өстендә уңышлы хезмәт куя; шул ук вакытта авылыбызга гына хас булган үзенчәлекләрне, авылыбызда яшәүчеләрнең ихтыяҗларын, мәктәптә эшләүче укытучы-тәрбиячеләрнең мөмкинлеген исәпкә алып үз сукмагын булдырырга тырыша. Мәктәп югары профессиональ компетентлы, күпчелек үз мәктәбебезнең элеккеге укучылары булган педагоглар белән тулыландырыла, мәктәпнең үсеш Программасына нигезләнеп, белем бирү шартлары камилләштерелә, мәктәп белән идарә итү, методик эш, укучылар үзидарәсе системасы үзгәртелә. Мәктәптә Мәктәп Советы, Попечительләр советы, әти-әниләр комитеты, “Кеше һәм җәмгыять», «Кеше һәм табигать” үзәкләре, укучыларның “Йолдызлык” үзидарәсе уңышлы эшләп китә, иң әһәмиятле мәсьәләләр, стратегик юнәлешләр, төп проблемаларны өлкән класс укучыларын, укытучылар, әти-әниләр, җәмәгатьчелек һәм администрацияне эченә алган конференциядә хәл итү практикага керә. Мәктәптә укытуның профиль алды һәм профиль юнәлешен ачыклау, 75 еллык юбилей үткәрү, укучылар формасын кабул итү, инновацион эш юнәлешләрен билгеләү, эзләнү-тикшеренү, проект эшләрен ачыклау, күпсанлы экскурсияләрнең юнәлешен һәм графигын ачыклау һәм башка шундый приоритет юнәлешләр мәктәп конференциясендә ачыкланды, хәл ителде. Мәктәптә коллегиаль җитәкчелек итү, хезмәттәшлеккә юнәлтелгән эш системасы булдырылды. Коллектив укыту-тәрбия процессын туган якны өйрәнү, сәламәтлекне саклау, фәнни-тикшеренү һәм проект эшләрен, электрон мәгълумати чаралар белән эшли белү күнекмәләрен үзләштерү, инновацион эшчәнлек юнәлешләре белән бәйләп алып барды. Фәнни-тикшеренү эшләреннән “Кеше һәм әйләнә тирәлекнең экологиясе”, “Туган якны өйрәнү”, “Мәктәп тәҗрибә участогында фәнни тикшеренү эшчәнлнеге” юнәлешләре төп юнәлешләр булып тордылар.

Мәктәп яны тәҗрибә участогына яшь биолог Габбасов Айнур Габделнур улы мөдир итеп билгеләнә. Мәктәпнең тәҗрибә участогында рекультивация үткәрелә, зур эшләр башкарыла. Тиз арада территория бик күп кирәксез чаган агачларыннан арындырыла, аларның төпләрен әрчеп Нарат фермер хуҗалыгы рәисе Юсупов Фәнис Минефаяз улы ярдәме белән элеккеге колхоз фермасы яныннан бик күп күләмдә черемә ташыла, 1997 елда янган иске мәктәп калдыклары, бик күп мичләрнең һәм мәктәпнең үзенең фундамент калдыклары чистартыла, Красный Бор энергосеть хезмәткәрләре һәм Әгерҗе леспромхозының Девятерня лесоучастогы эшчесе

Муллахметов Рафаэль ярдәме белән янган мәктәп территориясе кирәксез электр баганалары, башка кирәкмәгән каралтылардан арындырыла. Мәктәп җитәкчелеге Можга питомнигы, Удмурт дәүләт университеты, Ижевск авыл хуҗалыгы академиясе һәм академия каршындагы Завьялово селекция үзәге галимнәре белән тыгыз эшлекле элемтә урнаштыра. Бакчадагы барлык культураларның элитар сортлары булдырыла, бакчага йөзләрчә төп алма, карлыган һәм башка агач һәм куаклар утыртыла. Берничә ел эчендә бакча һәр ел саен 50-70 мең күләмендә чиста табыш бирә башлый. Шушы акчага мәктәпкә трактор алына, бакча эшләрендә ул зур ярдәмчегә әйләнә, балаларны ел әйләнәсендә бушлай витаминлы экологик чиста яшелчә, җиләк-җимеш белән ашату мөмкинлеге туа.



**Мәктәп участогының матурлык, финанс, витаминлы продукция чыганагы икәнлеген участок мөдире Габбасов Айнур нигезли.**

Мәктәпнең материаль-техник базасы ныгый: спонсорлар ярдәме белән УАЗ-3162 микроавтобусы, ДТ-75 тракторы алында. Районда беренчеләрдән булып моңа кадәр Нарат һәм Гали авылларыннан җәяү йөргән укучыларны ташу оештырылды, мәктәбебезнең элеккеге укучысы Әгерҗе нефтебазасы җитәкчесе Роберт Габдулла улы Садыйков мәктәпкә һәрвакыт бензин, солярка белән булышып торды, кирәк вакытта акча яки башка төрле формада булышу җаен тапты. Укучыларны иртә яздан витаминлы азык белән тәэмин итү максатын күздә тотып, 2 теплица төзелә, заман таләпләренә туры китереп уку кабинетларының күбесе яңадан җиһазландырыла. Canon копироваль аппараты, Samsung видеокамерасы, телевизор, LG видеомагнитофоны, 3 аудиомагнитофон, ксерокс, факс, проекторлар һ.б. техник җиһазлар сатып алына, музыка укытучысы Әхмәтҗанов Ленар Рәис улы җитәкчелегендә күрше авылларда концерт программалары оештырып синтезатор сатып алына, укучыларга физкультура дәресләрендә йөрү һәм ярышларда катнашу өчен пластик чаңгылар, теннис өстәле булдырыла. Мәктәптә һәм авылда пожар машинасы булмау сәбәпле район башлыгы Габбасов Фәрит Гарифович ярдәме белән 2007 елда иске бензовоз базасында пожар машинасы алына һәм аңа җылы гараж булдырыла, ул бүген дә авылга, халыкка хезмәт итә. Коллектив мәктәп проблемаларын хәл итү өчен кирәкле булган бюджеттан тыш средстволарны булдыруның күп төрле юлларын табарга тырыша: попечительләр советы, әти-әниләр комитеты ярдәме, мәктәп яны тәҗрибә участогында җитештерелгән продукцияне сату, мәктәптә оештырылган “Малыш” минифермасы җитештергән продукцияне реализацияләү, спонсорлар һәм иганәчеләр ярдәме, мәктәп тракторларының һәм автомобиленең авыл халкына түләүле хезмәт күрсәтүеннән, мәктәп территориясендә Әгерҗе леспромхозы Девятерня лесоучастогының агач үсентеләре питомнигына хезмәт күрсәтүдән, укучылар белән лагерь вакытында дару үләннәре, агач бөреләре җыеп тапшырудан, авылда, басу-кырлардан металлолом җыеп тапшырудан мәктәпнең

күп төрле ихтыяҗларын канәгатьләндерергә мөмкинлек табыла. 2001 елда Нарат авылыннан килеп укучы Җәләев Алмаз һәм Абдуллин Расихлар металлолом җыю буенча иң актив укучылар булып 3әр тонна металл тапшыралар. Мәктәп коллективының күпкырлы эшчәнлегенә район җитәкчелеге, район финанс бүлеге (җитәкчеләре Мусин Э.М., Бадахшин А.Н.лар), район мәгариф бүлеге җитәкчелеге уңай бәя бирәләр, һәрвакыт мөмкин булган кадәр булышалар. 2001 елның июнендә Әгерҗе районы халык депутатлары Советының күчмә президиум утырышы район советы рәисе Сәетов Рәфис Фәритович җитәкчелегендә Девятерня авыл советы җирлегендә мәктәпнең актлар залында үткәрелә, анда мәктәп директоры Шайхутдинов И.Н. авылның социаль-икътисади хәлен күтәрүнең юллары, мәктәпнең проблемалары буенча чыгыш ясый, мәктәпнең 75 еллык юбилеен үткәрү тәкъдимен кертә. Президиум членнары, район җитәкчелеге эшчәнлеккә уңай бәя бирәләр, әйтелгән тәкъдимнәрне хуплыйлар.

2002 нче елның 15 нче июнендә авылыбыз һәм мәктәп тарихында истәлекле зур вакыйга – мәктәбебезнең 75 еллык зур юбилее билгеләнеп үтелә. Дөресен әйткәндә, авылыбызда мәгариф, уку-укыту йортларының барлыкка килүе һәм үсеше 75 ел элек, ягъни 1927 нче елда гына башланмаган. Сүз яңа типтагы авыл укучыларын масса төсендә белем алырга мөмкинлек биргән совет мәктәбе турында бара. 1927 нче елга кадәр дә авыл тоташ надан һәм мәктәпсез булмаган! Бу турыда авторлар тарафыннан хронологик рәвештә алдарак язып үтелде.

Тормышта да, мәктәптә дә бәйрәмнәр күп була. Ләкин юбилей аеруча үзенчәлекле, күп елларга бер генә тапкыр килә торган, күпләрнең гомергә күңелләрендә кала торган олы бәйрәм. Шулай ук мәктәпкә, анда укучыларга район һәм башка җитәкчелекнең игътибарын җәлеп итеп мәктәп коллективы алдында торган проблемаларны хәл итү, мәктәпнең матди һәм финанс хәлен савыктыру, мәктәпнең абруен күтәрү өчен югары әзерлектә үткәрелгән юбилей чаралары зур әһәмияткә ия. Мәктәп дирекциясе һәм “юбилей авыруы” белән авырган мәктәп коллективы бу әһәмиятле чараны үткәрүгә бөтен көчләрен бирәләр. Әзерлек эшләре ел ярым элек үк башланган бу эшкә укытучылар коллективы күпчелек эшне үз өсләренә алуга карамастан, барлык әти-әниләрне, укучыларны, якын-тирәдәге предприятие җитәкчелеген, мәктәптә укыган элеккеге укучыларны һәм район җитәкчелеген тартырга тырышыла. Шундый эшчәнлек нәтиҗәсендә мероприятие район чарасы статусын ала, 21 кешедән торган район җитәкчелеген, мәктәп администрациясен һәм укытучыларны, әти-әниләрне, авыл җәмәгатьчелеген эченә алган комиссия тарафыннан 75 еллык юбилейга хәзерлек чаралары планы, юбилейны әзерләү һәм үткәрү өчен чыгымнар сметасы төзелә һәм Әгерҗе районы хакимияте башлыгы Сәетов Рафис Фәритович тарафыннан расланып, юбилейны үткәрү турында Район башлыгының аерым карары чыга. (Кушымтага теркәлә ).



Бер ел эчендә комиссия членнары, укытучылар, мәктәп советы (җитәкчесе Шәрипов Фәнис Фазылович) тарафыннан зур эшләр башкарыла. Шәрипов Ф.Ф. тарафыннан юбилейны үткәрү урыны (Комсомолка бакчасы), мәктәпнең тышкы ягы, мәктәпкә керү урыннары (капкадан башлап), ашханә, спортзал, рекреация, коридорларны үзгәртү, бизәү эскизлары эшләнә һәм кайбер үзгәрешләр белән чагыштырмача кыска вакыт эчендә тормышка ашырыла. Мәктәп эчке һәм тышкы яктан үзенең төсен үзгәртә, матурая. Мәктәп эчендә хезмәт укытучысы Фаррахов Флүр Ромим улы көче белән мәктәпнең үткәнен һәм бүгенгесен чагылдырган, зәвык белән эшләнгән стендлар барлыкка килә. Мәктәпнең өске коридорында мәктәп барлыкка килгәннән башлап юбилейга кадәр булган вакыт эчендә мәктәптә 25 ел һәм аннан да күбрәк эшләгән мөгаллимнәрнең зур фотопортретлары һәм алар турында кыскача мәгълүматны эченә алган "Мәңгелек хөрмәт тактасы", укучыларның, укытучыларның, техник хезмәткәрләрнең фидакарь хезмәтләрен, уңышларын яктырткан стендлар 14 ел буена - 2016 елда булган мәктәпнең капиталь ремонтына кадәр - тордылар.



*Мәктәп "Кремле"Казанның 1000 еллыгына әзерлек барышында эшләнде*

Юбилейга бәйле күп төрле чыгымнарны каплау өчен район җитәкчелеге ярдәменнән тыш спонсорлар ярдәме оештыру уңышлы була. Юбилейны әзерләргә, оештырырга, үткәрергә ярдәм итәрлек авылыбызда һәм якын-тирә торак пунктларда – Тирсә, Исәнбай, Сарапул, Әгерҗе, Ижау, Чаллы, Түбән Кама, Казанда яшәүче якташларыбыз ачыклана, аларга хәбәр ителә һәм күбесеннән финанс ярдәме алына. Комсомолка бакчасында сәхнә, скамейкалар, бизәкле металл койма-капкалар эшләнә. Биолог Габбасов А.Г. җитәкчелегендә чәчәк клумбалары булдырыла, күп итеп декоратив агач һәм куаклар утыртыла, иске янган мәктәп калдыклары чистартылып, аның урынында завхоз Файзуллин Р.Ф. җитәкчелегендә теплица төзелә һәм юбилейны үткәрү көнендә анда пешкән помидорлар матурлык һәм ямь биреп торалар иде. Мәктәп участогы чаган агачларыннан арындырылгач, чәчәкләргә күмелә. Тәҗрибә участогы матурлыгы, тәртибе белән кунакларны үзенә чакырып тора иде.



*Мәктәп бакчасындагы “Альп таулыгы”*

Мәктәпнең барлык ремонт сорый торган өлешләре ремонтланып, буялып, 2002 нче елның 15 нче июненә кунаклар каршылауга әзер иде, бүлмәләрне, коридорларны матур гөл чүлмәкләрендәге гөлләр бизәде һ.б.

Мәктәп советы утырышларында кунакка чакырылырга тиешле кешеләрнең исемлеге төзелә һәм мәктәпнең укыту-тәрбия эшләре буенча директор урынбасары Муратова Г.Г. җитәкчелегендә секретарь Фаррахова Рәйсә ярдәме белән һәрбер кунакка тирән эчтәлекле, тәэсирле чакыру хатлары язып җибәрелә. Алар арасында мәктәбебезне төрле елларда тәмамлап чыккан мәртәбәле кунаклар, район һәм республика күләмендә күренекле җитәкчеләр һәм шәхесләр бар иде. Мәктәпнең визит карточкасы булдырыла, пенсионер укытучылар Айдарова Мәүгыйдә Хайдаровна, Ахметов Минегаян Мухаметович, Хикматуллин Хаҗи Хикматуллович, хезмәт һәм сугыш ветераны Фаррахов Сабир абый һәм сугыш ветераны Шәрипова Ракыя апалар тырышлыгы белән мәктәп тарихын тулыландыру буенча күп эш башкарыла.



*Мәктәп юбилее мизгеле*

Мәктәп тарихына бәйле рәвештә укыту һәм тәрбия эшләре буенча директор урынбасарлары Муратова Г.Г., Гатауллина Г.В., рус һәм татар теле укытучылары Шәрипова

Ә.А., Шәрипова Г.М., җыр укытучысы, һәвәскәр композитор Әхмәтҗанов Л.Р. тырышлыклары белән үзенчәлекле эчтәлекле музыкаль номерлар, котлаулар белән чиратлашып барган юбилейны үткәрү сценарие төзелә. “Тугызбуй” төркеме тарафыннан концерт әзерләнә.

Шулай ук Девятерня мәктәбе турында һәм кунакларны юбилей кичәсенә чакырып, Казаннан Татарстан радиосы аша мәктәп директоры 15 минутлык чыгыш ясый. Ижау каласыннан җирле телевидение чакырыла, республика һәм район газеталары аша кунакка чакырып белдерүләр бастырыла. Мәктәбебезнең иң матур тавышлы күренекле дикторлар дәрәҗәсендә матур интонацияле итеп сөйләүче укытучылар Шәрипова Ә.А. һәм Әхмәтҗанов Л.Р.га алдан әзерләнгән сценарий буенча кичәне алып бару йөкләнә.

Иртәнге 8 дән 20 сәгатькә кадәр булган программа кунакларны каршы алу, иртәнге чәй, мәктәп белән танышу, 15 сәгатькә кадәр тантаналы өлешне, төшке ашны, Министрлык, район мәгариф бүлеге һәм башка мәгариф хезмәткәрләрен эченә алган түгәрәк өстәл артында эшлекле сөйләшү (авыл мәктәпләрен реструктуризацияләү турында), “Тугызбуй” төркеме чыгышын һәм башка чараларны эченә алган программа төзелә.

2002 нче елның 15 нче июнендә мәктәпкә әкренләп халык агыла башлый. Башта мәктәп укытучылары, хезмәткәрләр, укучылар, аннан соң мәктәбебезгә әзме-күпме бәйле булган мәртәбәле кунаклар җыела. Алар арасында район хакимияте башлыгы Сәетов Рәфис Фәрит улы, Татарстан республикасы мәгариф министрлыгыннан Габидуллин Фәрит Калимулла улы, язучылар, телевидение хезмәткәрләре, мәктәбебезне тәмамлап чыккан күренекле шәхесләр, район администрациясе вәкилләре, мәгариф бүлеге делегациясе, пенсионер укытучы һәм хезмәткәрләр, төрле елларда мәктәпне тәмамлаган укучылар, авыл халкы бар иде. Аларны күңелле музыка, бизәлгән, чәчәккә күмелгән, буяп-чистартылган мәктәп, сәләтле татар теле һәм әдәбияты укытучысы Шәрипова Гөлия Мәгъсүм кызы иҗат иткән һәм мәктәп стенасына беркетелгән канатлы сүзләр каршы алды:

“Читкә китеп туган төбәгеңнән
Аерылса да тормыш юллары.
Син онытма очар канат куйган
Белем биргән мәктәбең барын”.



Мәктәпнең 75 еллык юбилее мизгеле.
Алгы планда уртада район хакимияте башлыгы Сәетов Рәфис Фәрит улы.

Быргы һәм барабан тавышлары бәйрәмнең башлануын белдерә һәм матур итеп киенгән, кулларына чәчәкләр, ленталар тоткан укучы кызлар биюе белән Ленар Әхмәтҗанов башкаруында “Саумы, мәктәп” җыры яңгырый.

Мәктәп директоры Шайхутдинов Илдус Нургаян улы мәктәбебезнең 75 еллыгына багышланган юбилей тантанасын ачып җибәрә. Бәйрәм барышында кунаклар белән таныштырыла, мәктәпнең барлыкка килүеннән башлап бүгенге көнгә кадәр булган тарихын сөйләүче кунаклар, ветераннар чыгышлары арасында укучылар, укытучылар, һәвәскәр артистлар көче белән оештырылган җыр һәм биюләр, инцезировкалар бер кешене дә битараф калдырмый. Кемдер танышларын очратудан, укытучылары белән күрешүдән шатлана, кемдер күзләрен сөрткәләп ала. Казаннан кайткан дәрәҗәле кунак Хазиев Мулламөхәммәт абый исә тальян гармунын алып, яшь чакларын искә төшереп, моңлы көйләрен суза.



Мәктәп юбилее мизгеле. 2002 нче ел, 15 нче июнь.

Район хакимияте башлыгы Сәетов Рәфис Фәрит улының котлавы, министрлык вәкиленең, мәгариф бүлеге җитәкчеләренең чыгышлары һәрбер кешене дулкынландыра, алар мәктәп, мәктәпнең укытучылары, укучыларын яхшы яктан гына искә алалар, матур теләкләр телиләр, бүләкләр тапшыралар.



Район хакимияте башлыгы юбилейга җыелган барча халыкны котлады, укытучыларга, хезмәткәрләргә хезмәтләре өчен рәхмәт белдерде.

Президент аппаратында эшләүче авылдашыбыз Сәхиева Рәйсә Габдулла кызы һәм ТНВ каналы җитәкчеләреннән берсе Миләүшә Айтугакованың эчтәлекле котлаулары һәрбер кешене уйландырырлык була.




Мәктәпнең элеккеге укучылары – бүгенге Казан кунаклары мәктәпне онытмыйлар.
Мәктәп директоры Татарстан Республикасы Президентының
Дәүләт хокукый идарәсе начальнигы Сахиева Райса Габдулловна һәм
Татарстан Республикасы Югары суды судьясы Имамова Лариса Габдулловна белән. Август, 2007 нче ел.

Чыгыш ясаучылар һәм үзешчән сәхнә артистлары чыгышлары озак бара. Азакта сәхнәгә ветеран укытучылар чыга, аларны барлык халык тәбрикли, сәламәтлек тели. Соңыннан сәхнәгә мәктәптә эшләүче укытучылар коллективы чыгып, онытылмаслык эчтәлекле җыр башкаралар. Аларга барлык халык матур теләкләр телиләр.



Юбилеебызның иң кадерле кунаклары – дистәләрчә еллар буенча мәктәптә укытып, лаеклы ялга чыккан ветеран укытучыларны җыелган барлык халык тәбрикләде, бүләкләде һәм рәхмәт әйтте.

Соңнан килгән кунаклар өчен зәвык белән бизәлгән аш өстәлләре янында җыр-бию астында төшке аш була.

Сәхнәне Тугызбуй төркеменең берничә сәгатькә сузылган эчтәлекле концерты ала. Бәйрәм кичкә кадәр дәвам итә, авылга, гаиләләргә, табигать кочагына күчә.

Төшке аштан соң мәгариф бүлеге җитәкчеләре, методистлары һәм ТР Мәгариф министрлыгының гомуми урта белем бирү булеге җитәкчесе Кәримуллин Фәрит Габидуллович һәм Әгерҗе районы мәктәп директорлары катнашында мәгариф алдында торган проблемалары буенча эшлекле сөйләшү булды. Сөйләшү күпчелек авыл мәктәпләрен реструктуризацияләүнең негатив тәэсире турында бара, мәктәп директоры Шайхутдинов Илдус Нургаянович авыл

мәктәпләрен реструктуризацияләү политикасының нигезсез икәнлеген дәлилләп чыгыш ясый, сөйләшүдә катнашучыларның күпчелеге чыгыш ясаучыны хуплап чыгалар.

Мәктәбебезгә Ләбиб Айтуганов исеме бирелгәннән соң педсовет карары белән уку елы эчендә укуда һәм укудан тыш юнәлешләрдә курсәткән зур уңышлары өчен аерым укучыларга ел саен Ләбиб Айтуганов исемендәге премия бирелә башлады, 2003-2004 уку елыннан башлап 14 ел буенча мондый уңышка 26 укучы иреште (исемлек кушымтада бирелә) , Бакиров Камил һәм Бакирова Фәнзияләрнең кызлара Бакирова Айсинә мондый премиягә 6 тапкыр лаек булды.

Бу чорда мәктәп укыту һәм тәрбия юнәлешендә дә зур адымнар белән алга атлый. Укыту-тәрбия эшендә яңа технологияләр, методикаларны өйрәнү, аларны тормышка ашыру юнәлешендә директор урынбасарлары ярыша-ярыша армый-талмый эшлиләр, һәм күп тә үтми, бу эш үз җимешләрен дә бирә башлый. Берничә ел эчендә мәктәп районда иң яхшы мәктәп булып җитешә. 2004 елда ул “Ел мәктәбе- 2004” район конкурсы җиңүчесе була, алдагы елда “Новое лицо школьного двора» конкурсында җиңү яулый. Мәктәптә Муратова Галия Габдулловна төзегән “Булачак журналист мәктәбе” программасы нигезендә бер төркем сәләтле укучыларны шушы профессиягә әзерләү эше кызыклы, киң колачлы төсмер ала. Бу эшкә татар теле һәм әдәбияты укытучысы Шәрипова Гөлия Мәгъсүм кызы үзенең зур өлешен кертә. Мәктәптә “Тамчылар” радиостудиясе эшли. Укучылар ике төркемгә бүленеп, һәр атнаны җирле колхоз радиоузелыннан Девятерня, Нарат, Гали авылларына радиотапшырулар яңгыраталар, тапшыруларнын тематикасы, диапозоны мәктәп тормышын гына түгел, авыл тормышы, аның әхлагы, проблемаларын да үз эченә ала. Бу эштә аеруча активлык, инициатива күрсәткән укучылар: Муратова Рамилә, Загретдинова Альбина, Рамазанова Фәнзилә, Шайхутдинов Булат, Ситдиков Ришат, Шакирова Ләйлә, Шарипова Айсинәләрне билгеләп үтәргә була. 2002 елның июнендә мәктәбебезнең яшь хәбәрчесе Рамилә Муратова, “Тамчылар” радиотапшырулар төркеме кызлары Альбина Заһретдинова, Ләйлә Шакировалар “Алтын каләм” республика балалар һәм яшьләр иҗат фестивалендә катнашу хокукына ия булып, “Борис Полевой” теплоходында Казан-Самара-Саратов-Казан маршруты буенча иҗади сәяхәттә булып кайталар. Муратова Рамилә “Алтын каләм” республика фестивале гран-приена лаек булып, Казан дәүләт университетының журналистика факультетына льготалы кабул ителү хокукы ала.



2001 елда ТНВ каналының “Яшьләр тукталышы” тапшыруы мөхәррире Рамилә Сәхәбетдинова җитәкчелегендәге журналистлары 10 сыйныф укучысы, балалар һәм яшьләр өчен чыгучы матбугат басмаларының актив хәбәрчесе Рамилә Муратова турында тапшыру әзерләргә килде.

Нәтиҗәдә берничә ел эчендә шушы мәктәпне үткән бер төркем укучы журналистика юнәлешен профессия итеп сайлый. Алар арасында ТНВ каналы бүлек редакторы Фазлыева Ләйсирә, “Гаилә һәм мәктәп” журналы редактор урынбасары Муратова Рамилә, Удмурт республикасында нәшер ителүче “Яңарыш” газетасы, Удмурт дәүләт телевидениесенең татар телендә чыгучы тапшырулар журналистлары Заһретдинова Альбина, Хуҗина Эльвиралар бар.

Студия егетләре, кызлары актив җәмәгать тормышы алып бару белән бергә, төрле бәйгеләрдә катнашалар, укуда да сынатмыйлар. Шушы елларда мәктәпне 4 укучы медаль белән тәмамлый. Алар: Муратова Рамилә, Шайхутдинов Булат, Шакирова Ләйлә Рәис кызы, Хөснетдинова Энҗимә.

Бу елларда укыту-тәрбия процессында яңа эффектлы педагогик технологияләр кулланыла, шуның нәтиҗәсе буларак уку сыйфаты һәм өлгереш күтәрелә, һәр елны мәктәпне тәмамлаган укучыларның 40-50 % ы югары уку йортларының бюджет бүлекләренә укырга керә, район олимпиадаларында, республика конкурсларында фестивальләрдә җиңүчеләр һәм призерлар арта.

Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының 2004 елның 9 февралендә чыккан 132-р номерлы боерыгы нигезендә якташыбыз, күренекле татар шагыйре һәм композиторы Л.Айтугановның исемен мәңгеләштерү йөзеннән Девятерня урта гомумбелем бирү мәктәбенә Ләбиб Айтуганов исеме бирелә. Л.Айтуганов туган көнендә Казанда Г.Тукай исемендәге филармониянең концерт залында тантаналы кичә була, анда Шайхутдинов И.Н., Муратова Г.Г., Әхмәтҗанов Л.Р. лар составында мәктәп делегациясе катнаша һәм барысы да чыгыш ясый. Ленар чыгышыннан соң татарның күренекле җырчылары Резеда Галимова, Илһам абый Шакировның: “Булдырдың, егет!” дигән сүзләре истә калган.



Элеккеге мәктәбебез укучысы – күренекле композитор, язучы Ләбиб Айтуганов 2004 елның февралендә бик күп күренекле кунакларны җыйды, чөнки бу көнне мәктәбебезгә аның исеме бирелүгә багышланган тантана булды.

2004 елның 24 сентябрендә Девятерня урта гомумбелем бирү мәктәбенә якташыбыз Ләбиб Айтуганов исеме бирелүгә багышланган “Истә, һаман да истә”дип исемләнгән тантаналы кичә була. Тантанада ТНВ телерадиокомпаниясе генераль директоры урынбасары Айтуганова Миләүшә Ләбиб кызы, Татарстанның атказанган һәм халык артистлары Илсур Сафин, Флера Сөләйманова, район җитәкчеләре, Ләбиб Айтугановның туганнары катнаша. Кичәдә тагын бер шатлыклы мизгел була: мәктәп директоры Илдус Шайхутдинов укуда, җәмәгать тормышында актив катнашкан укучыларга Л.Айтуганов исемендәге премия булдыру турында боерык чыгарылуын белдерә. Бу премиягә мәктәп тарихында беренче тапкыр уку отличниклары, мәктәп үзидарәсе членнары Ләйлә Шакирова (Рәис кызы), Булат Шайхутдинов, Айсинә Шәрипова лаек була.



**Мәктәбебезнең иң яхшы укучыларына Ләбиб Айтуганов стипендиясе бирү барышы. Стипендияне Татарстан – яңа гасыр телерадиокомпаниясенең иҗади эшләр бүлеге генераль директор ярдәмчесе, филология фәннәре кандидаты, Ләбиб Айтугановның кызы Миләүшә Айтуганова тапшыра.**

21 нче гасыр башы безнең мәктәптә генә түгел, бөтен җәмгыятебездә, шул исәптән мәгариф системасында да зур үзгәрешләр чоры була. Россия мәктәпләрендә профильле укытуга әзерлек эшләре бара. Бу яңалыкны безнең мәктәп укытучылары да хуплап каршы алып, аңа кушылалар. Ата-аналар, укучылар, укытучылар фикерләрен анализлаганнан соң, мәктәп җитәкчелеге социаль-экономик юнәлешне сайлый. Мәктәп районда иң беренчеләрдән булып шушы юнәлештә профильле белем бирүгә керешә. Мәктәптә Галия Габдулловна авторлыгында “2004-2010 елларга гомумбелем бирү мәктәбенең үсеш программасы” эшләнә. Программа үзе VI Республика укыту-методик эшләнмәләр һәм авторлык программалары конкурсында катнашып, I дәрәҗә дипломга лаек була. Программада техник прогресс, компьютерлаштыру, информатизация чорында балаларның рухи үсешенә зур игътибар ителә. Проектта тасвирланган чыгарылыш укучысы моделе буенча югары класс укучылары мәктәпне тәмамлап чыкканда, җәмгыятькә яраклы, мәктәптә алган белем-күнекмәләрне тормышта кулланырдай, тормышта үз урынын табардай, илебез законнарын белә һәм үти торган коммуникабельле шәхес булып чыгарга тиеш була. Әлеге программада “Һөнәрне аңлы рәвештә сайлауга укучыны ничек әзерләргә?” дигән сорау кызыл җеп булып сузыла. Профильле укытуга күчүнең максаты баланы кайсыдыр бер һөнәрнең бар нечкәлекләренә төшендерү түгел, ә аңа үзенең мөмкинлеген, сәләтен аңларга өйрәтү була. Мондый сыйныфларда укытучылар укучыларга проект эшчәнлеге белән шөгыльләнергә, дөньяны, тормышны үз күзләре белән күреп танып белергә бар мөмкинлекләрне булдырырга тырышалар. Мондый укытуга күчү белән 2005-2006 уку елында ук профиль сыйныфлары белән мәктәп директоры Шайхутдинов И.Н. укытучылар Муратова Г.Г., Рахматуллин И.Р., Габбасов А.Г., Саттарова Л.В.лар җитәкчелегендә “КамАЗ”, “Нижнекамскнефтехим”, Менделеев химия заводларына, шулай ук башка инфраструктура объектларына эшлекле экскурсияләр оештырыла. Укучыларның фәнни җәмгыятенә йөрүчеләр 2006-2007 уку елында Болгар һәм Биләрдә, Алабугада, татар мөхитенә Габдулла Кариев кебек күренекле шәхесләрне биргән 600 еллык тарихлы Колбай-Мораса авылында булып, эзләнү эшләре алып баралар. Экскурсия барышында туплаган фото һәм видеоязмалар, мультимедия чараларын киң кулланып, фәнни конференцияләр уздыру балаларга күргәннәрен тагын бер кат ныгытырга ярдәм итә. Укучылар проект эшчәнлеге белән дә бик теләп шөгыльләнәләр. Алар район, республика күләмендәге фәнни-гамәли конференцияләрдә уңышлы чыгышлар ясыйлар. Күп проектлар кәгазьдә генә калмый, тормышка ашырыла. Укучыларның Рахматуллин Ирек Рафаил улы җитәкчелегендә эшләнгән куян фермасы турындагы бизнес-планы тормышка ашырылып мәктәптә “Малыш” исемендәге мини ферма төзелә.




*Мәктәп минифермасы укучылары*



*Миниферма җитәкчесе Рахматуллин Ирек Рафаил улы*

Гатауллина Гөлүсә Вәлиулла кызы җитәкчелегендә эшләнгән “Мин һәм минем сәламәтлегем” проектлары I Республика “Сәламәтлек культурасы” проектлар конкурсында “Иң сәләмәт балалар коллективы” номинациясендә җиңүче исеменә лаек була. 2008 елда Татарстан республикасы буенча “Сәламәт гаилә” проектында катнашып Габбасовлар гаиләсе “Әти, әни, мин – сәламәт гаилә“ номинациясендә җиңүче, Валеевалар гаиләсе өченче урынга лаек булып, 2009 елда “Әти-әни һәм мин – спорт сөюче гаилә” республика конкурсында Арслановлар гаиләсе беренче, Габбасовлар гаиләсе өченче урынны яулап, кыйммәтле бүләкләргә лаек булалар.




Шул ук елны “Без наркотикларга каршы” дип аталган республика иншалар конкурсында Хузина Эльвираның эше икенче дәрәҗә дипломга лаек була. 2010 елда балалар һәм яшүсмерләр прессасы Республика проектлар конкурсында “Иң төп сүз” дигән номинациядә мәктәп 1 урынны ала. Физкультура укытучысы Гатауллина Гөлүсә Валиулла кызы 2006, 2007, 2008 нче уку елларында “Супер тренер “ номинациясендә җиңүче исемен ала.

Бер төркем укучылар 2003 һәм 2011 елларда укыту-тәрбия эшләре буенча директор урынбасары Моратова Г.Г., тәрбия эшләре буенча директор урынбасары Гатауллина Г.В. һәм рус теле укытучысы Шарипова А.А. тарих укытучысы Валеева Л.М. белән берлектә көзге каникул чорында Алабуга шәһәренә экскурсиягә җибәрелә.

2000 елның 7 декабрендә мәктәбебездә “Милли-региональ компонентлар аша укучыларның иҗади сәләтен үстерү” темасы астында бай эчтәлекле, кызыклы укытучыларның зона семинары иҗади активлыкта үтә. Бу чара татар мәктәпләрендә татар теле һәм әдәбияты, башлангыч сыйныф укытучылары белән берлектә оештырыла. Компьютерлар локаль челтәргә берләштерелә, информатика укытучысы Фаррахов Флүр тырышлыгы белән эшли башлый. Шул елларда PENTIUM тибындагы яңа компьютерлар кайтып, эшли башлый. 2001нче елның 16 апрелендә “Спорт сәламәтлек сәгате- балалар күзе белән” конкурсы уздырыла, мәктәбебез уңай яктан телгә алына. 2002 нче елның 16 апрелендә “Спорт сәламәтлек сәгате- балалар күзе белән” конкурсында мәктәбебез командасы 2 урынны яулый. Традицион район педагоглары конференциясендә “Укучыларда уку-белем алу күнекмәләре” темасына үткәрелгән алдынгы педагогик тәҗрибә уртаклашу күргәзмәсендә мәктәп “Иң яхшы күргәзмә” исеменә лаек була. “Россия балалары ” исеме астында үтүче балаларны компьютер белән тәэмин итүче президент программасы нигезендә компьютерлар һәм модем кайтып урнаштырыла.



2004 елның гыйнвар аенда ТИН курсы буенча ел укытучысы бәйгесендә Девятерня урта мәктәбе (укытучысы Муратов К.Н.) район буенча 2 нче урынны яулый. 24 мартта 56 укучы һәм 17 җитәкче тәрбия эшләре буенча директор урынбасары Гатауллина Г.В. җитәкчелегендә Казан шәһәрендә экскурсиядә булып кайталар. Экскурсия бик бай эчтәлекле, онытылмас хатирәләргә бай булып исебездә калды. Район буенча үткәрелгән Бөек җиңүнең 60 еллыгына багышланган “Сугышчан Дан заллары” конкурсында Девятерня урта гомумбелем бирү мәктәбе 1 нче урынны ала. 2005 нче елның сентябрендә Л.Айтуганов ис. Девятерня урта гомумбелем бирү мәктәбендә спорт мәйданчыгы ачыла. Мәктәпнең төп бинасы каршында эти-әниләр соравы буенча балалар бакчасында тәрбияләнүчеләр өчен уен мәйданчыгы белән ябык веранда, беседка төзелә. Шулай ук ясалма сулык, фонтан, укытучылар һәм балалар өчен ял итү урыны, сәхнә һәм тамашачылар залы белән җәйге актовый зал төзелә.



*Л.Айтуганов ис. Девятерня урта гомумбелем бирү мәктәбенең территориясе 32073,3 кв.м тәшкил итә. Шулай ук 9960,75 кв.м күләмендә укыту-тәҗрибә урыны да бар.*

2004 елның 23 декабрендә мәктәпнең уңай эш тәҗрибәсен исәпкә алып Әгерҗе районы мәгариф бүлеге һәм методик кабинеты рекомендациясе буенча “Мәктәп җитәкчесе хезмәтен оештыру” темасына Л.Айтуганов ис.Девятерня урта гомумбелем бирү мәктәбендә районның барлык мәктәп директорлары һәм УТЭ буенча директор урынбасарлары, шулай ук район мәгәриф бүлеге җитәкчеләре катнашында район семинары була. Семинар-практикум эшлекле, югары әзерлекле дәрәҗәдә үтә. Семинарда катнашучылар, мәктәп җитәкчелегенә, укытучылар коллективы эшчәнлегенә югары бәя бирәләр. 2004 елның 20 октябрендә районда тарих һәм җәмгыять белеме кабинетларына конкурс булып, укытучы Валеева Л.М җитәкләгән тарих кабинеты зональ этапта 2 урынны ала.

2005 нче елны Девятерня урта мәктәбе Көчек урта мәктәбе белән берлектә Әгерҗе районы мәгариф учреждениеләре исеменнән “Образование. Карьера. 2005” республикакүләм күргәзмәдә катнашып, “Лучшая экспозиция системы образования” номинациясендә җиңеп, Диплом белән бүләкләнә.

2006 нчы елның 16 ноябрендә 9, 10, 11 класс укучылары, укытучылар Шайхутдинов И.Н, Муратова Г.Г., Гатауллина Г.В., Саттарова Л.В., Габбасов А.Г.лар җитәкчелегендә Сарапул шәһәренең 29 номерлы һөнәр училищесында “Ачык ишекләр” көнендә, төбәкне өйрәнү музеенда, драма театрында булып кайталар.

Шушы чорда укыту-тәрбия өлкәсендә күрсәткән хезмәтләре, ирешкән уңышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәтләре өчен укыту-тәрбия эшләре буенча директор урынбасары

Муратова Галия Габдулла кызына “Татарстан Республикасының атказанган укытучысы” дигән мактаулы исем, ә тәрбия эшләре буенча директор урынбасары Гатауллина Гөлүсә Вәлиулла кызына “Почетный работник общего образования РФ” билгесе бирелә.

Л.Айтуганов ис. Девятерня урта гомумбелем бирү мәктәбендә даими рәвештә 21 укытучы эшли, ләкин 10 эчендә контингент төрле сәбәпләр нәтиҗәсендә тулыланып үзгәреп тора.

2000-2010 нчы елларда Девятерня мәктәбендә эшләгән укытучы-тәрбиячеләр:

1. Шайхутдинов Илдус Нургаян улы – география укытучысы.
2. Муратова Галия Габдулла кызы – рус теле һәм әдәбияты укытучысы.
3. Гатауллина Гөлүсә Вәлиулла кызы – физкультура, сәламәтлек сәгате укытучысы.
4. Шакирова Зөлфия Хәйдәр кызы – башлангыч класслар укытучысы.
5. Мөсифуллина Нурия Шамил кызы – башлангыч класслар укытучысы.
6. Арсланова Алия Наил кызы – башлангыч сыйныфлар укытучысы.
7. Габбасова Гүзәлия Гыез кызы – башлангыч сыйныфлар, технология-рәсем укытучысы.
8. Шайхутдинова Резидә Мөнәвир кызы – башлангыч сыйныфлар укытучысы.
9. Даутова Әлфинур Фәйзулла кызы – рус теле һәм әдәбияты, татар теле һәм әдәбияты, технология укытучысы.
10. Шәрипова Гөлия Мәгъсүм кызы – татар теле һәм әдәбияты укытучысы.
11. Шәрипова Әлфия Әзһәр кызы – рус теле һәм әдәбияты укытучысы.
12. Саттарова Ләйсирә Вәгыйз кызы – физика, математика укытучысы.
13. Әхмәтҗанова Мөхтәрәмә Мөхәмәтдин кызы – математика укытучысы.
14. Валиева Ләрисә Муллаян кызы – тарих, җәмгыять белеме укытучысы.
15. Муратов Камил Нургаян улы – ТИН укытучысы-оештыручысы.
16. Габбасов Айнур Габделнур улы – биология-химия укытучысы.
17. Фаррахов Флүр Ромим улы – технология-информатика укытучысы.
18. Фархушина Гөлфия Илфат кызы – башлангыч сыйныфлар укытучысы, балалар бакчасы мөдире, мәктәпкәчә яшьтәге балалар төркеме тәрбиячесе.
19. Ахметова Мәүгыйдә Габденур кызы – башлангыч сыйныфлар укытучысы.
20. Габдрахманова Илзирә Илгиз кызы – башлангыч сыйныфлар укытучысы, Гали башлангыч гомумбелем бирү филиалы укытучысы.
21. Назмутдинов Фаяз Фәррах улы – профессиональ белем нигезләре укытучысы, трактор йөртергә өйрәтү инструкторы.
22. Габдрахманова Гөлфия Габдулла кызы – китапханәче.
23. Арсланов Фәнис Фазыл улы – җыр-рәсем укытучысы.
24. Симаков Раил Фирдүс улы – физкультура укытучысы.
25. Ахметзянов Ленар Рәис улы – тарих, музыка укытучысы.
26. Рахматуллин Ирек Рафаил улы – җәмгыять белеме, тарих, экономика укытучысы.
27. Рахматуллина Лилия Рафаил кызы – инглиз теле укытучысы.
28. Муллахметова (Ахметова) Гөлназ Расим кызы – башлангыч сыйныфлар укытучысы.
29. Амерханов Фирзан Нарулла улы – химия-биология укытучысы.
30. Амерханова Әлфия Шамил кызы – инглиз теле укытучысы.
30. Загретдинова Алсу Касыйм кызы – башлангыч сыйныфлар укытучысы.
31. Ахметзянов Рәис Габдулла улы – тарих укытучысы (вакытлыча).
32. Шәехов Рамис Рафыйк улы – инглиз теле укытучысы.
33. Садыкова Вәсилә Мөдәллиф кызы - башлангыч сыйныфлар укытучысы.
34. Зиятдинова Лилия Раил кызы – Гали башлангыч гомумбелем бирү филиалы укытучысы.
35. Файзуллин Рафил Рифгат улы – профессиональ белем нигезләре укытучысы, трактор йөртергә өйрәтү инструкторы.
36. Газизова Энже Мөхәмәтнур кызы – инглиз теле укытучысы.
37. Ахмадиева Алсу Илфат кызы – рус теле һәм әдәбияты укытучысы.
38. Гараева Гөлйөзем Сабир кызы – инглиз теле укытучысы, мәктәпкәчә яшьтәге балалар төркеме тәрбиячесе.
39. Хузяхметов Мансур Мөхәмәтдин улы - трактор йөртергә өйрәтү инструкторы.
40. Рахматуллина Ләйлә Фаил кызы – татар теле һәм әдәбияты укытучысы.

41. Закиров Илнур Илфат улы - трактор йөртергә өйрәтү инструкторы.

42. Усманов Фердинанд Рәис улы - трактор йөртергә өйрәтү инструкторы.

43. Фархушина Гөлнара Фәһем кызы - мәктәпкәчә яшьтәге балалар төркеме тәрбиячесе.

44. Гиззатуллина Альбина Шамил кызы – физика укытучысы. (Кадыбаш мәктәбе укытучысы, бер үк вакытта мәктәптә физика фәнен укыта).

Укыту тәрбия эшләре буенча директор урынбасары Муратова Галия Габдулловна “Лидер в образовании Республики Татарстан – 2006” республика конкурсында катнашып, җиңеп чыга. 2006-2007 нче уку елында мәктәп базасында “Укучыларның туган як тарихы, әдәбияты, сәнгате буенча фәнни-эзләнү эшчәнлеге, укыту-тәрбия процессында милли төбәк компонентларын кулланууда мәктәп китапханәсенең роле” темасына мәктәп китапханәчеләре район семинары, “Сәламәтлекне саклаучы технологияләр – заман мәктәбендә актуаль проблема” темасына мәктәп директорлары һәм физик тәрбия укытучылары район семинары үткәрелә. Ел әйләнәсендә мәктәптә укучылар контингентын саклау һәм арттыру буенча эзлекле максатчан эш алып барыла, нәтиҗәдә эти-әниләр һәм мәктәп хезмәткәрләре арасында күп балалы гаиләләр (мәсәлән, укытучылардан Даутовлар, Шариповлар, Фаррахувлар, Фархушиннар) барлыкка килә, тәрбиягә алган балалар саны арта. 2006-2007 нче уку елы башына мәктәптә укучылар саны 77 булса, уку елы азагына ул 80гә җитә. Укучыларга өстәмә белем бирү “Иҗади гөлбакча”, “Яшь натуралист”, “Эзтабар”, “Спорт аэробикасы” түгәрәкләре, баскетбол, волейбол секцияләре аша оештырыла. 2007 елда мәктәптә барлыгы 11 түгәрәк һәм секция эшли, 3 яңа түгәрәк өстәлә – “Волшебница», «Я и мое здоровье», «Любопытный Незнайка». Укучылар белән туган якны өйрәнү, шул юнәлештә эзләнү эшләре алып бару максатында, һәр уку елында экскурсияләр оештырыла. 19 укучы һәм укытучылар Болгар-Биләр маршруты буенча экскурсиядә, 15 укучы белән Сарапул шәһәренең №29 нчы профтехучилищесында “Ачык ишекләр” көнендә, 23 укучы белән Сарапул шәһәренең педколледжында һәм “Лилия” чәчәкләр үстерү теплицасында һәм 12 нче номерлы каты режимлы колониядә булса, 23 укучы меңъеллык Алабуга шәһәренә экскурсиядә була. Ел дәвамында берничә тапкыр район җитәкчелеге, Чаллы шәһәреннән Марсель хәзрәт, “Яңарыш” редакциясе хезмәткәрләре укучылар һәм укытучылар коллективы белән очрашалар. Укучыларыбыз республика һәм Россия күләмендә төрле бәйгеләрдә катнашып, зур унышларга ирешәләр: 4 укучы регионара физика-математика олимпиадасы җиңүчеләре дипломнары ала.

2005-2006 нчы уку елыннан мәктәбебездә ветеран укытучы Шайхутдинова Лена Габлулловнаның улы Рахматуллин Ирек Рафаил улы Казан дәүләт педагогика университетының тарих факультетын кызыл дипломга тәмамлап, хезмәт юлын башлый. Югары интеллектка ия яшь, энергияле белгеч туган мәктәбенә күп төрле яңалыклар алып килә, мәктәптә фәнни-тикшеренү эшчәнлеген җанландырып, күп балаларны проект эшчәнлегенә җәлеп итә. Ирек Рафаил улы профиль фәннәрен укыту программалары төзү, яңа укыту технологияләрен, алымнарын кертүгә зур көч куя, әлеге сыйныфларда белем алучы укучылар белән төрле шәһәрләрдәге сәнәгать предприятиеләренә, тарихи-мәдәни һәйкәлләргә экскурсияләр оештыруда катнаша, 4 укучы белән Казанда “Перспектива” республика конкурсында үз проектлары белән катнашып 3 урынны яулыйлар, 3 укучы Россия күләмендә “Кенгуру” бәйгесендә көч сынашып зур уңышка ирешәләр. Компьютер графикасы буенча “Волшебный мир сказок” ачык халыкара конкурсында катнашып, Шарипов Айдар (8 кл.) сертификатка лаек була. Ирек Рафаил улы 2006 елда район башлыгы грантына үткәрелгән “Елның яшь укытучысы-2006” бәйгесендә лауреат була, 2010 елда “Ел укытучысы” бәйгесенең “Яшь белгеч” номинациясендә 1 урынны яулый. Ә 2012 елда Ирек Рафаил улы Казанда районыбыз данын яклап “Ел укытучысы” конкурсының финал бәйгесендә республиканың иң яхшы 50 укытучысы белән көч сынаша һәм 4 урынны яулый.

2007 нче елның 27 нче ноябреннән Девятерня балалар бакчасы район башлыгы карары белән мәктәпкә кушылды, балалар бакчасы хезмәткәрләре: 2 тәрбияче, 4 техник хезмәткәр мәктәпкә эшкә күчереләләр.



*2006 елда балалар бакчасында мөдир Гараева Гөлйөзем Сабир кызы һәм тәрбияче Шайдуллина Алсу Рамиль кызы җитәкчелегендә 16 бала тәрбияләнде. Алгы рәттә сулдан уңга: Гатауллина Ләйлә, Шакирова Алия, Ильясова Нәргизә, Фархушин Булат, Нуриев Данил, Погудин Даниил, Фаррахова Ләйсән. Икенче рәттә уңнан сулга: Гильфанова Чулпан, Зарипов Дәнис, Сибятов Ильназ, Фаррахова Алсу, Шакирова Айгөл, Шарипов Нияз, Рамазанов Айнур. Өченче рәттә: мөдир Гараева Гөлйөзем, Шарипова Элина, Шаяхметова Ильнара һәм тәрбияче Шайдуллина Алсу.*

2008 елның 31 январендә Әгерҗедән һәм Башкортстан Республикасыннан килгән Әфган сугышы ветераннары көче белән "Яшел беретлар" исемле хәйрия концерты булып, Әфганстанда башын салган якташыбыз - Нарат авылы егете, мәктәбебезнең элеккеге укучысы Рәфис Хөснетдиновка мемориаль такта куела.

Мәктәп китапханәсе укыту-тәрбия эшенә кирәкле дәреслекләр һәм башка әдәбият белән тулысынча тәэмин ителгән, 49 исемдә 1 комплект медиатека бар.

Мәктәп 24 исемдә вакытлы матбугат чаралары — газета, журналлар алдыра. Аларның 11е (45,8 %) укытучыларга һәм мәктәп җитәкчеләренә методик яңалыклар, мәгариф буенча норматив документлар турында информация бирә ("Открытый урок", "Завуч", "Классный руководитель", "Вестник образования РТ", "Вестник образования РФ", "Сельская школа" һ.б.). Моннан тыш, укытучыларның барысы да предмет журналлары алдыра.

Мәктәптә шул елларда даими рәвештә 13 техник хезмәткәр эшләсә, аларның составы еллар барышында үзгәреп тора.

***Шул елларда мәктәптә эшләгән техник хезмәткәрләр*:**

1. Файзуллин Рифгат Фәйзулла улы – завхоз.
2. Закиров Илфат Муллаян улы – автомобиль йөртүче, ягучы.
3. Фаррахова Рәйсә Рәис кызы – лаборант, секретарь.
4. Нуриева Резидә Назыйм кызы – пешекче.

5. Фаррахова Рәмзия Фатыйх кызы – кухня хезмәткәре.
6. Бакирова Фәнзия Рәис кызы – җыештыручы.
7. Гатауллина Гөлсинә  Хәйдәр кызы - җыештыручы.
8. Фатхетдинова (Зарипова) Лилия Мөхәмәтнур кызы – җыештыручы.
9. Абдуллина Фәридә Мәсгут кызы – җыештыручы.
10. Фархушина Гөлия  Мөхәмәтнур кызы - җыештыручы.
11. Фархушина Ольга Ивановна – җыештыручы.
12. Ахметов Рафаэль Минегаян улы – төнге каравылчы.
13. Валеева Татьяна  Николаевна    - төнге каравылчы.
14. Гилязетдинов Рәвил Гыйләҗетдин улы – төнге каравылчы.
15. Валиев Альберт Рәхимҗан улы – төнге каравылчы, оператор.
16. Шаяхметов Рафаэль Хаҗи улы  - вакытлыча төнге каравылчы.
17. Бакиров Камил Мөхәмәтдин улы – төнге каравылчы, автомобиль йөртүче.
18. Әхмәтҗанова Рәйсә Суфиян кызы  - пешекче.
19. Ильясова Гамилә  Мөхәмәтдин кызы – пешекче.
20. Мусина Рүзилә Рифгат кызы – җыештыручы.
21. Нуриев Фәнил Мулламөхәмәт улы – оператор.
22. Шарипов Илшат Илдус улы - өлкән оператор.
23. Ситдиков Ришат Рифкат улы – оператор.
24. Ахмадиев Фәрит Илфат улы – электрик.
25. Фазлыев Илдар Рәкыйп улы – электрик.
26. Шакирова Рәмзия Илтизәр кызы – бакчачы.
27. Закирова Сабира Минехан кызы – лаборант.
28. Латыйпова Рафилә Мөхәмәтнур кызы – конюх.
29. Даутов Рамил Муллаян улы – төнге  каравылчы.
30. Галина Зөлфирә Шәех кызы – җыештыручы.
31. Рамазанова Кадрия Мансур кызы – җыештыручы.
32. Гильфанова Миләүшә Мөхәмәтнур кызы – тәрбияче ярдәмчесе, кер юучы.
33. Габдрахманова Ләйсирә Сәгыйт кызы – пешекче.
34. Гараев Фәнил Нәкыятулла улы – дворник.
35. Хузяхметов Мансур Мөхәмәтдин улы – төнге каравылчы.
36. Бадряшова Марина Владимировна – җыештыручы.
37. Гатауллин Рөстәм Габделхай улы – төнге каравылчы.
38. Бурнышев Илья Владимирович – төнге каравылчы

Техперсонал белән мәктәптә 1993 нче елдан шофер булып эшкә урнашкан, ә 1997 нче елдан 2014 нче елга кадәр завхоз булып эшләгән Файзуллин Рифкат Файзулла улы җитәкчелек итә. Эш барышында техперсонал үзләренә тапшырылган эшкә бик җаваплы карый: көндез һәм төнлә дежурлык һәм каравыл өзелми, мәктәптән һәм территориядән бер әйбернең дә югалганы булмый, һәр көнне мәктәп чистартыла-җыештырыла, бик күп гөлләр утыртыла, техника һәм хезмәт куркынычсызлыгы таләпләре төгәл үтәлә. Үзләренең төп функцияләреннән тыш, техперсонал белән үзара өстәмә килешү нигезендә 2002 нче елда,  мәктәпнең 75 еллык юбилеена әзерлек чорында, 2003 нче елда мәктәптә газ керткән вакытта һәм соңнан мәктәп эчендә һәм территориядә бик күп кирәкле объектлар төзелә. Күпләп саклау өчен яшелчә базы ремонтлана, ике теплица (берсе пирамида формасында), мастерской өчен хуҗалык сарае, столяр цехы төзелә, җиһазландырыла, гараж һәм столяр цехына  җылылык кертелә, артезиан скважинасы ремонтлана, душ һәм ял итү булмәсе булдырыла, балаларга ял итү өчен рекреациядә кошлар, попугай, балык һәм ташбакаларны эченә алган аквариумнар алына, шулай ук балаларга файдалану өчен телевизор,  магнитофон, DVD-караоке куела. Мәктәп эчендә коридор, ел саен берничә кабинет ремонтлана һәм зәвык белән җиһазлана, китапханә яңа бүлмәгә күчерелеп, озак елларга җитәрлек итеп яңа киштәләр, шкафлар эшләнә, стадионда яңа мәйданчыклар булдырыла, мәктәп территориясенең көньяк ягы яңа тимер койма белән тотыла һәм бизәкләп эшләнгән капка куела, спортзал  эче ремонтланып, яңа тренажер залы булдырыла.

Бюджет средстволарын оптимальләштерү процессында авыл медпункты мәктәп бинасына күчерелә. Казан шәһәренең 1000 еллык юбилеена әзерлек чорында макетлар бәйгесендә катнашып, Казан Кремле башнясы ясала, ул мәктәпкә матурлык өстәп, укучыларга сәгать 8 дә дәрес башланганын искәртеп тора. Файзуллин Рифкат һәм Гараев Фәниlләр тарих укытучысы Рахматуллин Ирек проектлаган мини куян фермасын төзүдә һәм саклауда зур өлеш кертәләр.

Мәктәптә өстәмә булдырылган акча средстволары ярдәмендә ДТ-75 бульдозер тракторы, соңрак Т-25 тракторы сатып алына. Алар трактор йөртергә өйрәтү инструкторы Назмутдинов Фаяз Фәррах улы тырышлыгы белән мәктәпкә, авылга газ керткән вакытта газ траншеяларын күмүдә күп эшли, язгы-көзге чорда мәктәп хезмәткәрләренә һәм авыл халкына зур ярдәм күрсәтә. Кыскасы, техник хезмәткәрләр мәктәпне, мәктәп территориясен ныгытуда, бизәүдә зур көч куялар, һәр эшне алар кыенсынмыйча, зарланмыйча башкаралар, мәктәптә укыту-тәрбия процессын уңышлы алып баруга бик нык булышалар. Алар еш кына үзләре эшләгән бу чорны мәктәпнең чәчәк аткан вакыты дип искә алалар.

